*Күңел һәр җирдә гөл эзли,*
*Кадәр һәр җирдә тикән төзли...*

*Там, где ищет глаз лилей,*
*Насаждает жизнь репей.*

# ДӘРДЕМӘНД
# ДЭРДМЕНД

Лирон Хәмидуллин
Лирон Хамидуллин

Казан
Татарстан китап нәшрияты

Казань
Татарское книжное издательство

2019




*«Каләм! Кальбеңдә ни сер бар – гаян ит...». Рәссамы Нәҗип Нәккаш*
*«О перо! Какая тайна на душе – открой...». Художник Наджип Наккаш*

# Кереш сүз
# Вступительное слово

Һәр милләтнең мәдәни, дини һәм икътисади үсеш дәрәҗәсен билгеләүче үрнәк шәхесләре була. Алар – шул милләтнең яшәешенә һәм алга китешенә билгеле бер дәвердә рухи көч-куәт өстәүчеләр, аны әйдәп баручылар. Татар халкының да андый мәртәбәле, үрнәк алырдай зыялы шәхесләре шактый. Мәсәлән, XIX гасырда яшәгән җәмәгать вә мәгариф-мәдәният әһелләре: Утыз Имәни, Габденнасыйр Курсави, Шиһабетдин Мәрҗани, Каюм Насыйри, Һибәтулла Салихов һ. б. XX гасыр башында татар халкының мәгърифәт өлкәсендәге үсеше өчен күп көч куйган Ризаэддин Фәхретдин, Габдулла Тукай, Гаяз Исхакый, Фатих Кәрими, Фатих Әмирхан, Галиәсгар Камал, Галимҗан Ибраһимов, Сәгыйть Рәмиев, абыйлы-энеле Әхмәтһади һәм Садри Максуди кебек дистәләгән зыялыны күрәбез. Ил күләмендә танылган фабрикант һәм эре сәүдәгәрләр рәтендә йөргән, байлыкларының бер өлешен, халык файдасына булсын дип, мәгариф һәм мәдәниятне үстерүгә тоткан Акчурин, Дибердиев, Сәйдәшев, Хөсәенов, Яушевларыбыз һ. б. да бар. Ул чорда күпчелек мәктәп һәм мәдрәсәләрне шушындый бай иганәчеләр яшәткән. Яшь буынны укытуга алар да үз өлешен керткән.

Россиянең танылган сәнәгатьчеләре, абруйлы нашир һәм җәмәгать эшлеклеләре Шакир белән Закир Рәмиев тә татар зыялыларының шушы иң югары катлавына керә. Аларны, һич икеләнмичә, татар халкының милли үзаңын саклауга һәм үстерүгә зур өлеш кертүчеләрнең иң алгы сафына куярга хаклыбыз. Мәгълүм җәмәгать эшлеклесе Әхмәтһади Максуди да әнә, XIX йөз ахыры вакыйгаларын бәяләгәндә: «Шакир Рәмиев Русиядә фикере иң элек ачылмыш зыялы байлардан иде», – дип язган. Рәмиевләрнең икесенә дә үз милләтләренең

У каждой нации бывают великие личности, определяющие уровень ее культурного, религиозного и экономического развития. Это те, кто в нужный момент истории дает толчок духовной жизни и прогрессу нации. И у татарского народа таких ярких личностей было много. Например, в XIX веке это поэты и общественные деятели: Утыз Имяни, Габденнасыр Курсави, Шигабутдин Марджани, Каюм Насыри, Хибатулла Салихов и др. В начале XX века в просвещение и развитие татарского народа много труда вложили Ризаэддин Фахретдин, Габдулла Тукай, Гаяз Исхаки, Фатих Карими, Фатих Амирхан, Галиасгар Камал, Галимджан Ибрагимов, Сагит Рамеев, братья Ахмет Хади и Садри Максуди и другие представители татарской интеллигенции. Были и известные в стране крупные промышленники и купцы, такие как фабриканты Акчурины, Дибердиевы, купцы Сайдашевы, Хусаиновы, Яушевы, внесшие большой вклад в преображение уклада жизни своих соотечественников, в культурное развитие и образование молодого поколения. Многие школы и медресе содержались тогда за счет средств меценатов из народа.

К этой когорте татарских общественных деятелей и интеллигенции относятся и видные российские золотопромышленники, крупные издатели и общественные деятели Шакир и Закир Рамиевы. Их, несомненно, можно поставить рядом с теми известными личностями, которые много сделали для возрождения национального самосознания своего народа. Эти братья известны как открыватели и содержатели десятков национальных школ в Орском и Верхнеуральском уездах Оренбургского края. Они являлись также

киләчәк язмышы өчен борчылу хас.
Алар – элекке Оренбург губернасының күп кенә авылларында мәчетләр төзеткән, мәктәп-мәдрәсәләр ачкан һәм тоткан шәхесләр. Оренбургтагы атаклы «Хөсәения» мәдрәсәсенең тышкы идарәчеләре – юнәлеш бирүчеләре һәм иганәчеләре дә булганнар.
Урал таулары җирлегендә алтын чыгаручылар буларак танылган Рәмиев байларның ил күләмендәге абруен билгеләүче вакыйгаларны да искә төшереп үтик. Алар патшаларны тәхеткә тәгаенләү тантаналарында, чит ил-дәүләтләр башлыклары да чакырылган мәҗлесләрдә аз санлы мөселман вәкилләре сафында кунак буларак катнашканнар. Мәсәлән, 1881 елда император Александр III не тәхеткә тәгаенләгәндә, Эчке Россия һәм Себер мөселманнары мөфтие Сәлимгәрәй Тәфкилев җитәкләгән бер дистә чамасы кунак төркемендә әлеге ике бертуганның этиләре Мөхәммәтсадыйк Рәмиев була.
Ә 1894 елда Николай II не зурлап тәгаенләү мәҗлесендә мөфти Мөхәммәдъяр Солтанов, Кырым морзасы Исмәгыйль Гаспринсий һ. б. белән бергә Мөхәммәтшакир Рәмиев тә катнаша.
Закир Рәмиев-Дәрдемәнд яшьләргә белем бирү мәсьәләсенә даими рәвештә әһәмият биреп яшәгән. Аның ике шигырь җыентыгын 1929,1959 елларда туплап чыгарган Исмәгыйль Рәмиев: «Кыш айларында Дәрдемәнд һәр атнакичтә бер сәгать вакытын укытучылар һәм белемгә омтылучы мәдрәсә шәкертләре белән очрашуга багышлаган. Ул аларга матди яктан ярдәм дә иткән», – дип язды.
Төрки-татарларның тарихын барлауга зур өлеш керткән галим Зәки Вәлиди дә (1890–1970) Төркиядә чыккан хатирәләр китабында: «Авыл мәктәбендә укыганда ук, мин борынгы әдәбият, тарих белән кызыксындым. Тарихчы Морад Рәмзи бездә булып киткәч, Казан газеталарын да ала идек. Оренбургта бер кыш укыгач, Закир бәй

активными членами правления и частично меценатами одного из известных медресе «Хусаиния» в Оренбурге.
О степени известности в России семьи Рамиевых можно судить и по факту их участия в числе малочисленных гостей-мусульман при коронации императоров Александра III в 1881 и Николая II в 1894 годах. В первом случае на церемонию были приглашены в ряду видных гостей из России и руководителей многих стран также и представители мусульманской знати: муфтий Центральной части России и Сибири Салимгирей Тевкелев, несколько лиц из купеческой знати и отец вышеуказанных братьев Мухаммедсадык Рамиев. А при коронации в 1894 году последнего царя среди семи-восьми приглашенных мусульман из Центральной части России были муфтий Мухаммедъяр Султанов, глава города Бахчисарая мурза Исмагил Гаспринский и из предпринимателей – Мухаммедшакир Рамиев.
Поэт, активный общественный деятель Закир Рамиев-Дэрдменд много внимания уделял просвещению своего народа, особенно молодежи. Составитель и комментатор двух поэтических сборников поэта 1929 и 1959 годов Исмагил Рамиев (1895–1969) пишет в воспоминаниях, что Дэрдменд в зимние месяцы устанавливал день и час приема молодых учителей и шакирдов медресе. К нему в эти часы чаще всего обращались с просьбой об оказании какой-либо помощи или об устройстве на работу. В один из таких дней к нему обратился и будущий общественный деятель и известный ученый-историк Заки Валиди (1890–1970). Этот случай З. Валиди описывает в своих воспоминаниях, изданных в Турции: «Я с детства интересовался прошлым своего народа. После посещения нашего села историка Мурада Рамзи мы стали

Рәмиев белән киңәшергә дип өенә килдем. Казанга барып уку, университет галимнәре белән аралашу хыялым булуын сөйләдем», – дип билгеләп үтә. Һәм Дәрдемәнднең аңа Казанга барып урнашырдай күләмдә акча биреп җибәрүен хәбәр итә.
Бертуган Рәмиевләрнең беренче татар һөнәри скульпторы Мирзаҗан Байкиевка (1868–1942) да Петроградта махсус уку йортында укырга ярдәм иткәннәре мәгълүм.
Орск шәһәрендәге мәдрәсәне тәмамлагач, 1880 елда Закир белем эстәү һәм төрки дөнья тормышы белән танышу өчен дип Төркиягә китә. Һәм ел ярым чамасы Истанбулда яшәгән дәвердә төрек телен үзләштерә, университет укытучыларының дәресләренә йөри. Кайбер мәшһүр язучылар белән таныша һәм алар белән аралаша. Аның шул чорда абыйсы белән язышкан хатларының бер өлеше сакланган. Шакир аңа Төркиядән җибәреп торган газета-журналлар, китаплар өчен рәхмәт әйтә. Чик сагында торучылар ничаклы рөхсәт бирсә, шулай җибәрә аласың, дип тә язган абыйсы. 1881 елгы хатында Шакир: «Татар милләте уянсын дисәң, аның үз матбугатын булдыру зарур», – дип тә язган энесенә.
Бу ике бертуган XIX гасырның сиксәненче еллары ахырында ук татар телендә газета-журналлар нәшер итү турында талпынып карыйлар. Ләкин Рәмиевләр Россия күләмендә танылып килүче сәнәгатьче булуга карамастан, патша хакимиятенең татарларга карата электән килгән тискәре сәясәте ул вакытта әле үзен сиздерә. Аларның һәм алар белән бервакыттарак шундый өмет белән йөргән башкаларның да үтенече кире кагыла. Г. Ибраһимов та 1922 елда нәшер ителгән «Революция вакыйгаларына бәйле материаллар» хезмәтендә казый Рәшид Ибраһимов, Һади Максуди, Шакир вә Закир Рәмиевләр һ. б.ның 1890 елларда шул үтенеч белән мөрәҗәгать иткәнен, патша хакимиятенең аларның барысына да тискәре җавап биргәнен язды.

выписывать газеты на татарском языке из Казани… Проучившись одну зиму в Оренбурге, решился посоветоваться с Закир-беем Рамиевым и пошел к ним домой. Сообщил ему о своем желании учиться в Казани и общаться там с известными учеными университета. Он одобрил мое желание». Дэрдменд вручил тогда ему и определенную сумму денег, достаточную для поездки в Казань и устройства там.
По другим воспоминаниям известно, что братья Рамиевы оказали материальную помощь и первому из татар официальному скульптору Мирзаджану Байкиеву (1868–1942) в период его учебы в Петербургской специальной академической студии.
После завершения учебы в медресе города Орска в 1880 году Закир отправляется в Турцию с желанием расширить свой жизненный кругозор. В Истанбуле он проживет более полутора лет. Займется усвоением турецкого языка, посетит занятия некоторых преподавателей университета, будет общаться с известными писателями и поэтами. Частично об этом мы знаем из сохранившейся переписки братьев и сообщений соратников поэта.
В письмах Шакир благодарит брата за присланные книги, газеты, журналы. Каждый раз просит прислать побольше книг и газет, иногда добавляя слова «насколько разрешат в таможне». В письме от 1881 года Шакир пишет брату, что «наш народ не по своей вине пока отстал по этой части, что для пробуждения его необходимо издавать побольше таких вот газет и журналов».
В конце 1880-х годов братья Рамиевы пытаются издать свою газету. В это время фамилия Рамиевых была уже довольно известной среди предпринимателей России. Но царское правительство отказало и им. Как пишет Галимджан Ибрагимов в книге «Материалы о революционных событиях»

Ә яңарак кына Россия канаты астына кергән «Кавказ татарлары»на андый мөмкинлек бирелә.
Бары тик яңа гасыр башында – 1905 елгы халык күтәрелеше вакыйгаларыннан соң гына – җирле татарларга да матбугат ачу иреге тудырыла. Закир Рәмиевкә «Вакыт» газетасын нәшер итү рөхсәте 1906 елның февралендә бирелә. Ә 1907 елның 13 декабрендә бертуган Рәмиевләр «Шура» журналын нәшер итәргә рөхсәт алалар. Ә бер елдан аларның заманча җиһазландырылган үз басмаханәләре эшли башлый. 1908 елның декабрендә ул басмаханәдә беренче китап – Риза хәзрәт Фәхретдиновның «Мөхәммәд» дигән китабы басылып чыга. Ризаэддин хәзрәтнең бертуган Рәмиевләр иганәчелегендә басылып чыккан 35 китабы булганлыгын, шуларның бер өлешенең әлеге «Вакыт» басмаханәсендә дөнья күргәнлеген дә әйтеп үтик. 1909 елның гыйнварыннан 1918 елның февраль урталарына кадәр монда мәктәп-мәдрәсәләр өчен дәреслекләр, уку әсбаплары, татар, казах телләрендә күп санда әдәби һәм җәмгыяви эчтәлекле китаплар да нәшер ителгән. Ә 1918 елның февраленнән анда яңа хакимиятнең беренче матбугаты чыга башлаячак.

(1922), в 1890-е годы с такой же просьбой обращались в правительство казый (один из трех высших чиновников) муфтията в Уфе Рашит Ибрагимов, Хади Максуди из Казани и братья Шакир и Закир Рамиевы. И всем им было отказано в издании газеты на татарском языке. А недавно вошедшим в состав России «кавказским татарам» такие разрешения были выданы.
Только в начале нового века, после народного восстания 1905 года и местным татарам разрешили издавать газеты и журналы. Разрешение на издание газеты «Вакыт» Закир Рамиев получил в феврале 1906 года. А 13 декабря 1907 года было выдано свидетельство губернатора на издание журнала «Шура». В том же году они получили документы на открытие своей типографии. И в декабре 1908 года в хорошо оснащенной типографии Рамиевых «Вакыт» была издана первая книга «Мухаммед» («Мөхәммәд») – один из 35 трудов богослова, историка и писателя Ризы Фахретдинова, увидевших свет при содействии этих братьев. С января 1909 года до середины февраля 1918 года издательство «Вакыт» выпустит множество учебников для школ и медресе, газет и журналов, исторических и литературных книг на татарском, казахском языках. А с февраля 1918 года там же будут печататься первые издания новой власти.



*Жиргән авылының хәзерге күренеше*
*Современный вид села Зирган*

Татарлыктан татар
һич гарь итәрме,
Кеше үз исмене
инкяр итәрме.

Татарин от татарина не отречётся,
Татарин именем татарским наречётся.



*Дәрдемәнд. Рәссамы Айдар Хисамов*
*Дэрдменд. Художник Айдар Хисамов*

# Шагыйрь Дәрдемәнд

# Поэт Дэрдменд

Закир Рәмиев Төркиядә вакытта кулына каләм алып, иҗат эше белән шөгыльләнә башлаган, «Дәрдемәнд» тәхәллүсен дә шул чорда кабул иткән, дип фаразлана. Әмма аның шигырьләре XX гасыр кергәндә генә басыла башлый. Әдипнең милли-фәлсәфи эчтәлекле, тирән фикерле, халыкчан рухлы шигырьләре укучы күңелен бик тиз җәлеп итә. Чөнки аның иҗатына хас сыйфатларның берсе – үз халкының киләчәк язмышын кайгырту. Ләкин 1917 ел вакыйгаларыннан соң Закир Рәмиев-Дәрдемәнднең иҗаты һәм җәмәгать өлкәсендәге файдалы эшчәнлеге ярты гасырга якын дәвердә үз халкыннан читләштерелеп тора.
Еллар үтеп, кеше эшчәнлегенә сыйнфый караштан торып бәя бирү заманнары арттарак калган саен, Әдипнең шигърият өлкәсендәге казанышлары, фидакярлеге һәм күпкырлы җәмәгать эшчәнлегенең кыйммәтен бәяләү һаман арта бара.

* * *

Атам-анам йорты өчен
Булса мең җаным фида,
Туган-үскән җирем өчен
Соң тамчы каным фида.

* * *

Матур гөлләргә бул былбыл,
нәзакәт багына сакчы!

* * *

Татарлыктан татар һич гарь итәрме,
Кеше үз исмене инкяр итәрме.
Татарлыкта татар угълы татармын,

Предполагают, что стремление Закира Рамиева к творческой деятельности созрело в годы его пребывания в Турции. Там же он принял псевдоним «Дэрдменд», что в переводе означает «сострадающий». Произведения Дэрдменда начали появляться в периодической печати в начале XX века. Окрашенные национальным колоритом и философским взглядом на жизнь стихи поэта сразу же привлекли внимание читателей. Но после событий 1917 года творчество и другие общественно полезные деяния Закира Рамиева-Дэрдменда были надолго забыты. Значение его философской поэзии и вклад в культурно-духовное развитие своего народа все ярче проявляются в последние десятилетия – по мере освобождения литературоведения от классовых штампов и предрассудков предыдущих десятилетий.

* * *

За материнский, отцовский кров
И тысячу жизней отдать не жаль;
За край, в котором родился и рос,
Последней капли крови – не жаль.

* * *

Будь настоящим соловьем для настоящих
цветов в саду искусства и любви!

* * *

Татарин я. Татарства не стыжусь,
От имени отцов не откажусь.
Татарин я, татарин родовой.
Кто скажет «нет» – рискует головой!

Татар түгел димә – башың ватармын!
Әдәбият фәнендә «Дәрдемәнднең тәүге шигырьләре 1902–1903 елларда Кырымда чыгучы «Тәрҗеман» газетасында күренә башлый» дип әйтелә. Ризаэддин Фәхретдиннең 1903 елда нәшер ителгән «Әсма, яки Гамәл вә җәза» әсәрендә, авторы күрсәтелмичә, аның «Үткән көннәр» шигыре басылып чыга. Ул елларда Уфада яшәгән «Әсма…» әсәре авторына әлеге шигырьнең кайчан һәм ничек килеп кергәнлеге ачыкланмаган. «Үткән көннәр» дә, бәлки, «Тәрҗеман»да яисә Кавказда нәшер ителүче башка бер газетада яки Кырым татары Ильяс Браганскийның Санкт-Петербургтагы типографиясендә нәшер ителгән берәр җыентыкта чыккан булгандыр.
«Каргалының Сибгатулла хаҗига мәктүб» шигырен, Дәрдемәнднең ел ярым чамасы Төркиядә яшәп кайтканнан соң, 1884 елда Юлык авылында тәмамлаганлыгы мәгълүм. Соңрак ул шигырь «Шура» журналының 1908 елгы 1 нче санында һәм Дәрдемәнд вафатыннан соң чыккан «Дәрдемәнд әсәрләре» (1929) белән «Исә җилләр» (1980) китапларында нәшер ителгән.
Шагыйрьнең иҗатын барлауга зур өлеш керткән, 1950 елларда аның варислары белән аралашкан галим Мөхәммәт ага Гайнуллин «Совет әдәбияты» журналында чыккан хезмәтендә (1959): «Дәрдемәнднең Истанбулда чакта һәм аннан кайткач…



Литературовед Мухаммед Гайнуллин полагает, что «первые стихи Дэрдменда начали печататься в 1902–1903 годах в газете «Тарджеман», издававшейся в Крыму И. Гаспринским». И в своем литературном произведении «Әсма…» («Асма…», 1903) Ризаэддин Фахретдинов привел его стихотворение «Үткән көннәр» («Прошедшие дни»), не зная еще автора. Это первое произведение Дэрдменда, изданное на родине. Стихотворение не датировано.
Каким путем оно попало к жившему в то время в городе Уфе автору данной повести – осталось невыясненным. Может быть, стихотворение до этого тоже было напечатано в одной из газет, выходивших за пределами Поволжья и Урала – на Кавказе, например, или в одном изсборников,издававшихся в типографии крымчанина Ильяса Браганского в Санкт-Петербурге.
Известно, что стихотворение «Каргалының Сибгатулла хаҗига мәктүб» («Письмо каргалинскому хаджи Сибгатулле») было завершено Дэрдмендом в 1884 году в селе Юлук и посвящено недавно умершему известному поэту и религиозному деятелю Сибгатулле Салихову. Эта дата считается началом поэтического творчества Дэрдменда. Потом стихотворение было напечатано в 1-м номере журнала «Шура» за 1908 год и изданных в годы советской власти книгах поэта «Дәрдемәнд әсәрләре» («Произведения Дэрдменда», 1929) и «Исә җилләр» («Веют ветры», 1980).

*Шагыйрьнең үзе исән чагында дөнья күргән бердәнбер китабы. «Балалар өчен вак хикәяләр».*
*Төзүчесе Дәрдемәнд. «Вакыт» матбагасы. Оренбург. 1910*
*Единственное прижизненное издание поэта. «Маленькие рассказы для детей».*
*Составитель Дэрдменд. Издательство «Вакыт». Оренбург. 1910*

төрекчәдән татарчага берничә җиңел хикәя тәрҗемә иткәнлеге, шигырьләр яза башлавы турында… мәгълүматлар бар», – дип белдерә. Исмәгыйль Рәмиев тә: «Аның берничә тәрҗемә хикәясе «Шура»да да басылган иде», – дип яза. Дөреслектә, «Шура» журналында Дәрдемәнд тәрҗемә иткән өч проза әсәре басылган икән. Миркасыйм Госманов белән Раиф Мәрданов туплап чыгарган «Шура» журналының библиографик күрсәткече» китабында (2014) алар һәм Дәрдемәнднең бу мәҗмуга битләрендә урын алган барлык шигырьләренең исемнәре теркәлгән. Ә әлеге өч тәрҗемә чәчмә әсәрнең берсе, шактый зур күләмле булып, «Шура»ның 1909 елгы өч санында басылып чыккан. Соңгы тәрҗемә әсәрдән кала барлык хикәя һәм нәсерләр, шул исәптән автор тарафыннан балалар өчен махсус язылганнары да, Дәрдемәнднең үз гомерендә нәшер иткән бердәнбер китабында – «Балалар өчен вак хикәяләр»дә (1910, «Вакыт» басмаханәсе, Оренбург) урын алганнар.
1895 елдан бертуган Рәмиевләр белән аралашкан Фатих Кәрими (1870–1937) хәбәр итүенчә, Төркиядә чакта Дәрдемәнд европача яшәү рәвешен чагылдырган бер француз романын да тәрҗемә иткән була. Төрекчә нөсхәдән күчерә, әлбәттә. Төрекләр ул вакытта европалылар әдәбиятын еш тәрҗемә иткәннәр. Әмма Дәрдемәнд иленә кайткач һәм шул тәрҗемәне кабат-кабат күздән кичереп чыккач, «безнең мохиткә бу әсәр бармый» дип ертып ташлый.
Закир Рәмиев шушы башлангыч иҗат чорында үзенә «Дәрдемәнд» дигән тәхәллүс тә сайлый, дип алдарак әйткән идек.
Ә инде 1905 ел ахырыннан соң шагыйрьнең иҗат үрнәкләре әүвәл «Казан мөхбире», аннары «Вакыт» газеталарында, «Шура» журналында әледән-әле күренә башлый. «Дәрдемәнд» тәхәллүсе белән кемнең иҗат иткәнлеге ачык билгеле булмаган көннәрдән үк аның шигырьләре укучы күңелен җәлеп

Литературовед Мухаммед Гайнуллин, с 1950-х годов встречавшийся с некоторыми наследниками поэта, в изданном в журнале «Совет әдәбияты» («Советская литература», 1959) труде написал о том, что Закир Рамиев в период нахождения в Турции и после возвращения оттуда, кроме сочинения своих пробных стихотворений, был занят и переводом отдельных прозаических произведений. Им тогда с турецкого языка были переведены небольшие рассказы и новеллы, часть которых потом вошла в изданную им в 1910 году книгу «Балалар өчен вак хикәяләр» («Маленькие рассказы для детей», издательство «Вакыт»). По данным И. Рамиева, еще один из переведенных им тогда рассказов напечатан на страницах трех номеров журнала «Шура», в данную книгу не помещен. И в книге, изданной Миркасымом Усмановым и Раифом Мардановым в 2014 году, «Шура» журналының библиографик күрсәткече» («Библиографический указатель журнала «Шура») указаны три прозаических произведения, переведенные Дэрдмендом. В той же книге названы все стихотворения поэта, изданные в этом журнале.
По сообщению же Фатиха Карими (1870–1937), с 1895 года близко общавшегося с семьями Рамиевых, находясь в Турции, поэт приступал еще и к переводу какого-то романа французского автора. Естественно, переведенного на турецкий язык. В Турции тогда произведения европейских авторов издавались часто. И после возвращения оттуда Дэрдменд несколько раз брал в руки эту рукопись. А потом, решив, что содержание романа не соответствует укладу жизни своих соотечественников, разорвал и выбросил ее.
Многие предполагают, что псевдоним «Дэрдменд» Закир Рамиев начал применять именно с первых дней творчества.
С конца 1905 года стихи поэта периодически

итә, телгә керә. Мисал итеп, шул чорның әдәбият галиме Габдерахман Сәгъдинең «Шура»да (1911) басылган «Шагыйрьләр һәм шигырьләр» хезмәтен искә төшерик. Шагыйрьнең үзенчәлекле иҗатына уңай бәя биргәннән соң, ул: «Дәрдемәнднең кем булуы безгә мәгълүм түгел», – дип тә өстәп куйган. Яңарак кына Төркиядән кайтып, чит-ят җирләрдә укытып йөргән Г. Сәгъди түгел, бер үк мохиттә яшәүче иҗат кешеләренең дә күпчелеге байтак вакыт «Дәрдемәнд» тәхәллүсе белән язучының кем булуын белмәгәннәр. Ә шагыйрьнең хикмәтле сүз-әйтемгә, сәнгати төгәл сурәтләүгә бай шигырьләре белән кызыксыну көннән-көн арта барган. Мәгәр шигырь җыентыкларын кат-кат чыгару мөмкинлегенә ия кеше булса да, үзе исән вакытта Дәрдемәнд аларны бер китапка туплап чыгармаган. Дәрдемәнд иҗатында тормышка милләт язмышы аша караш – төп сыйфатларның берсе. Аның күпчелек шигырьләре берничә строфадан гына тора. Ләкин шул уналты-егерме юллык әсәрдә кешегә ил, Ватан, милләт язмышын күз алдына китерү хас. Милләте турында уйлануларын ачык итеп әйтмәгән хәлдә дә, Дәрдемәнднең әсәрләрен укыганнан соң, күңелдә шул хис яңара. Ирексездән милләтеңнең үткәне һәм киләчәге турында уйлана башлыйсың. Аларда кеше язмышы да, борынгы тарих рухы да, киләчәк өмет нурлары да җемелдәп күз алдыннан үтәләр. Җиңел укылышлы теле, төгәл

начали выходить в газетах-журналах и на родном языке автора. (А «Тарджеман» издавался на крымско-татарском – более близком к турецкому.) В газете «Казан мөхбире» («Вестник Казани»), с осени 1905 года заявившей о себе, под псевдонимом «Дэрдменд» было напечатано первое стихотворение поэта на родном языке. Потом его поэтические произведения стали регулярно печататься на страницах своих изданий – газеты «Вакыт» и журнала «Шура». В периодической печати творчество «нового, доселе неизвестного поэта» одним из первых оценил будущий литературовед Габдрахман Сагди. В 1911 году в том же журнале «Шура» вышла его статья «Шагыйрьләр һәм шигырьләр» («Поэты и стихотворения»). Г. Сагди, оценив своеобразие стихотворений Закира Рамиева, свое выступление завершает сообщением, что он лично пока не знаком с поэтом по имени Дэрдменд. И люди с ближайшего окружения поэта сообщают, что тогда многие не предполагали, что под этим псевдонимом пишет свои произведения известный всем «господин Закир Рамиев». В то же время после каждого опубликования очередного его произведения интерес к личности поэта возрастал. А автор продолжал скромничать. Не любил он популярности. И потому, видимо, имея хорошо оснащенную типографию,




*«Кораб» (шигырь тулысы белән). Рәссамы Нәҗип Нәккаш*
*«Корабль» (стихотворение полностью). Художник Наджип Наккаш*

сыйфатлаулары, куәтле фикере ярдәмендә Дәрдемәнд өч-дүрт кенә җөмләле шигырьдә дә гомумиләштерү тирәнлегенә ирешә. Моның классик мисалы итеп «Кораб» шигырен алырга була.
«Дәрдемәнд татар әдәбияты дөньясына сигезенче елның башында куәтле тавышлар илә шауламакта булган диңгезнең дулкыннарын ярып барган могъҗиз «Кораб» өстендә заһир (пәйда) булды… «Менә татар сәнгате әдәбиясе күгендә яңа бер йолдыз заһир булды», – димешләрдер. Чөнки аңарда, чынлап та, яңа рух сизелә – ниндидер әдәби мәдәнилек, чын каләм сәнгате, матур өслүб, җыйнак вә кыска тәкъбирләр… Гүя ул ниндидер бер сихерле куәт белән әйтергә теләгән мәгънәсен йөрәгеңә турыдан-туры яра да сала… Алыйк «Кораб»ны, «Без»не, «Өмидләр», «Бүзләрем мана алмадым», «Бәллү»не… «Бәллү», югарыда сөйләп килгән һәммә кәмалләрне (камиллекне) үзендә җыйдыгы кебек, өслүбенең матурлыгы, гаҗәеп аһәңе илә дә бөтен матбугатымызда беренче урынны аладыр», – дип язган иде Галимҗан Ибраһимов 1913 елда дөнья күргән «Татар шагыйрьләре» очеркында.
Кайчан, кайларда өйрәнгән, ничек ирешкән шагыйрь андый осталыкка?
Казан ханлыгы чоры морзаларына бәйле шәҗәрәсе булуына карамастан, ул гап-


(قارعالينك سيبعەتوللا حاجيگە مەكتوب)
(عوسمانلى لەهجەسندە) (*)

سەعادەت واقتى بر فورسات زامانى
بولنب مەسكەندە بر تەنها مەكانى
بوراده‌رلە سەنى تەزكير ئيدەردك
سەنك ئوسافنگن تەكرير ئيدەردك
پيامبەر حەزرەتكدەن بيتدى ناگە
عينايەت نامەكز دەن ئيتدى ئاگە
ئوقب ئەووەلدە مازمونى حيتابى
ئاجب هەم دەست حورمەتلە كيتابى
دەروننده عەجەب ئەشعارى كوردك
نە ئەشعار شيعرلەر گولزارى كوردك،
شو نيسبەت ئوزرەدر مۆعجيز كەلامى
ديلى شەبحون ئيدەر هەر بر پيامى
ئەدايى ديلنوازى شاعيرانە
كى تەعريف ئەيلەمەك گەلمەز ليسانە
فەساحەت گوللەرندر هەر بەيانى
بەلاغەت شەبنەمى مەعلو ميانى
نەشەككور ئەيلەرز بز جان وەديلدەن
كى ئالدق بەهرە ئول جەمعى جەميلدەن
ئچب عيرفان سەبوسندەن مەدامى
شەرابى ئەيلەدك حەز (حظ) تەمامى
ويربدر فەحر ئوچن حەلقە حوداوەند
سەنى ئى شاعيرى فيردەوسى ماننەد
فەساحەت گەنجى گويا عەز وە جەلدەن
سەگا تەحسيس ئولنمشدر ئەزەلدەن
بوتن ئارزولارك هەب وار ئولسن
دەلەك هەر ئمرنك نايبار ئولسن!
ئەفەندم، حەزرەتنك عاجيزانە
بو دەم كورندردگم بو بر فەسانە
تيلادى كيلكى عەبد عاجزيدر
(تلاد كلك عبد عاجزيدر)
حسولى حەرسن فيكرى ناچيزيدر
(حصول حرث فكر ناچيزيدر).
نقوش عيلمدەن ظالى مەئەلى
دانا ئولماز ئەگەر ديرسەم ميسالى
هەنوز گەلمش جيرمانە بر سابيدر
ئەديبلەر دەرگە هەندە بر غەبيدر.
حيجابندان دوشب ئەفعان وەزارە
قەبول ئيتمەزدى كم دەرگاهە وارە
ولاكين ئولمايوب ئيل رەسميدە شان
(كى عادەتدر سابيلار گورمەك ئوستاز)
عەزيمەت ئەيلەدى سوز گرازلە
سەنك دەرگاهگا عەجزو نيازلە
سولار ئيتمەزسە دەرگە لوتف عالى
ساباوات مەعدەنە ئيرمش نيهالى

*) بو شيعر تورندا مەجموعەنك باشندا توزوچى نارافندان كرش سوز تورندا يازلعان باش سوزنك ئازاقنى بوللارن قارا.

не выпустил ни одного сборника своих трудов, кроме ранее указанной тоненькой книжонки для детей.
Характерной особенностью поэзии Дэрдменда является философский взгляд на жизнь. Большинство его стихотворений состоят всего из нескольких строк. Однако в этих шестнадцати–двадцатистрочных произведениях перед читателем предстает судьба народа, родины. Дэрдменд отличается от многих поэтов-современников высочайшим уровнем философско-образного мышления. И даже если он не говорит открыто о том, что занимает его мысли и чувства, после чтения многих его произведений невольно задумываешься о прошлом и будущем своего народа. Перед глазами проходят и судьба отдельного человека, и страницы древней истории.
Произведениям Дэрдменда свойственны особая образность, изящество слога, меткость сравнений. Поэт достигает глубины обобщения даже в стихах, состоящих из двух-трех предложений. Классический тому пример – этапное стихотворение «Кораб» («Корабль»).
«Дэрдменд появился в восьмом году в мире татарской литературы на удивительном своем «Корабле», рассекающем волны бушующего моря… Вокруг сразу заговорили:

*Закир Рәмиевнең ул еллар иҗат үрнәге булып 1884 елда төрекчә сүзләр кулланып язылган «Каргалы шагыйре мәрхүм Сибгатулла хаҗига язган бер мәктүбә» исемле шигъри хаты калган. Әлеге шигырьнең типографик басмасы*
*«Письмо Сибгатулле хаджи из Каргалы», образец поэтического творчества Закира Рамиева тех лет с использованием турецкой лексики 1884 года. Типографское издание этого стихотворения*

гади бер татар авылында туган, гадәти татар мәктәп-мәдрәсәләрендә белем алган. Гади халык арасында яшәп, аның моң-зарын күкрәк сөте белән үк күңеленә сеңдергән. Буй җиткән, яшәгән төбәге дә бик үзенчәлекле – татар, башкорт, казах ише кардәш халыкларның укмашып көн күргән, тел-лөгать алмашкан урыны – Урал-тауның көньяк-көнчыгыш төбәге. Шагыйрь иҗатында алар да чагылыш табачак: башкортларның моңлы озын җыр-кобаерлары, казах акыннарының кыллы кубыз, думбра чиртә-чиртә тапкыр сүз әйтеш бәйгеләре йогынтысы Дәрдемәнд шигырьләрендә бик ачык сиземләнә. Дәрдемәнднең 1929 елда чыккан китабының кереш өлешендә, аның иҗатына багышланган мәкаләсендә Фатих Кәрими мондый фактлар да китерә: «Ул Шәрык дөньясындагы Газзали, Фәхерразый, Ибне Рөшд, Гомәр Хәйям, Сәгъди, Нәваи, Фөзули, Габделхак Хәмит, Әкрам, Тәүфикъ Риза, Габдулла Җәүдәтләр иҗаты белән таныш булган шикелле, Гареб дөньясындагы Гегель, Кант, Вольтер, Лютер, Шиллер, Һейне… Толстой, Пушкин, Горький вә башкалар иҗаты белән дә бик төпле таныш иде», – ди.

Әйе, Дәрдемәнд югарыда искә алынган күпчелек классик затларның иҗаты белән күпмедер дәрәҗәдә таныш булган. Кайберләренең шигырьләрен иркенрәк рәвештә тәрҗемә дә иткән. Яисә алар кулланган сюжет-мотивны үзенчәрәк итеп язган.



«Татарлыктан татар һич гарь итәрме...». Рәссамы Нәҗип Нәккаш
«Татарин от татарина не отречется...». Художник Наджип Наккаш

«На литературном небе татарского искусства взошла новая звезда». Потому что действительно все почувствовали новый дух – особую литературную культуру, мастерское владение пером, изящный стиль, афористичность… Возьмем, к примеру, его стихи «Корабль», «Мы», «Надежды», «Не сумел я окропить савана», «Колыбельная»… Например, «Колыбельная», вобравшая в себя все эти совершенства, занимает первое место… красотой стиля и удивительной гармонией», – писал Галимджан Ибрагимов в 1913 году в объемном очерке-исследовании «Татар шагыйрьләре» («Татарские поэты»). Где истоки творчества поэта Дэрдменда? Откуда черпает он духовные силы? Несмотря на родословную, берущую начало от мурз периода Казанского ханства, он – уроженец обыкновенного татарского села, учился в обычных для того времени татарских учебных заведениях. Живя среди простого люда, он с детства был знаком с болью и тревогами своего народа. Юго-восточные отроги Уральских гор – это места, где бок о бок жили родственные народы – татары, башкиры, казахи. Дэрдменду с детства были знакомы башкирские протяжные песни-кубаиры, он видел состязания казахских акынов, которые, подыгрывая на домбре и скрипках-кубызах, экспромтом слагали свои стихи. Все это позже найдет отражение и в творчестве поэта Дэрдменда.

Үз бәяләмәсен язганда, Г. Ибраһимов белән Ф. Кәрими фикерләрен икенче бер әдип һәм галим Габделбари Баттал да куәтли. 1925 елда Төркиядә басылган «Казан төрекләре» китабында ул: «Дәрдемәнд – мәгънә ягыннан фикерче бер шагыйрь… Шигырь төзелешендә тиешенчә хәбәрдар… аһәңгә, рифмага һәм вәзенгә бик игътибарлы. Һәм, бу яктан караганда, Казан төрки шагыйрьләре арасында иң өстен шагыйрьләрнең берседер. Иске төрки әдәбияты белән дә җитди шөгыльләнгән, Нәваи, Лотфи, Бабур кебек чагатай шагыйрьләренең җыентыкларын игътибар белән укыган булуы да ачык билгеле. Шуңа күрә Дәрдемәнд шагыйрьләр арасында иң белемлесе саналырга хаклы», – дип яза. Ф. Кәрими һәм Г. Баттал язганнар белән танышканнан соң, Рәмиевләр гаиләсендәге тәрбиянең булмышын күз алдына китерәсең. Әйе, бу ике бертуганның анасы Хәнифә Дашкова бик укымышлы булган. Ул балаларын яшьли укырга-язарга өйрәткән. Үзе дә борынгы төрки әдәбиятны да, рус телендә нәшер ителгәнен дә берникадәр үзләштергән булган. Улларын да шул рәвештә тәрбияләгән. Хәер, ул дәвер зыялы морзалар гаиләсендә укымышлылык бик югары бәяләнгән була шул. Риза хәзрәт Фәхретдинов та бер истәлек язмасында: «Шакир Рәми мине беренче танышканда ук Нәваи, Сәгъдиләр шигырьләрен яттан белүе белән үзенә җәлеп итте. Мин генә түгел, бүлмәдәшләрем дә шаккатты шуңа», – ди. Замандашлары шулай олылаган зур шагыйрь, олуг фикер иясе, абруйлы җәмәгать эшлеклесе Закир Рәмиев-Дәрдемәнд исеме 1917 елгы түнтәрелеш вакыйгаларыннан соң күпмедер вакыт күренми тора. Аның үзенчәлекле, нигездә, милли рухлы шигырьләре дистә елдан артыграк басылмый, үзе телгә алынмый диярлек. Ләкин бөтенләй үк «югалмый» ул. 1929 елда аның «Дәрдемәнд әсәрләре» исемендә беренче күләмле җыентыгы дөнья

Ф. Карими во вступлении к первому сборнику стихов поэта 1929 года привел и такие факты: «Он, наряду со знанием творчества классиков Востока Газзали, Фахеррази, Ибн Рушда, Омара Хайяма, Саади, Навои, Фазули, Абдульхака Халита, Акрама, Тауфика Ризы, Абдуллы Джавдата, был также основательно знаком с творчеством крупных представителей западной культуры: Гегеля, Канта, Вольтера, Лютера, Шиллера, Гейне, Пушкина, Толстого, Горького и других».
Он иногда свободно переводил или использовал мотивы того или иного произведения вышеуказанных классиков мировой литературы.
Литератор, историк Габдельбари Баттал (1880–1969) в книге «Казан төрекләре» («Казанские тюрки»), изданной в 1925 году в Турции, так представляет творческие истоки и успехи своего современника: «С точки зрения смысла Дэрдменд – глубоко мыслящий и достаточно начитанный поэт… В должной мере знает строение стиха… Очень внимателен к созвучности, рифме, размеру. Он серьезно был ознакомлен со средневековой тюркоязычной литературой. Хорошо запомнил суть произведений Навои, Лутфи, Бабура. И с этой стороны он – один из наилучших казанских тюркоязычных поэтов».
В этих высказываниях Ф. Карими и Г. Баттала можно почувствовать суть воспитания в семье Рамиевых. Их мать Ханифа Дашкова была начитанной женщиной. Она с малолетства приучила детей к чтению. И сама хорошо знала как восточную, так и европейскую литературу. В семьях многих мурз образование было первоочередной задачей. И тому примеров много.
И Ризаэддин Фахретдинов в одном из своих воспоминаний с восхищением пишет о первой ветрече с «Шакир Рами». Упоминает, что Шакир по ходу разговора прочел наизусть стихи Навои и Сагъди.



*Дәрдемәнд портреты. Рәссамы Абрек Абзгилдин*
*Портрет Дэрдменда. Художник Абрек Абзгильдин*

күрә. Ул җыентыкны туплаучы-төзүче, аерым искәрмәләр авторы – Исмәгыйль Рәмиев (1895–1969), тәфсилле кереш сүз авторы әдип Фатих Кәрими була. Ә Дәрдемәнд шигырьләрен туплап чыгару кирәклеген ул елларда Галимҗан Ибраһимов кузгатты, дип әйтер иде И. Рәмиев.
Ләкин киң җәмәгатьчелек ул вакытта Дәрдемәнднең китабы чыгуга җитди игътибар бирә алмый. Ул чорда әле аны искә алу сәяси хата санала. Әдәбият галимнәре билгеләп үткәнчә, ул елларда әле «буржуй Дәрдемәнд» иҗатына карата гына түгел, Тукай һәм чордашлары иҗатына карата да ниндидер тискәре караш яшәгән. Шул чор матбугатында Тукайны «вак буржуаз шагыйрь», Фатих Әмирханны «эре буржуаз

Современники Дэрдменда высоко ценили его творчество, являющееся результатом юношеской начитанности и упорства поэта. Однако послереволюционные события отодвинули его имя в сторону. Один из наилучших поэтов, мыслитель, известный общественный деятель и издатель Закир Рамиев – Дэрдменд как бы сошел со сцены татарской литературы и культуры. Его поэзия, мастерски отшлифованная и имевшая яркие национальные черты, оказалась на некоторое время как бы не востребованой и забытой. Только в 1929 году увидел свет первый сборник его литературных трудов под названием «Дәрдемәнд әсәрләре» («Произведения Дэрдменда»). Но широкая общественность тогда не обратила должного внимания на выход этой книги… Классовые взгляды интеллигенции тогда запрещали думать о творчестве «поэта-буржуя».
В те годы не только его творчество, даже произведения Габдуллы Тукая, Фатиха Амирхана некоторые считали творением «буржуазным» и писали об этом открыто. Указанный сборник произведений поэта подготовили к изданию составитель и автор комментариев И. Рамиев. Предисловие написал Ф. Карими. По сообщению И. Рамиева, инициатором издания данного сборника поэзии Дэрдменда был Г. Ибрагимов.
Новые попытки вернуть народу поэзию Дэрдменда были сделаны в конце 40-х годов. В изданную в 1947 году хрестоматию по литературе для студентов высших учебных заведений было включено несколько стихов поэта. В ноябрьском журнале «Совет әдәбияты» 1959 года вышла большая статья, посвященная жизни и творческой деятельности поэта. Как сообщалась ранее, автором был доктор филологических наук, профессор Мухаммед-ага Гайнуллин. Это первое объективное исследование творчества поэта и более-

язучы» дип теркәү очраклары булган. Дәрдемәнд шигъриятенең кабат үз милләтенә кайтарыла башлавы илленче еллар тирәсенә туры килә. 1947 елда аның берничә шигыре югары уку йортларында укучылар өчен чыгарылган әдәбият дәреслегенә кертелә. Ә 1959 елның декабрендә тууының йөзьеллыгы тантаналы рәвештә билгеләп үтелә. Тел, әдәбият һәм тарих институты тырышлыгы белән уздырылган ул тантанада байтак кына татар зыялылары катнаша. Шул юбилей алдыннан гына Дәрдемәнднең «Сайланма әсәрләр»е басылып чыга («Сайланма әсәрләр», кереш мәкалә авторы Мөхәммәт Гайнуллин, төзүчесе Исмәгыйль Рәмиев). Тагын ун елдан соң Дәрдемәнд шигырьләренең русчага тәрҗемә китабы нәшер ителә («Стихи» // төз.: Сибгат Хәким, Ренат Харис. – Казан, 1970). Ә 1980 елда шагыйрьнең татарча өченче шигырь китабын – «Исә җилләр»не – халык шагыйре Сибгат Хәким (кереш мәкалә авторы) белән әдип Рәис Даутов (төзүче һәм искәрмәләр авторы) әзерләп чыгардылар… 1999 елда ике телдә «Агарган кыл» – «Поседевшая струна» исемле сайланма шигырь җыентыгы нәшер ителде (төзүче һәм кереш сүз авторы Ренат Харис). «Татар поэзиясе антологиясе» (татарча 1956, 1992, русча 1957 еллар) һәм «Татар балалар поэзиясе антологиясе» (1980) томнарында, «Бөтендөнья әдәбияты китапханәсе» сериясенең 38 (102) томында да (Мәскәү, 1977) Дәрдемәнд шигъриятенең асыл үрнәкләре урын алган. Бу елларда төрле матбугат битләрендә дә («Казан утлары», «Азат хатын» журнallары һ. б.) Дәрдемәнд эшчәнлегенә һәм иҗатына багышланган күпсанлы хезмәтләр басылды. Аерым әсәрләре күренгәләде.

Шул рәвешле, Дәрдемәнднең «корыч кебек өслүбле, тирән мәгънәле, музыкаль аһәңле» (Г. Ибраһимов бәяләмәсе) тиңсез шигъри иҗаты татар әдәбияты дөньясында үзенә тиешле бәяне алды, шагыйрь исеме олуг тиңдәшләре янәшәсендә беркетелде.

менее достоверное описание биографии Закира Рамиева. В конце ноября того же года прошли торжества по случаю столетия со дня рождения поэта, организованные Институтом языка, литературы и истории. К юбилею был издан сборник «Сайланма әсәрләр» Дэрдменда («Избранные произведения», 1959, автор вступительной статьи М. Гайнуллин, составитель И. Рамиев). Десять лет спустя вышел сборник стихов Дэрдменда и на русском языке («Стихи», 1970, составители: Сибгат Хаким, Ренат Харис). А еще через десять лет увидела свет книга его избранной поэзии «Исә җилләр» («Веют ветры», 1980, автор вступительного слова Сибгат Хаким; составитель Раис Даутов). В 1999 году на татарском и русском языках был издан сборник избранных произведений поэта «Агарган кыл» – «Поседевшая струна» (автор предисловия и составитель – народный поэт Татарстана Ренат Харис). Лучшие образцы поэзии Дэрдменда вошли также в «Антологию татарской поэзии» (в 1956 и 1992 годах – на татарском, а в 1957 году – на русском языках), «Антологию татарской детской поэзии» (1980, на татарском языке) и в 38-й (102) том серии «Библиотека всемирной литературы» (Москва, 1977). В те же годы в журналах «Казан утлары» («Огни Казани»), «Азат хатын» («Свободная женщина») и на страницах иных периодических изданий печатались отдельные его стихи, а также статьи, посвященные личности и творчеству поэта.

Таким образом, произведения мастерски владевшего пером и глубоко мыслящего поэта-философа с «изящным стилем» вновь вернулись к своим почитателям. Поэзия Дэрдменда постепенно завоевывала достойное место в новой среде деятелей татарской литературы и народа.

Гасырлар кичте китте...
кичте еллар!
Нәбиләр, падишаһлар
Сөрде дәүран...

*Столетия истекли...*
*Эпохи миновали.*
*Пророки, падишахи*
*отошли.*



*Тайсуган авылы*
*Село Тайсуган*

# Шагыйрьнең туган-үскән җире. Морза Рәмиевләр нәселе

# Родина поэта и род мурз Рамиевых

Мөхәммәтзакир Мөхәммәтсадыйк улы Рәмиев 1859 елның 23 ноябрендә Җиргән авылында сәүдәгәр гаиләсендә дөньяга килә. Бабалары Исмәгыйль (?–1801) белән Габделкәрим (?–1851) чыгышы ягыннан Зәй елгасы буендагы Тайсуган авылыннан була. Бу авыл хәзер Татарстанның Әлмәт районына керә. Ш. Мәрҗани хәзрәтләре хәбәр итүенчә, 1730 еллардан Тайсуган авылында мәдрәсә булган. Габделкәрим шул мәдрәсәдә укыган. Һәм, әтисе артыннан Агыйдел буйларына күченеп киткәнче, берничә ел күрше авылларның берсендә мулла вазифасын башкарган. Әтисе чакыргач, гаиләсе белән Җиргән авылына күчеп килгән, әтисенең сәүдә эшен үз кулына алып, сәүдәгәр булып киткән.
Башта 1900 елларда нәшер ителгән «Асар» хезмәте томнарының берсендә, аннары «Шура» журналының 1913 елгы 6 нчы санында Р. Фәхретдинов алтын чыгаручы Рәмиев байларның нәсел шәҗәрәсен барлап бастыра. Менә ул Казан ханлыгы дәвереннән башланган нәсел чылбыры: Габделкәрим бине Исмәгыйль бине Рәхимкол бине Урман (Урманай) морза бине Кабкай морза бине Түләй морза бине Колай морза бине Сөләйман морза бине Тимери морза бине Рәми бине Ихсан бине Миргалим. Садыйк хаҗи шул чылбырның унөченче, Шакир белән Закир ундүртенче буыны була.
Бу шәҗәрәдәге «Урман» атамасын И. Рәмиев «Урманай» рәвешендә язылырга тиеш дигән иде. Казан ханлыгы яулап алынгач, нәкъ шул «Урманай морза», йомышлы татар буларак,

Мухаммедзакир Мухаммедсадыкович Рамиев родился 23 ноября 1859 года в селе Зирган в семье потомственного купца. Его предки Исмагил (?–1801) и Абдулкарим (?–1851) были родом из села Тайсуган на реке Зай (ныне входящей в Альметьевский район Татарстана).
В трудах Ш. Марджани упоминается о том, что с 1730-х годов в Тайсугане было медресе. Дед братьев Рамиевых Абдулкарим после окончания этого медресе служил муллой в одном из соседних сел. Потом по просьбе отца переселился в село Зирган и наследовал его купеческое дело.
В 1900-е годы Р. Фахретдинов в одном из томов своего энциклопедического труда «Асар» опубликовал генеалогическое древо Рамиевых. (Это шеджере с некоторыми добавлениями потом было опубликовано в журнале «Шура», в № 6 за 1913 год.) Вот она, родословная, берущая начало с периода Казанского ханства: Абдулкарим, сын Исмагила, сына Рахимкула, сына Урман (Урманай)-мурзы, сына Кабкай-мурзы, сына Тулей-мурзы, сына Кулай-мурзы, сына Сулейман-мурзы, сына Тимери-мурзы, сына Рами, сына Ихсана, сына Миргалима. Мухаммедсадык-хаджи был тринадцатым, а Шакир и Закир Рамиевы – четырнадцатым звеном этой цепочки.
По предположению И. Рамиева, после завоевания Казанского ханства семья мурзы Урманая, как служивого татарина, была переселена к восточной границе государства – в зону рек Зай и Шешма. Потом его потомки, ставшие уже простыми



патша хакимияте тарафыннан Зәй-Чишмә тирәсендәге чик буена җибәрелә, дип язды. Бу нәселдән Агыйдел буена иң элек күченеп утыручы кеше Исмәгыйльнең бертуганы Сәлим Рәмиев (?–1819) була. Эстәрлетамак каласы төзелә башлаган 1770 елларда аны имам вазифасын башкарырга чакырып алалар. Озакламый ул монда ахун итеп билгеләнә. Оныкларыннан да берәү шушында өяз ахуны булган. Ә ике оныгының уллары – шагыйрь Сәгыйть һәм әдип Исмәгыйль Рәмиевләр – татар әдәбиятына вә мәдәниятенә билгеле бер өлеш керткән зыялылар. Сәлим хәзрәт чакыруы буенчадыр, тиздән монда аның бертуганы Исмәгыйль дә килә. Һәм Эстәрлетамактан кырык чакрымдагы Җиргән авылында

«мурзами в лаптях», переселились еще дальше на восток. Первым из этого рода в долину реки Белой переселился родной брат Исмагила – Салим-хазрет (?–1819). В 1770-е годы, когда было начато строительство города Стерлитамак, ему предложили должность имама. Вскоре он был назначен уездным ахуном. Один из его внуков также был здесь уездным ахуном. А два других его правнука – с начала XX века известные поэт Сагит и писатель Исмагил Рамиевы – интеллигенты, внесшие значительный вклад в развитие татарской литературы и культуры.

Вскоре в эти края переселился с семьей и Исмагил-купец. На этом настоял его брат Салим. Исмагил затем обосновался в селе Зирган.

История свидетельствует об одновременном начале строительства будущего города Стерлитамак и села Зирган, входящих сегодня в состав Республики Башкортостан. Село находилось в сорока верстах от Стерлитамака – вверх по реке Белой. Зирган расположен ровно на середине дороги Уфа – Оренбург, вымощенной камнем еще при Екатерине II и имевшей государственное значение. Родившийся и выросший в этом селе писатель советского периода Мирсай Амир так описывает ее в одном из произведений, основанном на воспоминаниях детства: «На этой дороге днем и ночью не умолкали скрип идущих непрерывно повозок с тяжелым грузом и крики обозчиков…». И сегодня на этой дороге поток машин непрерывен.

Природа вокруг деревни Зирган очень богата. Если со стороны известного села Стерлибаш деревню окружали лишь редкие островки рощ, то противоположная сторона за рекой Белой была сплошь покрыта лесом. Рыжеватые бока Зирган-горы поднимались как бы из самой реки. А между деревней и рекой простирался широкий цветущий луг. К концу XIX века в селе было 633 двора.

*Мөхәммәтзакир Рәмиев. XX йөз башы*
*Мухаммадзакир Рамиев. Начало XX века*

урнаша, сәүдә эшенә керешә.
Хәзерге Башкортстан Республикасына кергән Эстәрлетамак белән Җиргәннең бер үк елларда төзелә башлавы тарихта теркәлгән. Җиргән Агыйдел буйлап төшерелүче салларны туплау урыны буларак барлыкка китерелә. Анда тиздән такта яру эше җайга салына, дип яза Башкортстан тарихчылары. Җиргән – дәүләти әһәмияте булган, Әби патша заманында ук таш түшәлгән Уфа – Оренбург юлының кыл уртасында урнашкан зур авыл. Шушы авылда туып үскән Совет чоры әдибе Мирсәй Әмир балачак хатирәләренә нигезләнгән бер әсәрендә: «Аллы-артлы тезелешкән авыр йөкле арбалар шыгырдавы, олаучылар кычкырышуы көн-төн тынып тормас иде анда», – дип тасвир итә.
Җиргән тирәсенең табигате бик бай. Мул печәнле киң болынны ашкын сулы Агыйдел елгасы каймалап тора. Мәгълүм Эстәрлебаш авылы тарафында кыр булса, елганың аргы ягында тоташ урманлык. XIX гасыр азакларында авылда 633 йорт исәпләнгән. Халкының күпчелеге татарлар. Әмма бүген дә анда «урыс урамы», «чуаш очы» кебек атамалар ишетелгәли әле. Бай гаиләләр, нигездә, Эстәрле тарафындагы «мещаннар очы»нда яшәгән. Анда татар һәм рус сәүдәгәрләреннән калган, кызыл кирпечтән төзелгән, еш кына шундый ук кирпеч коймалар белән уратып алынган бай йортлар күп. Туксанынчы елларда шулар арасыннан Дәрдемәнд туган өйне тапмаган идек. Рәмиев фамилияле кешеләр ул авылда ишле генә булса да… Ун еллар элек шулар арасындагы «бай Рәмиевләр утары»н да ачыкладылар. «Ул йорт диварына «Монда шагыйрь Дәрдемәнд туган» дигән хәтер тактасы да элдек» дигән хәбәр 2009 елда матбугатта булды.
Дәрдемәнднең әтисе Мөхәммәтсадыйк Җиргәндә туган. Ризаэддин хәзрәт язмасында аның «1892 сәнәсендә… 63 яшендә вафат итмеше», «Юлык авылы

Большинство населения состояло из татар. Но и сегодня еще сохранены названия некоторых улиц со значением «русская сторона», «чувашская сторона». Купцы, богачи в основном жили на Стерлитамакской стороне села. И сегодня еще там много добротных старых домов из красного кирпича, окруженных аккуратными кирпичными же заборами. Эти дома принадлежали как русским, так и татарским «богачам». В 1994 году в селе проживало несколько семей с фамилиями Рамиев. Но никто тогда не мог указать нам дом, где родился Дэрдменд. «В советское время запрещали вспоминать их. Боялись», – говорили они. Лет через десять из этого села пришло сообщение, что «усадьба и дом купцов Рамиевых найдены». А к 150-летию со дня рождения Дэрдменда в 2009 году на стене этого дома была установлена мемориальная доска с указанием, что здесь



*З. Рәмиевнең җәмәгате Мәхүбҗамал. Оренбург, 1905*
*Супруга З. Рамиева Махубджамал. Оренбург, 1905*



зиратында җирләнмеше» күрсәтелгән. Димәк, ул 1828/1829 еллар арасында туган. 1850 елның мартында өйләнгән. Хатыны Хәнифә – шул ук Эстәрлетамак өязенең Яуш авылы морзасы Әлмөхәммәт Дашков кызы. «Ул 1825 елның соңгы көннәрендә туган вә 1896 сәнәсе март башында, «Солтанский» приискында вафат булып, Юлык авылы зиратында дәфен ителмештер» диелә шәҗәрәдә. Юлык зиратында бүген икесенең дә кабер ташлары саклана. Әлмөхәммәт белән Әминә Дашкова варислары шәҗәрәсендә Садыйк белән Хәнифәнең биш баласы исеме теркәлгән. Анда, Шакир (1857–1912) һәм Закирдан (1859–1921) тыш, Камилә, Гомәр, Галихәйдәр исемнәре дә китерелә. Мөгаен, Шакирдан иртәрәк туган ике бала, бик яшьли гүр иясе булып, Җиргәндә җирләнгәндер. Ә Юлык авылы зиратының «Рәми байлар» почмагында тагын бер истәлек ташы бар. Кар, яңгыр әләгеп укымаслык хәлгә китерелгән таш язмада авылның яшь мулласы анда «Гали» сүзен таныды кебек. Ул таш иясе дә бик иртә үлгән бугай. Шуңа күрәдерме, соңгы өч исем бертуган Рәмиевләргә багышланган язмаларда очрамый диярлек. Юлык зиратында башкалары белән бер үк тирәдә

родился поэт Дэрдменд.
Отец Дэрдменда Мухаммедсадык Рамиев родился в Зиргане. А умер Садык-хаджи в возрасте 63 лет и был похоронен в селе последнего проживания – Юлуке. Значит, он родился между 1828–1829 годами. За год до своей смерти отец его поженил на богатой, славившейся своей образованностью мурзихе Ханифе Дашковой. Семья купца Альмухаммеда Дашкова, как и многие мурзы, лишенные статуса дворянина средней руки, жила в селе Яуш того же Стерлитамакского уезда. Свадьба молодых произошла в марте 1850 года. По данным Р. Фахретдинова, Ханифа «родилась в декабре 1825 и смерть ее достигла на прииске Султанской в марте 1896 года. Похоронена она также на кладбище села Юлук, рядом с мужем». По данным родословной Дашковых, у них было пятеро детей. Риза-хазрет называет только двоих – Шакира (1857–1912) и Закира. Видимо, двое из них, родившиеся до Шакира, – Камиля и Гумер умерли еще в младенчестве и похоронены на кладбище села Зирган. А могила третьего, видимо, также умершего младенцем Галихайдара, может находиться на территории любого из двадцати приисков Садык-бая. В центре Юлукского кладбища имеются еще два надгробных камня. Один из них установлен



*Шагыйрьнең ата-анасы Юлык зиратында җирләнгән. Сулда – атасы Мөхәммәтсадыйк Рәмиевнең, уңда – анасы Хәнифәнең кабер ташлары*
*Родители поэта похоронены на кладбище Юлука. Надмогильные камни: слева – отца Мухаммедсадыка Рамиева, справа – матери Ханифы*

Мөхәммәтсадыйкның якын туганы каберенә куелган таш та бар. Ул таштан да «78 яшьтә вафат» сүзләрен һәм ул таш хуҗасының исемен генә ачыклаган идек.
Мөхәммәтсадыйк тынгысыз кеше булган. Сәүдә эшләре белән Җиргәннән 200 чакрымдагы Оренбург, Уфа, Каргалы базарларына йөргән. Җәйге ярминкә вакытларында Эстәрлетамактан 300 чакрымдагы Юлык авылына да барып чыккалаган. Ул ярминкәгә Урта Азиядән ефәк тукыма, чәй ише үтемле товарлар китерелгән, анда башкорт, казахлар белән еллык алыш-биреш килешүләре башкарылган. Шундый бер сәфәре вакытында Мөхәммәтсадыйк Юлыкта ныклап төпләнеп калу фикеренә килә. Өй һәм кечерәк «сабын заводы»н сатып ала. Бу вакыйга 1862 елның җәендә була. Монда күченеп килү белән тире-күн эшкәртү эшен дә җәйлап җибәрә. Кибет тә ача. Аның бу авылга килеп урнашуының төп сәбәбен алдарак ачыкларбыз.
«Юлык исә – Урал тауларының Сакмар суы авышында, бөрҗән-тангаур башкортлары уртасында урнашкан ялгыз бер татар авылыдыр», – дип яза Р. Фәхретдинов. Авыл Оренбург – Верхнеуральск, Эстәрлетамак – Орск юллары кисешкән төбәктә 1780 еллар башында рәсми карар белән ямчылык хезмәтен үтәү өчен нигезләнгән. Зур әһәмияте булган әлеге юлларда ямчы хезмәтен башкарачак татарларны монда бик ерактан китерәләр. Архив документларында күрсәтелүенчә, алар Казан арты Чар даругасы сотнигы Кулиевка буйсынулы авыллардан булганнар. Юлык картлары бүген дә: «Безнең бабалар монда кырык дуга тотарга, юлларны карап торырга җибәрелгән», – дип сөйлиләр. Атналап, айлап юл йөргән авыл кешеләре төрле һөнәр үзләштергән, алыш-биреш итәргә өйрәнгән. Шуңа күрә Юлыкта тиздән атналык зур базар ачылган, җәй айлары кергәч, ярминкә үткәрелә башлаган.
Шакир белән Закир Рәмиевләрнең таякка

на могиле брата Садыка, умершего в 78-летнем возрасте. На другом, с плохо сохранившимися буквами камне местный молодой мулла в 1994 году сумел прочесть только слово, похожее на «Гали».
Мухаммедсадык был человеком энергичным. По торговым делам ездил за 200 верст в Оренбург, Уфу, Каргалу и в отдаленную от Стерлитамака на 300 верст Юлукскую ярмарку. На эти базары и ярмарки из Средней Азии привозили ходовые товары, например, шелковое полотно, чай и пр. На Юлукской же ярмарке с башкирами, а иногда и с казахами заключались годовые обменные сделки. И этот вид услуг был выгоден обеим сторонам. В 1862 году Мухаммедсадык решил окончательно обосноваться в Юлуке, купил себе дом и небольшой мыловаренный завод. Потом там наладил кожевенное производство. Но это дальнее село его привлекло, конечно, по другой причине.
«Юлук же представляет собой расположенную на склоне Уральских гор, у реки Сакмара, одинокую татарскую деревню среди бурзян-тангаурских башкир», – писал Р. Фахретдинов.
Село основано в начале 1780-х годов официальным постановлением губернатора для выполнения ямской службы на очень важных в то время дорогах: Оренбург – Верхнеуральск и Стерлитамак – Орск, и располагалось на перекрестке этих дорог. Более сорока татарских семей переселили сюда издалека, в основном – из Заказанья. В документах указано, что они были из сел сотника Чарской даруги Кулиева. «Даругами» в те времена именовались административные единицы типа современных районов. Старики деревни Юлук и сегодня рассказывают, что их прадеды были направлены сюда, чтобы «содержать дороги и сорок подвод для ямской службы». Проводя в дороге большую часть своей жизни, они попутно

атланып урамда чабып йөргән дәвере шушы Юлыкка туры килә. Авыл ягасыннан, якындагы Сакмарга карап, тау елгасы Мәгәш агып төшә. Түбән очта, кыйбла яктагы зират янәшәсендә, аңа Төгәл инеше кушыла. Мәгәш елгасыдай боргаланган кырыйдагы урам артында ук текә тау тезмәләре күренә. Алар – башкорт халкы җырларында җырланган Ирендек-тау сыртының бер өлеше. Авыл кыйблага таба авыш сөзәк калкулыкта урнашкан. Биредәге кечкенә инеш-елгалар, якынтирәдәге таулар шул беренче күченеп килүче «Мәгәшев, Төгәлбай» бабалар исеме белән йөртелә. Рәмиевләрнең Юлыктагы утар-йорты авыл уртасындарак булган. Аның урам як тәрәзәләре әлеге яшел чирәмле тауларга, ишегалды тәрәзәләре көньякка карап торган. Зур-зур унбер бүлмәле ул йортның бер башында элек Рәмиевләр приискларының конторасы да була. Совет хакимияте урнашкач, ул йортта башлангыч мәктәп ачыла. Ә 1929 елда исә, «мәктәп»не сүтеп, бай бураны Баймак каласына күчереп утырталар. Рәмиевләр утарында хәзер тау ташыннан төзелгән зур келәт һәм шундый ук таштан эшләнгән койманың бер өлеше генә бар. Таш келәтнең тимер ишекле җир асты өлешендә элек дәүләткә тапшырыласы алтын сакланган. Колхоз оешкач, ул келәтне тегермән



занимались ремесленничеством или мелкой торговлей. И в Юлуке действовал большой базар, проводились ежегодные летние ярмарки.
То время, когда Шакир и Закир носились по улицам верхом на палке, приходится на период их проживания в Юлуке. Деревня была расположена на южном склоне пологой возвышенности. По краю деревни в сторону протекающей невдалеке Сакмары сбегала горная речка Мэгаш. А на южной окраине села, у кладбища, в нее вливалась речушка Тюгал (эти речки и часть гор вокруг носили имена первых переселенцев). За изгибами речки Мэгаш поднимались крутые цепи гор – часть горного хребта Ирендык, воспетого во многих башкирских песнях. Дом-усадьба Рамиевых располагался в центре села. Фасад дома был обращен в сторону покрытых березняком гор, а дворовая часть смотрела на юг. Дом был большой – с одиннадцатью комнатами, где размещалась семья, прислуга и главная контора приисков Рамиевых. При советской власти сначала открыли там начальную школу. А в 1929 году срубы дома разобрали и переместили в город Баймак. На месте имения Рамиевых сегодня сохранились только большой амбар, сооруженный из горного камня, и часть забора из того же

*Юлык авылы күренеше*
*Вид села Юлук*

итеп үзгәрткәннәр. Садыйк хаҗи йорты янәшәсендәге өйдә полиция вәкиле яшәгән. Картлар: «Күршедә исправник йорты була. Ул монда кайтарылган алтын бөртекләре исәбен дә алган, шуларны саклаган да», – дигәннәр иде миңа, 1980 елда авылга килгәндә.

400–500 йортлы Юлыкта элек ике мәчет эшләгән. Шуның берсе – Рәмиевләр 1890 елларда төзеткән таш мәчет. Элек аның карамагында ир балалар өчен мәдрәсә, кызлар өчен мәктәп һәм кул һөнәренә өйрәтү класслары булган. Шул ук елларда авылда җәмәгать китапханәсе оештырыла. Аны тотуны Рәмиевләр үз мәчетләре мөәззине белән аның хатынына йөклиләр. Шул хезмәт өчен өстәмә эш хакы түлиләр. Китапханә ир-атлар өчен атнага дүрт, хатын-кызлар өчен ике көн ачык була. 1918 елда бу тирәләрдә дә болганышлар башлангач, китапханәне саклап калу өчен, киләсе кышта монда Орскидан драматург Мирхәйдәр Фәйзи җибәрелә. Ул монда драма түгәрәге оештыра, бер-ике пьеса яза. 1923 елда моннан китә. Юлыкка багышланган бер шигыре дә бар. Дәрдемәндне искә алмый бугай. Хәер, ул чор көндәлекләрен бер коммунист энесе бик нык чистарткан, дип яздылар. Драматург көндәлегендә аны Юлыкка җибәрүченең исем-аты да теркәлгән. Ул өяз түрәләреннән Хаҗи Рәмиев була.

материала. В подвальной части каменного амбара за железными дверями когда-то перед сдачей в государственные учреждения хранилось золото. А в соседнем доме жил исправник, следивший за учетом поступающей крупицы золота и ответственный за его сохранность совместно с хозяевами приисков. После образования колхоза этот амбар был переделан в мельницу.

В селе Юлук с 400–500 домами раньше действовали две мечети. Одна из них, каменная, была построена на средства Рамиевых в конце XIX века. При мечети Рамиевы содержали медресе для мальчиков, школу и курсы рукоделия для девочек. Чуть позже они организовали в отдельном доме общественную библиотеку. За дополнительную плату муэдзин мечети и его жена обслуживали эту библиотеку. В неделю четыре раза читальню открывал для мужского населения сам муэдзин. А женскую часть села дважды обслуживала его жена. В начале 1919 года, когда участились ограбления магазинов «баев» и начисто был ограблен большой магазин Рамиевых, для присмотра за библиотекой и работы с населением из Орска решили послать сюда драматурга Мирхайдара Файзи. Инициатор такой идеи указан



*Бу йортта 1919–1923 елларда күренекле татар драматургы Мирхәйдәр Фәйзи китапханә мөдире булып эшләгән һәм яшәгән*

*В этом доме в 1919–1923 годах жил и работал библиотекарем известный татарский драматург Мирхайдар Файзи*

Шакир белән Закирга иң әүвәл әниләре хәреф танырга өйрәткән. Беренче әкият-хикәятләр сөйләүче дә ул булган. Русча укырга һәм язарга да башлап Хәнифә әниләре, аннары инде «Орск өязе Тәмәч авылы учителе хосусый сурәттә җәй айларында» өйрәткән. «Закир Рәмиев үзлегеннән русча телне… дөрес язарлык, дөрес сөйләрлек, яхшы укып аңларлык үзләштергән», – дип яза Ф. Кәрими. Алар үскәндә, Юлыкта башлангыч (ибтидаи) мәктәп кенә була. Шуннан соң алар ике кыш Орск шәһәрендә укыйлар. Аннары укуларын алтын приискларының баш утарына якынрак булган Муллакай авылы мәдрәсәсендә дәвам иттерәләр. Юлыктан Орскига 150 чакрымнар булса, Муллакай аларга икеләтә якын. Табигатьнең иң гүзәл җирендә, Сакмар-су буенда урнашкан авыл. Закирның мәдрәсәдә укуын Орскида тәмамлаганлыгы мәгълүм. Соңгы елларда инде алар кыш айларын өяз үзәгендә – Орск каласында уздырганнар. Шул вакытлар тирәсендәдер, «Садыйк хаҗи» бу шәһәрдә дә зур гына кибет ача. Төрле тукыма, шул исәптән Урта Азиядән китерелгәне һәм Мәскәүдән кайтарылганы белән сату итә. Шуны дәлилләрдәй факт буларак, Шакирның сәүдәгәр Мостафа Борнаев белән бергә Мәскәү фабриканты Тимофей Морозов конторасында төшкән



в дневнике писателя – это один из уездных руководителей Хаджи Рамиев. Мирхайдар и здесь организовал драмкружок, ставил и писал новые пьесы.
Шакир и Закир первые буквы алфавита узнали от матери. И первые детские книжки читала им она же. Читать и писать по-русски тоже учила их мама Ханифа. А затем в летние месяцы с ними занимался нанятый для этой цели учитель из деревни Тамач Орского уезда. «Закир Рамиев самостоятельно освоил русский язык на уровне грамотного письма, речи и хорошего понимания читаемого», – писал Ф. Карими. Когда они росли, в Юлуке была только начальная мусульманская школа. После нее они две зимы проучились в городе Орске. Затем продолжили учебу в медресе деревни Муллакаево, расположенной недалеко от главной усадьбы золотых приисков отца. Если от Юлука до Орска было около 150 верст, то до Муллакаево – вдвое ближе.
Муллакаево расположено на самом берегу известной реки Сакмары. Отсюда недалеко и до реки Белой. Воспетые во многих татарских и башкирских песнях, эти реки текут здесь параллельно. Их разделяет лишь хребет Ирендыка. Вокруг неописуемая красота горных склонов, заросших белым

фотосын китерергә мөмкин. Дәрдемәнднең, Төркиядән кайткач, күбрәк вакытын Орскида уздыруын шул кибет эшенә бәйләп искә алалар.
Рәмиевләрнең кайбер приисклары мәңге онытылмас җырларга җирлек биргән Агыйдел белән Сакмар елгалары, ярышып, янәшә диярлек аккан тирәләрдә була. Бигрәк тә Муллакай авылы янында бу елгаларны фәкать Ирендек-тау сырты гына аерып тора. Сайрар кошлары, алар авазын бүлдереп, тау бөркетләренең ара-тирә кыркылдап алулары дисеңме… Тау иңкүләрендә җай гына яфрак лепердәтеп утыручы каен, усаклыклар, елга буйларындагы әрәмәлек, җимешле аланнар – күңел түреннән китмәс хозурлык! Еллар үтү белән, ул гүзәл күренешләр хыялда яңарачак, шигырь юлларына күчәчәк:

Берзаман чыгар идек без
Кырга дуст-ишләр илә;
Анда уеннар, көлүләр,
Сикерүләр бар иде…

*(«Үткән көннәр»)*

Муллакай мәдрәсәсен тәмамлагач, Рәмиевләр кабат Орскида яшиләр, белем үзләштерүне дәвам иттерәләр. Закир шуннан Төркиягә китә һәм, ел ярым чамасы Истанбулда яшәгәннән соң, 1881 елда шул шәһәргә әйләнеп кайта.
Закир Рәмиев-Дәрдемәнднең Төркиядә яшәү чоры аз өйрәнелгән. Абыйсы белән язышкан ике-өч хаты сакланган һәм соңрак сөйләнгән кайбер истәлекләре генә язмада теркәлеп калган. Аның 1959 елда дөнья күргән китабына язылган сүз башында Мөхәммәт ага Гайнуллин түбәндәге юлларны китерә: «Дәрдемәнд 1880 елда, укырга дип, Төркиягә китә. Истанбул шәһәренә урнашып, хосусый рәвештә төрек телен һәм әдәбиятын өйрәнә. Аерым бер мәктәпкә кереп укымый, бәлки, иректә рәвештә кайбер укытучыларның дәресләрен тыңларга гына йөри. Шунда Дәрдемәнд төрек язучылары һәм

березняком и осинником. Их вечно шепчущиеся листья создают особый уют и покой. А на лугах – разноцветье трав. Над всем этим разносится пение птиц, изредка прерываемое клекотом горных орлов. Пройдут года, поэт будет вспоминать все это вновь и вновь и запечатлевать в стихотворных строках:

Мы выходили без помех
С друзьями в поле;
Игры, смех пленяли, радовали всех, –
Какие развлеченья были!…

*(«Прошедшие дни»)*

После окончания муллакаевского медресе Рамиевы вновь переезжают в Орск и продолжают совершенствовать образование. Отсюда Закир уехал в Турцию и, прожив там немного, осенью 1881 года вернулся в эту же уездную столицу.
О жизни Закира Рамиева – Дэрдменда в Турции информации мало. Кое-что известно из сохранившейся переписки братьев и из воспоминаний, записанных окружающими со слов самого поэта.
В предисловии к книге, изданной в 1959 году, Мухаммед Гайнуллин пишет: «Дэрдменд в 1880 году отправляется для продолжения образования в Турцию. Жил он там в Стамбуле, частным образом изучал турецкий язык и литературу. Официально нигде не обучаясь, посещал уроки отдельных преподавателей. Там же Дэрдменд встречается и общается с турецкими поэтами и писателями».
Орск строился как укрепленный городок на границе с Казахским ханством на азиатском берегу реки Урал. Возникшая в 1735 году возле устья реки Орь крепость вскоре становится «столицей» обширного Орского уезда. Позднее Мирхайдар Файзи напишет: «Узнал, что Орский уезд по площади равен Курской губернии, а из заграничных стран превосходит



*Шәкерт Закир Рәмиев. 1877, 18 гыйнвар*
*Выпускник медресе Закир Рамиев. 1877, 18 января*



*Шагыйрьнең улы*
*Морад Рәмиев*
*Сын поэта*
*Мурад Рамиев*



*Улы Җәгъфәр Рәмиев*
*Сын Жагфар Рамиев*



*Уллары Гариф белән Искәндәр*
*Сыновья Гариф и Искандер*



*Дәрдемәнднең кызлары Зәйнәп белән Рауза. Самара, 1910 еллар*
*Дочери Дэрдменда Зайнап и Рауза. Самара, 1910-е годы*



*Кызы Өммегөлсем*
*Дочь Уммугульсум*

шагыйрьләре белән дә аралаша».
Орск шәһәре Җаекның аргы ягындагы Казакъ ханлыгы чигендәге кальга буларак 1735 елда төзелә башлый. Тиз арада зур бер өязнең үзәгенә әверелә. Мирхәйдәр Фәйзи соңрак: «Орск өязе Курскиның бөтен губернасы кадәр, чит мәмләкәтләрдән Даниянең бөтен җире аннан кечерәк икәнен белдем», – дип язачак. Орск каласы Җаекка Ур (Орь) елгасы кушылган җирдә урнашкан. Халкы бик чуар, Россиянең төрле почмакларыннан җыелган мөселманнар да күп анда. Алар элекке шәһәр халкының өчтән бер өлешен тәшкил иткән.
Форштадт бистәсе исә тулаем татар атлы казакларыннан тора. Аларның бабалары монда каланы нигезләүдә башлап йөргән «полкауник» Тәфкилев заманнарында ук килгән була.
Чит илдән кайткач, Закир берникадәр вакыт Орскида яши, дидек. Сәүдә эшләре белән шөгыльләнә. Җәй айларының бер өлешен, гадәттәгечә, алтын приисклары бистәләрендә дә уздыргандыр.
Мөхәммәтсадыйкның бу кибетендә төрле тарафтан китерелгән тукыма, үз «фабрика»сында эшләнгән күн әйберләре һәм сабын белән сату иткәннәр. Башкорт авылларында кулдан җитештерелгән әйберләр дә булган анда. Ә тукыма башлыча Мәскәүдән кайтарылган.
Төркиядән кайтуының икенче елында Дәрдемәнд Орскиның зур сәүдәгәре Мостафа Муса улы Борнаев кызы Мәхүбҗамалга (1861–1943) өйләнә. Сәүдәгәр Борнаевларны Казан янәшәсендәге Әтнә якларыннан килгән дип әйтәләр иде. Режиссер Марсель Сәлимҗанов та бервакыт: «Борнаевларда приказчик буларак сәүдә эшен башлаган бабаларым да шул Әтнә ягыннан», – дип сөйләгән иде. Өч бертуган Борнаевларны Касыймнан чыккан диючеләр дә бар.
Закир белән Мәхүбҗамалның сигез баласы туып, шуларның җидесе балигъ булган: Өммегөлсем (1883–1921, кияүдә – Камалова),

территорию Дании». Народ городка был пестрым; кроме русских чиновников и служащих здесь проживало довольно много мусульман. По архивным данным, их здесь было одна треть всего населения. Форштадтская же слобода состояла только из сословных татар, несших здесь когда-то пограничную казачью службу. Их деды переселились сюда еще при полковнике Тевкелеве, который был одним из основателей крепости.
По возвращении из-за границы Закир некоторое время жил в Орске. Был занят торговлей, часть летних месяцев проводил, видимо, и на золотых приисках. В эти годы Мухаммедсадык и в городе имел свой торговый дом. Торговал он здесь в основном разными тканями, кожей и мылом своего производства и кое-какими ручными изделиями, привозимыми из башкирских деревень. Ткани привозились также и из Москвы. Свидетельством этому служит фото, где Шакир Рамиев совместно с Орским крупным купцом Мустафой Бурнаевым встречается с фабрикантом Тимофеем Морозовым.
На второй год после возвращения Дэрдменд женился на Махубджамал Бурнаевой. Отец ее Мустафа Мусаевич Бурнаев был в этих краях известным купцом, имел прямые контакты с московскими и другими фабрикантами по производству тканей, одежды.
У него была своя торговая сеть и свои представители и на Ирбитской ярмарке. Бурнаевых некоторые считают выходцами из Атнинского района современного Татарстана.
И режиссер Марсель Салимджанов как-то говорил, что его деды – атнинцы купеческое дело начинали приказчиками у своих земляков Бурнаевых. А также есть сведения о том, что братья Бурнаевы были выходцами из города Касимова.
В семье Закира и Махубджамал Рамиевых было восемь детей:

Искәндәр (1886–1943), Рауза (?–1938, кияүдә – Яушева), Зәйнәп (1891–1977, кияүдә – Вәлиева), Гариф (1893–1971), Җәгъфәр (1895–1976), Морад (1898–1918). 1903 елда туган Фоад сабый чакта ук вафат була, дип хәбәр итте туганнары.
Яшь гаилә озакламый губернаның үзәк шәһәренә күчеп китә. Аларның анда төпләнүе ике гаилә өчен дә кирәк булгандыр. Шуңа күрә шәһәр уртасындагы булачак «шалаш»ларын да бик тиз төзеткәннәрдер. Искәндәр улы Бәшир ага Рәмиев: «Әти дә, мин дә Оренбургта туганбыз», – дигән иде. Димәк, алар гаиләсе анда 1885 елдан да соңламыйча яши башлаган. Оренбургның хәзерге Ленин урамында әлеге гаилә өчен төзелгән матур йорт (№ 31) әле дә үз урынында. Иркен ишегалдындагы таш келәтләре, ат абзарлары, төп йорт янәшәсендәге «Вакыт» типографиясе бинасы гына күптән сүтелгән инде. Ул йорт «Хөсәения» мәдрәсәсенә һәм аның мәчетенә якында гына – күрше урамда була.
Дәрдемәнд гомеренең байтак өлеше шушы ике шәһәр һәм Орск, Верхнеуральск өязләрендә урнашкан дистәләгән алтын приискы утарларында уза. Ике бертуган Рәмиевләрнең төрле җирдә егермеләп приискы булган. Аларның гаиләсе җәй айларын Сакмар елгасы буендагы Солтан,



Уммугульсум (1883–1921, в замужестве – Камалова), Искандер (1886–1943), Рауза (? – 1938, в замужестве – Яушева), Зайнап (1891–1977, в замужестве – Валиева), Гариф (1893–1971), Жагфар/Ягфар (1895–1976), Мурад (1898–1918) и Фуад (1903–?). Родственники написали, что Фуад умер младенцем.
В губернском центре для молодой семьи в скором порядке был построен добротный дом на одной из центральных улиц с обширными дворовыми постройками. Этот большой одноэтажный кирпичный дом и сейчас цел: расположен в Оренбурге на улице Ленинской, дом № 31. В 1989 году на стене дома была установлена мемориальная доска. Дом расположен недалеко от комплекса зданий медресе «Хусаиния» – на соседней улице. И ближайшая к Рамиевым мечеть находится в этом комплексе.
Иметь свой дом в губернском центре было выгодно обеим семьям. Поэтому и построили его в очень короткие сроки.
По сообщению внука поэта Башира Рамиева, семья их поселилась там не позднее 1885 года. «Сестра отца Уммугульсум родилась в Орске. А мы с отцом оба оренбургские», – сообщил он нам при встрече осенью 1993 года.

*Сулдан уңга: II гильдия Орск сәүдәгәре Мостафа Борнаев, фабрикант Тимофей Морозов, сәнәгатьче Шакир Рәмиев. Мәскәү, XIX йөз ахыры*
*Слева направо: торговец из Орска Мустафа Бурнаев, фабрикант Тимофей Морозов, промышленник Шакир Рамиев. Москва, конец XIX века*

Гаделшаһ утарларында һәм Юлыкта, хәзерге Магнитогорскидан ерак булмаган Балкан бистәсендә, шифалы дала үләннәре һавасы һәм саба җилләре белән данлы булган, хәзерге Оренбург өлкәсенең төньяк-көнчыгышындагы Сөендек елгасы тирәләрендә урнашкан Сахара, Шиһан авылларында уздырган. Сөендек, Урал елгаларына кармак салып, Дәрдемәнд балык та тоткан, диючеләр дә бар.
Алтын чыгаручы Рәмиевләрнең җәй айлары, шулай итеп, мәҗбүри рәвештә зур шәһәрләрдән читтә, прииск авылларында узган. Сакланып калган, «Бертуган Рәмиевләр» китабына (2002) кергән хатларга гына күз төшерик. «Тиз арада күрешеп булмас... Көз кермичә кайтылмас» сүзләре еш очрый анда. Һәр эшнең, һәр кәсепнең үз таләпләре. Ә алтын шахталары хуҗаларының үз мәшәкатьләре – эш сезонында алар приискларын ташлап китә алмаганнар. Ел әйләнәсендә аларга ат-арбада меңнәрчә чакрым юл узарга туры килгән. Оренбург белән Орск шәһәрләрен тоташтыручы 349 чакрымлы тимер юлны бары тик 1912 елда гына төзи башлыйлар. Сугыш чыгу сәбәпле, ул эш тә 1914 елда, ярты юлга җиткәч, ярым тукталыш хәленә килә. 1925 елда әле Муса Җәлил дә, калага барып җитмичә, Орскидан егерме чакрымдагы Круторожино тукталышында төшә. Нинди генә яхшы ат, затлы арбалар булмасын – берничә көнгә сузылган юл йөрүләр (Орскидан соң прииск авылларының иң якынына да 200 чакрым чамасы ара кала әле) бик ялыктыра, әлбәттә. Шуларны күз алдына китерсәң, алтын чыгаручы байлар эшенең бик тынгысыз икәнлегенә төшенәсең. Кышын да алар приискларын бөтенләй ташлап китә алмаган. Җир асты юлларын терәп торучы баганаларны китерү өчен генә дә күпме вакыт кирәк булган. Дөрес, элегрәк ул эшләрне Шакир агасы, соңыннан аның улы Сөләйман башкарган. Иҗат кешесен андый мәшәкатьтән азат итәргә тырышканнар.

Большую часть года Рамиевы проводили в Орском и в Верхнеуральском уездах, у золотых приисков «Балкан», «Гадельшах», «Султановский» и в селе Юлук. Или в степных аулах Сахара и Шихан, расположенных в пределах современной Оренбургской области. Там было царство целебных трав и степного легкого ветра. Поблизости текла чистая и богатая рыбой река Суюндук. О том, что в последние годы жизни Дэрдменд любил посидеть с удочкой на берегу Суюндука и Урала, сообщали многие в городе Орск.
У каждого дела свои тонкости, а у добытчиков золота – хлопоты особенные. Братьям Рамиевым с ранней весны до глубокой осени приходилось быть на своих приисках, жить вдали от крупных городов. Часть сохранившихся писем Дэрдменда приводятся в книге «Бертуган Рәмиевләр» («Братья Рамиевы», 2002). Там часто встречаются предложения, сообщающие о невозможности скорого свидания из-за нахождения в отдаленности автора письма («Не скоро еще встретимся», «Встреча откладывается до осени»).
Им за эти месяцы случалось проезжать в повозках тысячи верст. Строительство 349-километровой железной дороги, соединяющей Оренбург и Орск, началось только в 1912 году, с началом войны 1914 года шло с большими трудностями. Когда Муса Джалиль летом 1925 года направлялся на работу в Орск, до города он не доехал. Тогда конечной станцией было Круторожино, в двадцати километрах от Орска.
Дэрдменд и его близкие преодолевали это расстояние в 350 километров на подводах иногда по нескольку раз в год. Да и от Орска до приисков было не меньше пути. Самые близкие из них находились в двухстах километрах. Например, до села Балкан, где были самые прибыльные прииски Рамиевых, из Орска добирались двумя, а иногда и тремя ночевками. Так что миллионы

Рамиевых зарабатывались нелегким трудом. И зимой, когда рабочие-золотодобытчики отдыхали, хозяева приисков должны были подготавливать подземные сооружения шахт к новому сезону. Эту работу в основном выполнял Шакир, а после его смерти – их старший сын Сулейман.



*«Хөсәения» мәдрәсәсенең ишегалды күренеше. XX йөз башы*
*Общий вид медресе «Хусаиния» со двора. Начало XX века*

Күңел һәр җирдә гөл эзли,
Кадәр һәр җирдә тикән төзли...

*Там, где ищет глаз милей, Насаждает жизнь репей.*



*Закир Рәмиев – Россиянең I Дәүләт Думасы депутаты. Фотосурәт 1906 елда Санкт-Петербургта мәшһүр Карл Булла фотостудиясендә төшерелгән*
*Закир Рамиев – депутат I Государственной Думы России. Фотография сделана в знаменитой фотостудии Карла Буллы в Санкт-Петербурге в 1906 году*

# Сәнәгатьче Рәмиевләр

# Золотопромышленники Рамиевы

Урал-тауның җир асты байлыкларыннан кешеләр борынгы заманнардан бирле файдаланганнар. Элекке Орск өязе җирләрендә хәзер дә бакыр мәгъдәне алынган тирән-тирән коелар очрап тора. Юлык авылы янәшәсендә дә бер «бакыр чыгару чокыры» бар. Ул тирән чокырда элгәре алтын бөртекләре дә табылган. Әйе, алтынга да бай Урал-тау. Бу төбәктә яшәүчеләргә ул гомер-гомергә юлдаш булган. Аны чишмә, инеш буйларыннан да, тау йөзе убылган урыннардан да әледән-әле тапкалап торганнар. Җир өстендәрәк яткан алтынны артельләргә берләшкән «старательләр» эзләп көн күргән. Гадәттә, берничә кеше берләшеп, гади эш кораллары белән коралланып, урыннан урынга күчеп, махсус иләк-чүмеч, чиләк ярдәмендә су буйларында «алтын комын юдырып» йөргәннәр алар. Ягъни алтын бөртекләре булырдай комга чиләк-чиләк су коеп, махсус иләкләр аша уздырып, шул бөртекләрне берәмтекләп чүпләгәннәр. Ләкин андый гади ысул белән зур уңышка ирешеп булмаган шул.
Орск өязендә алтын чыгаруны сәнәгать ысулына күчерү XIX йөзнең утызынчы елларына туры килә. Брокгауз энциклопедиясенең 43 нче томында (130 б.) хәбәр ителүенчә, Россиядә аерым кешеләргә алтын приисклары ачу һәм тоту хокукы 1836 елдан бирелә. Шуннан соң бик күпләр бу җирләргә ябырыла. Алтын ятмалары табылган бер урында аерым кешеләргә биреләсе мәйдан бер квадрат километрдан артмаска тиеш була. Шуңа күрә инде кайберәүләр табышлырак урында туганнары исеменнән дә приисклар

Подземные богатства Уральских гор использовались людьми с древних времен. На землях прежнего Орского уезда до сих пор встречаются глубокие колодцы бывших медных рудников.
И рядом с селом Юлук есть такая глубокая «медная яма». Прежде в ней находили и крупицы золота. Да, и золотом богат Урал. Его периодически находили у родников и на берегах рек после весеннего паводка или сильных дождей, а также в местах горных обвалов. Поисками золота обычно промышляли небольшие артели старателей. Объединившись по нескольку человек и вооружившись нехитрыми инструментами, кочуя с места на место, они обильной водой промывали золотой песок с помощью переносного специального сита-ковша.
Но достичь большого успеха таким способом было сложно. Прибыль подобных артелей была невелика, но удовлетворяла потребности обыкновенной семьи.
Перевод золотодобычи на промышленные рельсы пришелся в Орском уезде на тридцатые годы XIX века. В 43-м томе Брокгаузской энциклопедии сообщается, что в 1836 году вышел указ, позволяющий путем раскапывания месторождений добывать золото. После этого на юго-восточных регионах Оренбургской губернии началась настоящая золотая лихорадка. Словно стая ворон, слетевшаяся на поле во время жатвы, сюда стекались желающие разбогатеть на добыче золота.
В нищенствовавшем раньше Орске открыли свою фирму и банк даже английские предприниматели.
В Орском уезде первый прииск-шахту




ачканнар. Унике яше тулган ир балалар исеменнән приисклар ачу хокукы бирелгәч, Рәмиевләр дә андый мөмкинлектән файдаланган.
Әйе, 1836 елдан соң Орск өязендә «алтын чыгару мәхшәре башланды» дип язалар шул чорга караган китапларда. Юлыктан 80 чакрым төньяктарак булган Күсәй авылы янәшәсендә беренче зур шахта-прииснкы генерал А. Жемчужников 1837 елда ача. Ике елдан соң Оренбургның эре җирбиләүчесе Н. Е. Тимашев та шул тирәдә үк берьюлы өч прииск нигезли. Соңрак шагыйрьнең әнисе Хәнифә Дашкова нәсел-ыруыннан да кемдер бу эшкә тотынып караган. Мәгәр боларның берсе дә Садыйк бай дәрәҗәсенә ирешә алмаган. Садыйк байның искәрмәстән генә

открыл генерал А. Жемчужников в 1837 году рядом с башкирской деревней Кусей, что в восьмидесяти верстах севернее Юлука. Спустя два года оренбургский помещик И. Е. Тимашев обосновал там же сразу три прииска. Годы спустя кто-то и из рода Дашковых тоже брался за это дело. Однако никто из них не смог достичь уровня Садык-бая. И ускоренный переезд семьи Мухаммедсадыка в 1862 году в Юлук был связан с этими событиями.
В 1869 году Мухаммедсадык Рамиев приобрел свой первый прииск около деревни Ишбирды (рядом с Кусеем). Внучка Шакира Рамиева Адиля Айда пишет в своей книге «Садри Максуди-Арсал» (Анкара, 1991): «Семья Рамиевых вправе считаться золотыми королями России… Будучи человеком трудолюбивым, Мухаммедсадык приобрел у российского правительства один из золотых приисков на Уральских горах, заключив сделку на 99 лет…» Такого договора, конечно, не было. Да и запасы золотоносных слоев истощаются намного скорее выше указанного срока. На самом же деле Садык купил этот прииск у одного разорившегося хозяина. Естественно, документы покупки утверждали чиновники царского правительства. Открытие или покупка месторождения золота было делом хлопотным, требующим больших затрат. Перед открытием каждого нового прииска приходилось обращаться в Управление горных дел, которое находилось в Екатеринбурге, а потом ждать, когда из далекой столицы придет разрешение.
После первого прииска в Ишбирды Мухаммедсадык почти каждый год открывает новый, иногда закрывая старые. Говорят, он не жалел ни сил, ни денег на поиски новых залежей золота. И сам открывал несколько новых мест скопления крупиц золота. Он, включая членов семьи, был хозяином около двадцати приисков.

*Хәзерге Башкортстан, Чиләбе өлкәсе җирләрендә Рәмиевләрнең иң эре алтын приисклары – картада кызыл түгәрәкләр белән билгеләнгән*
*Наиболее крупные золотые прииски Рамиевых на территории современного Башкортостана и Челябинской области – обозначены на карте красными кружочками*

Орск өязенә кергән Юлык авылына күченүе дә алтын чыгару кәсебенә бәйле, әлбәттә. Әмма аңа үзенә тиясе өлешне берничә ел көтәргә туры килә.
Мөхәммәтсадыйк Рәмиев беренче прискны 1869 елда сатып ала. Әлеге Күсәй янәшәсендәге Ишбирде авылындагы искерәк бер шахта була ул. Шакир кызы Камиләнең кызы Гадилә Айда әтисенә багышлы «Садри Максуди-Арсал» китабында (Әнкара, 1991): «Рәмиевләр гаиләсе Россиянең алтын корольләре саналырдай… Эшкә сәләтле кеше буларак, Мөхәммәтсадыйк… Россия хөкүмәтеннән Урал тауларындагы бер алтын приискын 99 елга дип килешеп ала», – дип яза. Дөреслектә, ул аны бөлгенлеккә төшкән бер рустан сатып алган. Билгеле, алыш-биреш документларын патша хакимияте түрәләре раслаган. Алтын чыгару чыганагын ачу, сатып алу эше бик мәшәкатьле булган һәм зур чыгым таләп иткән. Һәр прискны ачар алдыннан, Екатеринбургта урнашкан Тау эшләре идарәсендә эш йөртергә, шуннан соң ерак башкаладан рөхсәт килүен көтәргә кирәк булган.
Ишбирдедән соң Мөхәммәтсадыйк ел саен бер-ике яңа прииск ача яисә сатып ала, искеләрен яба торган була. Яңадан-яңа алтын «учаклары»н табуга ул көчен дә, малын да жәлләмәгән.
Варислары хәбәрләренә караганда,



Из них один был оформлен на имя Ханифы Дашковой. Так же по-одному были записаны за сыновьями. Например, Закир Рамиев числился хозяином прииска с 1871 года. Одному лицу иметь несколько приисков на одном месте не разрешалось. Поэтому среди их приисков были записанные и на имя Ханифы Дашковой, и на имена сыновей Шакира и Закира. Дети тогда имели право быть хозяином собственности с двенадцати лет. Еще работая вместе с отцом, Шакир отличился рационализаторскими способностями. Материалы о новшествах, введенных Шакиром Рамиевым в процесс добычи золота, публиковались в специальных изданиях России и за рубежом.
В 1994 году нас с фотографом Зуфаром Башировым принял Главный геолог Башкортостана Басыр Магадеев. На встрече присутствовал и внук Дэрдменда, геолог Равиль Рамиев. Ими была составлена карта всех приисков Рамиевых за 1869–1918 годы. Красными кружочками на карте отмечено более сорока мест (эта карта включена в альбом за 2003 год). Там же нам сообщили, что Шакир и Закир Рамиевы с начала XX века состояли также членами в трех-четырех коллективных компаниях. В том же кабинете нам показали два-три десятка журналов прихода и расхода золота за те же года, принадлежащих приискам Рамиевых.

*Гәүһәр – Шакир Рәмиевнең хәләл җефете*
*Супруга Шакира Рамиева – Гаухар*

Мөхәммәтсадыйк Рәмиев үз гомерендә егермеләп прииска ия булган. Алар арасында Хәнифә Дашкова исеменә язылганы да, Шакир белән Закир хуҗа булып исәпләнгәннәре дә бар. Мәсәлән, 1871 ел ахырында Закир да бер бай ятманың иясе булган, диелә бер язмада.
1994 елда фотограф Зөфәр Бәширов белән икебезне Башкортстанның баш геологы Басыйр Мәгадиев белән Дәрдемәнд оныгы, геолог Равил Рәмиев кабул иттеләр. Алар төзеп биргән картада Рәмиевләр гаиләсенә нисбәтле барлык приисклар да кызыл төскә буялып күрсәтелгән иде. Алар кырыктан ашкан. Шулар арасында кайберләре берничә хуҗаныкы. XX йөз башында Шакир белән Закир өч-дүрт күмәк ширкәттә дә торганнар, дип аңлаткан иде безгә Басыйр иптәш. Шул ук кабинетта безгә Рәмиевләр приискларыннан кергән алтынны теркәп баручы ике-өч дистә журналны да күрсәттеләр. 1869–1918 еллар арасында Рәмиевләр хөкүмәткә биш тоннадан артыграк алтын тапшырган икән. Шул ук төбәктән шул ук елларда хөкүмәткә кырык мең тонна алтын тапшырыла. Бертуган Рәмиевләр приискларының иң күп алтын биргәннәре хәзерге Чиләбе өлкәсе Нагайбәк районы Балкан авылы тирәсендә урнашкан була. Аларның ачылу мисалы да бик гыйбрәтле. Мул сулы Гүмбәй елгасы



Б. Магадеев нам сообщил, что с территории, охватывающей прииски Рамиевых, было добыто за тот период чуть более сорока тонн золота. Из этого количества на долю Рамиевых выпадает более пяти тонн. Самые золотоносные прииски братьев Рамиевых располагались на территории села Балкан современного Нагайбакского района Челябинской области. История их открытия тоже очень интересна. У полноводной реки Гумбей расположен небольшой нагайбако-казачий хутор Требия (тогда называвшийся еще и «Восьмым» хутором, упомянутым в известной повести Маджита Гафури «На золотых приисках поэта»). В 1895 году из колодца казака-нагайбака Кувшинова были подняты три крупицы золота. Об этом было сообщено братьям Рамиевым. Вскоре рядом с хутором заработала новая шахта. Исследовав окрестности, золото обнаружили и в четырех-пяти верстах от хутора. Там вырыли еще три шахты, рядом с ними вскоре появились слободы, носящие имена сыновей Шакира и Закира. Потом образовалось большое село Балкан. (Эти части современного села Балкан и сегодня именуются Искандеровской, Мидхатовской.) В центре слобод были отстроены сначала дом правления под зеленой крышей, упомянутой в вышеуказанной повести М. Гафури. А потом красивый гостевой дом с небольшим балкончиком и минаретами.

*Шакир Рәмиев – сәнәгатьче, алтын приисклары хуҗасы, нашир*
*Шакир Рамиев – промышленник, владелец золотых приисков, издатель*

буендагы кечерәк Требия хуторында (элек ул «Восьмой» хутор буларак М. Гафуриның мәгълүм әсәрендә дә теркәлгән) татар халкының бер этник төркеме – нагайбәкләр яши. 1895 елда Кувшинов фамилияле кеше коесыннан өч бөртек алтын чыга. Шул хакта бертуган Рәмиевләргә хәбәр итеlә. Тиздән хутор янәшәсендә яңа шахта эшли башлый. Хутордан дүрт-биш чакрымдагы билгесез үзән тирәсендә дә казу эшләре башлана. Анда алтын тагын да мулрак табыла. Шунда өч шахта казыла, алар янәшәсендә бистәләр барлыкка килә. Бистәләр уртасында Рәмиевләрнең баштарак яшел түбәле идарә бинасы, аннары кечерәк балконлы, ике манаралы купшы кунак йорты төзелә. Шул рәвешле, данлыклы Балкан авылына нигез салына. Аның аерым бистәләре бүген дә элекке прииск хуҗалары исеме белән «Искәндәрский», «Мидхәтский» дип йөртелә. Ул йортның фотосы бүген район музеенда саклана. Йорт исә 1943 елда янган. Бу балконлы, бик купшы эшләнгән йортта

(Фото этого дома имеется в музее районного центра.) Этот дом с балконом и минаретами летом 1910 года посещал Садри Максуди, приехавший свататься за семнадцатилетнюю Камилю Шакировну. Их свадьба состоялась той осенью в Оренбурге. Иногда отдыхали в этом доме с семьями Ф. Карими, Р. Фахретдинов и другие лица из ближайшего окружения Дэрдменда.

Для промывания золотого песка необходимо очень большое количество воды. Рядом с Балканом Рамиевы запрудили русло речушки в трех местах, создав таким образом три искусственных озера, и принялись за дело с большим усердием, заказав из-за границы локомобили и специальное оборудование. Вырыли артезианские колодцы. В вышеуказанной повести М. Гафури сообщается о находке здесь куска золота величиной с голову лошади. Это было у села Балкан. Там же обнаружили еще два крупных самородка. О них имеются сведения в музее района. Указано, что самородок



*Рәмиевләр йорты. Чиләбе өлкәсе, Балкан авылы, XX йөз башы. Бу йорт 1943 елда янган*
*Дом Рамиевых. Челябинская область, село Балкан, начало XX века. Этот дом сгорел в 1943 году*

1910 елның җәендә Садри Максуди да була. Ф. Кәрими белән Ризаэддин Фәхретдинов та төрле елларда анда булганнар. Ә Садри Максуди исә Шакирның унҗиде яшьлек кызы Камилә белән танышыр өчен килгән була. Шул елның көзендә Оренбургта аларның туй мәҗлесе уза.
Алтынлы балчык яки комны юдыртып төшерү өчен бик күп су кирәк. Балкан тирәсендә Рәмиевләр, үзән инешен өч җирдән буып, өч ясалма күл ясыйлар. Чит илдән локомобильләр, махсус җиһазлар кайтарып, артезиан коелары казытып, эшне бик зурдан башлап җибәрәләр. М. Гафури повестенда тасвир ителгән «ат башы зурлыгындагы алтын» да шушы Балканда табыла. Анда шундый зур өч алтын кисәге табылуы турында район музеенда да мәгълүмат бар. «Ат башы кадәрлесенең авырлыгы 24 килодан артыграк икән».
Балкан авылы уртасында бүген дә Рәмиев байлардан калган таш келәт һәм авыл халкын су белән тәэмин итүче артезиан коесы бар. Мәҗит Гафуриның мәгълүм повестенда («Шагыйрьнең алтын приискасында») телгә алынган яшел түбәле идарә йорты һәм Гадилә Айда китабында тасвирланган кунак өе 1943 елда сугыш афәтеннән качып килгән гаиләләр яшәгәндә янганнар. Рәмиевләрнең элекке утары урынында хәзер авылның ике катлы затлы мәктәп бинасы урнашкан. Балкан төбәге приисклары 1925 елдан соң



«величиной с лошадиную голову» имел вес более двадцати четырех килограммов.
Посреди села Балкан сохранились каменный амбар и артезианский колодец Рамиевых, которыми жители пользуются и по сей день. (На месте их дома в настоящее время стоит двухэтажное здание местной школы.) Дом правления приисков и гостевой особняк, описанный в книге Адили Айда, сгорели в 1943 году, когда там жили беженцы из западных районов СССР.
Прииски в Балкане закрылись после 1925 года.
У искусственных озер на краю села и рядом с выходами шахт до сих пор возвышаются горы гравия и песка, вынутых из недр земли.
Семьи Шакира и Закира Рамиевых летние месяцы проводили при своих приисках на различных местах Оренбургской губернии. Осенью семьи Рамиевых возвращались в Оренбург. Город Оренбург был основан в 1743 году на месте слияния рек Урал и Сакмара. Как пишет историк П. И. Рычков, на этом месте раньше был город Актюба, основанный половецким ханом Бачманом, а затем принадлежавший правителям Ногайской Орды. (Да, этот городок ранее принадлежал роду половецкого хана Бачмана, и Рычков описывал о нахождении там же его посмертного памятника.)

*Шакир Рәмиев йорты. Оренбург, 1994*
*Дом Шакира Рамиева. Оренбург, 1994*

ябылганнар. Авыл читендәге ясалма күлләр, элекке шахта авызлары тирәсендә бүген дә тау-тау булып җир куенынннан чыгарылган ком-таш өелеп ята.
Шакир белән Закир гаиләсе җәй айларының бер өлешен шушы Балкан авылында уздырган. Кадерле кунакларны да еш кына шушында каршы алганнар.
Кыш айларында бертуган Рәмиевләр башлыча Оренбург шәһәрендә яшәгәннәр. Бу кала Җаекка Сакмар елгасы койган урында 1743 елда төзелә башлый. Тарихчы П. И. Рычков дәлилләвенчә, элек ул урында борынгы кыпчак ыруы ханы Бачман яшәгән, аннары Нугай Урдасына кергән Актүбә каласы булган икән. 1885 елда Дәрдеменд гаиләсе күчеп килгәндә, бу шәһәрдә байтак кына татар зыялылары һәм эшмәкәрләре дә гомер иткән: телче галим Мирсалих Бикчурин, Укытучылар мәктәбе (Татарская Учительская школа) җитәкчесе һәм мөгаллимнәре, морзалар Усман Саинов, Гайса Еникиев («Җырчы Гайса»), мәшһүр сәүдәгәрләр Әхмәт, Мәхмүт, Габделгани Хөсәеновлар һ. б. Элегрәк шәһәргә килеп-китеп кенә йөргәләгән Шакир Рәмиев гаиләсе дә 1900 елдан биредә яши башлый. Шакир шәһәр театры янәшәсендә, Эссен һәм Перовский урамнары чатында, иркен ишегалды һәм бакчасы булган үз йортын салдыра. (Аларның йорт-утары 1994 елда да үз урынында иде әле.) Закирлар исә



*Шакир Рәмиев икенче хатыны Мәхбүбә һәм кызы Зәйнәп белән. Екатеринбург, 1904*
*Шакир Рамиев со второй женой Махбубой и дочерью Зайнап. Екатеринбург, 1904*

В то время, когда семья Дэрдменда переехала в Оренбург, там проживало довольно много представителей татарской интеллигенции: ученый-филолог, автор нескольких словарей восточных языков Мирсалих Бикчурин, учителя бывшей Татарской учительской школы мурзы Усман Саинов и Гайса Еникеев («Гайса-певец»), а также известные купцы Ахмет, Махмут и Абдулгани Хусаиновы и др. Вскоре, с 1900 года, Шакир и Гаухар Рамиевы тоже обосновались здесь. Шакир приобрел себе дом-усадьбу с просторным двором и садом на перекрестке улиц Эссена и Перовского, рядом с городским театром. Закир с семьей проживал чуть поодаль в своем доме. Позднее рядом с особняком Шакира был построен трехсекционный дом для сотрудников газеты и журнала. С лета 1906 года в двух секциях этого дома проживала семья Ризы Фахретдинова. Они также свободно пользовались приусадебным садом семьи Шакира (об этом пишет дочь Р. Фахретдинова). А в комнатах третьей секции поселялись более молодые сотрудники издательства «Вакыт».
Почти тридцать пять лет жизни общественного деятеля, поэта и золотопромышленника Закира Рамиева – Дэрдменда прошли в Оренбурге. Здесь написано большинство его известных стихов. Здесь он познакомился со

алардан ике-өч квартал арырак булган үз өйләрендә яши, дидек. Бераз соңрак Шакир утары янәшәсендә өч өлеш-секцияле «матбугат хезмәткәрләре йорты» да төзелә. 1906 елдан шул йортның ике өлешен Ризаэддин ага Фәхретдинов гаиләсе биләгән. Өченче секция бүлмәләрендә исә яшьрәк буын журналист гаиләләре яшәгән.
Закир Рәмиев-Дәрдемәнд гомеренең утыз биш елга якын өлеше Оренбург шәһәрендә узган. Биредә ул заманының күренекле шәхесләрен кабул иткән, алар белән әңгәмәдәш булган. Гыйльман ахун Кәримов, аның улы Фатих Кәрими, Ризаэддин Фәхретдинов, Шәриф Камал – бу йортның даими кунаклары. Әдипләрдән Галиәсгар Камал, Нәҗип Думави, Галимҗан Ибраһимов, җәмәгать һәм сәясәт әһелләре Хәсән һәм Йосыф Акчуриннар, бертуган Максуди кияү-кодалар, Зәки Вәлиди, Бари Баттал һ. б. да шагыйрьнең Введенская урамындагы адресын яхшы белгәннәр. (Шәһәр җәмәгатьчелеге тырышлыгы белән 1989 елда хәзерге Ленин урамындагы Дәрдемәнд яшәгән йорт диварына истәлек тактасы куелды. – Кара 95–96 б.)
Оренбургта яшәгән дәвердә Дәрдемәнд актив җәмәгать хадиме була – берничә тапкыр шәһәр Думасына халык вәкиле буларак сайлана. «Хөсәения» мәдрәсәсе оешкан 1889 елдан ул – тышкы иганәчеләр һәм идарәчеләр әгъзасы. XX гасыр башында Оренбург һәм Орскида оешкан берничә хәйрия җәмгыяте әгъзалыгына, «Оренбург мөселман шәкертләренә ярдәм итү җәмгыяте» рәислегенә сайлана.
Россия мөселманнары мәнфәгатен зур трибуналардан торып яклар дип өмет ителгән «Иттифакъ әл-мөслимин» партиясен оештыру корылтайларында катнаша. Программаларында милләтләрнең тигез хокуклылыгын һәм мәдәни үзбилгеләнү мөмкинлеген яклаган Кадетлар партиясенең Оренбург губернасы бюросына керә.
1906 елда Оренбург губернасыннан 1 нче

знаменитыми людьми своей эпохи, был их собеседником. В его доме частыми гостями бывали Гильман Каримов, его сын Фатих Карими, Ризаэддин Фахретдинов, Шариф Камал. Хорошо знали адрес дома поэта казанцы Галиасгар Камал, Наджип Думави, Галимджан Ибрагимов, общественные и политические деятели Хасан и Юсуф Акчурины, Хади и Садри Максуди, историки и писатели Заки Валиди, Бари Баттал.
(В 1989 году стараниями национальной общественности города на стене дома была установлена мемориальная доска, посвященная Дэрдменду. – См. стр. 95–96)
В оренбургский период своей жизни Дэрдменд активно участвовал в общественной работе, несколько раз избирался народным депутатом в Городскую думу, с 1889 года, как только было организовано медресе «Хусаиния», стал членом ее попечительского совета и благотворителем. В начале XX века был выбран членом нескольких благотворительных обществ Оренбурга и Орска, председателем Общества помощи мусульманским шакирдам. Участвовал в организационных собраниях партии «Иттифакъ аль-муслимин», от которой ожидалось, что она будет защищать интересы российских мусульман с больших трибун. Вступил в Оренбургское губернское бюро Кадетской партии, провозглашавшей в своей программе равноправие и возможность культурного самоутверждения народов России.
В 1906 году Дэрдменд избирается депутатом от Оренбургской губернии в I Государственную Думу, где записывается в мусульманскую фракцию, которая должна была защищать интересы единоверцев, выдвигается в руководящее бюро этой фракции. Однако Государственная Дума этого созыва была распущена указом царя и потому не успела развить свою деятельность.

Дәүләт Думасына депутатлыкка сайлана, анда үз диндәшләре таләпләрен якларга тиешле Мөселманнар фракциясенә языла, аның җитәкче бюросына тәкъдим ителә. Ләкин ул чакырылыш Дәүләт Думасы эшен җәелдерергә өлгерми, патша фәрманы белән таратыла.
Соңрак, 1917 елгы Февраль революциясе көннәрендә, Дәрдемәнд кабат яңарып киткән милли хәрәкәтләр эшендә бик теләп катнаша башлый. Шул елның июль аенда Казанда узган Бөтенроссия мөселманнары корылтаена килә, анда Вакытлы милли идарәнең Малия (финанс) нәзарәтендә эшләячәк әгъза итеп сайлана. Ләкин андый яңарыш чоры гына кыска гомерле булып чыга.
Зур өметләр баглап каршы алынган 1917 елның Февраль революциясе хөррияте озакка бармый. Шул елның көз айларында ук яңа түнтәреш була – Рәмиевләр ише мал-мөлкәтле кешеләр өчен хәтәр көннәр башлана. Совет хакимияте игълан ителгән көннән соң бер тәүлек үтмәстән, «байларның байлыкларын алу» турында декрет чыгарыла. Дөрес, Оренбург төбәгендә ул карарны гамәлгә ашырырга бераз соңлыйлар. Оренбургның үзендә Совет хакимияте беренче тапкыр гыйнвар азакларында, тулаем губерна күләмендә тагын бер елдан соң гына урнаштырыла.
Ә аңа хәтле, 1917 елның ноябрь азакларында, шәһәрдә Бөтенбашкорт корылтае уздырыла. Зәки Вәлиди җитәкчелегендә мөстәкыйль Башкорт мохтарияты игълан ителә. Мохтарият чикләренә кергән җир өсте һәм җир асты байлыклары аның милке дип белдерелә. Ә ул чикләргә Рәмиевләрнең барлык приисклары да сыеп бетә диярлек. Җир асты байлыкларының яңа мохтарият карамагына күчү хәбәрен Дәрдемәндкә шул кичтә үк Галимҗан Ибраһимов җиткерә. Ул әлеге корылтай кунагы була. Булачак мохтарият чикләренә кергән җирләрдә унбишләп прииск тоткан Рәмиевләрне бу хәбәр дә сөендерми, әлбәттә.

Позднее, после Февральской революции 1917 года, Дэрдменд, несмотря на удаленность от центров политической жизни, старается участвовать в работе вновь возродившихся национальных движений. В июле 1917 года он приезжает в Казань, где участвует в работе Всероссийского мусульманского курултая и избирается членом предполагаемого в будущем Министерства финансов Временного национального правительства. Эйфория свободы, дарованной Февральской революцией, длилась недолго.
Уже осенью того же года вновь совершился революционный переворот, начались дни, тревожные для богатых людей, подобных Рамиевым. Не прошло и суток со дня объявления советской власти, как был издан декрет об экспроприации богатств имущих слоев. Правда, в Оренбургской губернии с исполнением этого решения немного запаздывали. В самом Оренбурге власть Советов установилась только к концу января 1918 года, а в целом по губернии – лишь через год. А до этого, в конце ноября 1917 года, в городе проводился Общебашкирский курултай. Под руководством Заки Валиди была провозглашена суверенная Башкирская республика. Все надземные и подземные богатства в границах республики были объявлены ее собственностью. Почти все прииски Рамиевых вмещались в эти границы. Первым об этом событии сообщил Дэрдменду писатель Галимджан Ибрагимов, участвовавший в Башкирском курултае как гость.

Мөгзе бар
куйның бары да кучкар түгел,
Очкан кошның
барысы да шоңкар
түгел.

Овца с рогами
не всегда баран,
И не орёл
любая птица.



# Нашир Рәмиевләр

# Издатели Рамиевы

Рәмиевләр XIX гасырның сиксәненче елларында, Закир Төркиядә белем эстәп йөргән вакытта ук, газета нәшер итү, басмаханә булдыру турында үзара хәбәрләшәләр, дидек. Төркиядән кайтышлый Дәрдемәнд, Бакчасарайга кереп, Исмәгыйль Гаспринский белән дә очрашкан булса кирәк. Татарча газета чыгару уенда булган Исмәгыйль морза белән шул көздә үк Казанда бергә туры килүләре очраклы түгелдер. Шул очрашуда «Тәрҗеман»ның иганәче һәм абунәчеләре исемлегендә дә Рәмиевләр фамилиясе беренчеләрдән булып теркәлә. Ике бертуган, Казанга кунактан иртәрәк килеп, аңа булачак абунәчеләр белән очрашу урынын әзерлиләр. Әмма казанлылар ул очрашуга килми.
Соңрак Рәмиевләр дә үз газеталарын чыгарырга талпынып карый. Ләкин патша түрәләре Идел-Урал төбәге татарларына андый мөмкинлек бирүдән тыела, дип язган идек. Ә Россия канаты астына яңарак кына кереп сыенган «Кавказ татарлары»на андый «прәннек» тоттырылган: Бакуда «Игенче», Тифлистә гомуми төрки телдә «Зыя-и Кавказия» газеталары борын төрткән.
1906 ел башында «Вакыт» газетасын нәшер итәргә рөхсәт бирелгәч, Рәмиевләр мөхәррирлеккә Фатих Кәримине чакыралар. Ул да – Төркиядә укып кайткан, берничә китап авторы булган әдип. Рәмиевләр аның гаиләсе белән Шакир Европага сәяхәт кылырга ниятләгәндә танышалар. Тәрҗемәче-юлдаш сыйфатында аңа Фатихны Гани бай Хөсәенов тәкъдим итә. Нәкъ шул елда Фатихның әтисе, Бөгелмә өязе ахуны Гыйльман Кәримовның Оренбург шәһәрендә төпләнеп, татарча китап басу

Как было написано ранее, издательские дела обсуждались братьями Рамиевыми еще в 80-х годах XIX века, когда Закир совершенствовал свое образование в Турции. Возможно даже, что Дэрдменд по пути домой встретился в городе Бахчисарае с Исмаилом Гаспринским. У них были схожие взгляды на будущее и одинаковое желание издавать свою газету. Наверно, не случайной была их встреча той же осенью в Казани. Тогда Гаспринский приехал в Казань для сообщения местной публике о своем намерении издать газету в Крыму. А братья Рамиевы к его приезду арендовали зал, вывесили объявления о времени встречи. Но из казанцев на эту встречу никто не пришел. Так, в Казани единственными спонсорами и первыми абонентами будущей газеты «Тарджеман» Гаспринского стали братья Рамиевы.
А первый номер собственной газеты братьев Рамиевых «Вакыт» вышел только 21 февраля 1906 года. Редактором был назначен писатель, так же обучавшийся в Турции, Фатих Карими. Творческая дружба между Каримовыми и Рамиевыми зародилась, когда Шакир намеревался совершить путешествие по странам Европы. Ему в качестве спутника-переводчика Гани-бай Хусаинов предложил Фатиха. А он с отцом писателя, ахуном Бугульминского уезда Гильманом Каримовым, оказалось, был знаком давно. Отец писателя мечтал тогда, обосновавшись в Оренбурге, открыть типографию и взяться за издание книг. В этом деле первоначальную помощь ему оказал Гани-бай. Затем и братья Рамиевы протянули



وقت

اورنبورغده جمعا نورغانه كونده‌لك سياسى و ادبى غزته‌در.

غزته‌نك بهاسى:
يللق ٥ صوم، آلتى آيلق ٢ صوم ٦٠ ت.
اوچ آيلق ١ صوم ٣٥ ت، بر آيلق ٤٥ ت.
بر نمره ٥ تين
آدريس آلماشدرو ٢٨ تين.

«شورا» مجموعه‌سى
ايله برلكده و بر مدتكه يللق ٩ صوم.
آلتى آيلق ٤ صوم ٦٠ تين.
اوچ آيلق ٢ صوم ٤٠ ت، بر آيلق ٨٥ ت.
«شورا» نك بر نومرى ٢٥ تين.

چيت مملكت ايچون «وقت» يللق ١٠ صوم. «شورا» ٦ صومدر.

ОБЪЯВЛЕНІЯ впер. текста на 3 квадрата за строку петита 40 к., позади—20 к.

Редакція газеты „ВАКТЪ“ Оренбургъ.
REDACTION „VAKT“ ORENBOURG. RUSSIE.

اورنبورغده „وقت“ مطبعه‌سنده

هر تورلى كتابلر، كانطور كنيگه‌لرى، اسچوط وخط بلانقه‌لرى،
كانويرتلر، كارتچكه و زاپيسكه‌لر اشلرگه زاكاز قبول ايتوله‌در.

Оренбургъ, Типографія газ. „Вактъ“. مراجعت ايچون آدريس:

эшенә керешергә ниятләгән чагы була. Гани бай белән бертуган Рәмиевләр дә булышкач, Гыйльман ахунның да хыялы эшкә аша: 1901 елда Оренбургта беренче шәхси «мөселман басмаханәсе» барлыкка килә. «Вакыт»ның беренче саны 1906 елның 21 февралендә шул «Кәримовлар басмаханәсе»ндә нәшер ителә. Исмәгыйль Рәмиевнең «Вакытлы татар матбугаты. 1905–1925» (1926) исемле энциклопедик хезмәтендә: «Вакыт» – милли-либераль газета. Оренбургта чыга. Барысы 2309 сан чыкканнан соң, 1918 елның 26 гыйнварында туктатыла… Сәяси мәсьәләдә сак, дини һәм милли мәсьәләләрдә үз артыннан ияргән милли матбугатка юнәлеш биреп барды. Уку-укыту эше, тел һәм әдәбият, мәдәният мәсьәләләренә киң урын бирә, милли театр,

ему руку помощи как при покупке дома, так и при переоборудовании старой типографии. Вскоре газета «Вакыт» превратилась в самую надежную, самую читаемую, авторитетную в татарском обществе газету. В энциклопедическом труде Исмагила Рамиева «Татарская периодика. 1905–1925 гг.» (в 1926 г. на татарском языке) есть такие строки: «Вакыт» – национально-либеральная газета. Издавалась в Оренбурге. Была закрыта в 1918 году после выхода 2309 номеров. Осторожна в политических проблемах. В вопросах религии и нации указывала направление национальной периодике, следовавшей за ней. Уделяла много внимания проблемам образования, языка и литературы, культуры, выражала солидарность распространению музыкального искусства, последовательно защищала обучение в государственных школах».
Второе издание Рамиевых – журнал «Шура». Выходит два раза в месяц, всего 24 номера в год. Первый номер увидел свет 10 января 1908 года. «Издатели – Мухаммедшакир и Мухаммедзакир Рамиевы». Редактором указан Ризаэддин Фахретдинов, бывший с лета 1906 года заместителем редактора газеты «Вакыт». Журнал издавался на 36 страницах, имел большой формат, иногда там публиковались иллюстрации.
В книге Исмагила Рамиева читаем: «…Издавался до начала 1918 года, выпущено 240 номеров. Литературный, научный, исторический журнал. Самый видный среди татарских журналов. Приобрел авторитет как регулярное издание, хорошо распространялся… И по техническому исполнению, несомненно, был на первом месте в свое время».
В редакциях газеты и журнала работали известные журналисты и писатели той эпохи: Бурхан Шараф, Габдельбари Баттал, Шариф Камал, Джамал Валиди, Кабир Бакир, Зариф Башири и др. Одновременно широко

*«Вакыт» газетасының бер саны*
*Номер газеты «Вакыт»*

музыка сәнгатен җәелдерүгә теләктәшлек күрсәтә, дәүләт мәктәпләренә кереп укуны эзлекле яклый иде», – диелә.
Рәмиевләрнең 1908 елдан чыга башлаган «Шура» журналы айга ике мәртәбә, елына 24 сан булып нәшер ителә. Беренче саны 1908 елның гыйнвар башында дөнья күрә. «Наширләре Мөхәммәтшакир һәм Мөхәммәтзакир Рәмиевләр». Шул ук документта 1906 елның октябреннән «Вакыт» газетасы мөхәррир урынбасары булган Ризаэддин Фәхретдинов «Шура»ның мөхәррире дип күрсәтелгән. Һәр саны зур форматта 36 битле булып, вакыт-вакыт анда төрле-төрле рәсемнәр белән басылган.
И. Рәмиев китабында «Шура» журналының 1918 ел башына кадәр нәшер ителүе, барлыгы 240 саны чыкканлыгы әйтелә. «Әдәби, гыйльми, тарихи журнал. Татар журналлары арасында иң күренеклесе. Дәвамлы, тәртипле чыгып торуы белән дә абруй казанды, күп таралды, күп укылды… Техник эшләнеше ягыннан да үз заманында, һичшиксез, беренче урынны тотты», – дип яза Исмәгыйль ага. Журнал беренче елында шулай ук «Кәримов, Хөсәенев вә шөрәкәсе»ндә басыла.
Бу газета һәм журнал редакцияләрендә шул чорның танылган журналист вә әдипләре – Борһан Шәрәф, Габделбари Баттал, Шәриф Камал, Җамал Вәлиди, Кәбир Бәкер һ. б. эшли. Читтән торып алар эшендә Галимҗан Ибраһимов, Йосыф Акчура, Габдулла Тукай, Мәҗит Гафури, Нәҗип Думави, Ярулла Биги, Зәки Вәлиди, Һади Атласи, Чыгътай һ. б. язучылар, шагыйрьләр, «җәмәгать хадимнәре һәммәсе диярлек үзләренең каләмнәре белән катнашалар».
«Вакыт» белән «Шура»ны татар, башкортлар гына түгел, башка кардәш халыклар, мәсәлән, үзбәк, казахлар да үз итеп укыйлар. Газета һәм журнал битләрендә әдәби, гыйльми, дини эчтәлекле әсәр һәм хезмәтләр байтак урын алган, алар арасында үзара ярышлар уздырылган.

привлекались со своими произведениями и другие известные личности того времени: Галимджан Ибрагимов, Юсуф Акчура, Габдулла Тукай, Маджит Гафури, Наджип Думави, Ярулла Бигиев, Заки Валиди, Хади Атласи, Чагатай и др.
«Вакыт» и «Шуру» читали не только татары и башкиры, но и другие родственные народы, например узбеки, казахи.
На страницах газеты и журнала были широко представлены литературные произведения и труды научного, религиозного содержания, иногда проводились конкурсы. Произведения, победившие на конкурсах, а также те, которые по какой-либо причине не вошли в номера газеты и журнала, издавались Рамиевыми отдельными книгами в виде приложений.
«Закир Рамиев особенное внимание обращал на хорошее жизнеобеспечение работников




*1908–1917 елларда басылып чыккан «Шура» беренче татар әдәби журналының тышлыгы*
*Обложка первого татарского литературного журнала «Шура» («Совет»), издававшегося в 1908–1917 годах*



Ярышларда җиңеп чыккан әсәрләр, газета һәм журнал кушымталары рәвешендә, Рәмиевләр тарафыннан аерым китап итеп тә бастырылганнар. Редакцияләргә килеп тә, төрле сәбәпләр белән аларда урын ала алмаган шигырь, хикәяләр дә еш кына аерым җыентыкларга тупланып чыгарыла торган булган.

«Закир Рәмиев редакция эшчеләренең тормыш ягыннан яхшы тәэмин ителүләре... яшәүләре ягына нык күз сала, аларга, ул чорларда һичбер җирдә күрелмәгән рәвештә, зур жалованье – «Вакыт» газетасы редакторы Фатих Кәримов белән «Шура» журналы редакторы Риза казыйга – аена 130 сум бирә иде. Моны күпләр «министрлар жалованьесы» дип йөртә торганнар иде», – дип яза 1908–1909 елларда Оренбургта «Чүкеч», «Шура» журналларында эшләп алган әдип Зариф Бәшири («Замандашларым

редакции и поэтому платил им большое жалование в невиданных для той поры размерах. Например, платил месячное жалование в 130 рублей редактору газеты «Вакыт» Фатиху Каримову и редактору журнала «Шура» Риза-кадию Фахретдинову. Многие называли это министерским жалованием», – пишет в своей книге «Замандашларым белән очрашулар» («Встречи с современниками», 1968) писатель З. Башири, работавший в 1908–1909 годах в оренбургских журналах «Чүкеч» («Молот») и «Шура». «Так как Рамиевы, особенно Закир, питали большую любовь к литературе, они не смотрели на издательское дело с точки зрения прибыли... За последние годы от издания «Вакыт» и «Шура» они имели убыток примерно в десять тысяч золотых», – писал он. Разумеется, расходы Рамиевых на типографию «Вакыт», начавшую свою работу с декабря 1908 года, были во много раз больше этого.

Как сообщалось ранее, перед началом издания газеты «Вакыт», Рамиевы приобрели для работников редакции



*Дәрдемәнднең Фатих Кәримигә язган ике хат автографы*
*Автографы двух писем Дэрдменда, адресованных Фатиху Карими*



белән очрашулар», 1968). «Рәмиевләр, бигрәк тә Закиры, матбугат һәм әдәбиятка зур мәхәббәт белән караганлыктан, бу эшкә сәүдә-табыш ягыннан килмәделәр...» Үткән елларда «Вакыт» һәм «Шура»дан алтын хисабы белән ун мең сумлап зарар күрделәр», – ди ул. Әлбәттә, «Вакыт» басмасының чыгымы икеләтә зуррак булгандыр. Байтак кына китаплар бит анда Рәмиевләрнең матди ярдәмендә нәшер ителгән.
«Вакыт» газетасын чыгара башлау белән бер үк вакытта Рәмиевләр, редакция хезмәткәрләре өчен дип, Шакирның йорт-утары янәшәсендә өч бүлемнән торган бер йорт булдыралар, дип тә алдарак хәбәр иттек. Аның бер секциясендә төрле елларда яшәгән шәхесләр исемлегендә Казаннан сөрелгән Борһан Шәрәф, Петербургтан күчеп килгән Кәбир Бәкер һ. б. бар. Ул өй урынында хәзер биш катлы торак бина. Сиксәненче елларда аның диварына «Бу урындагы йортта 1906–1918 елларда

трехсекционный дом на Эссенской улице. В большой части дома жила семья редактора, там же находился его рабочий кабинет. В одной из секций в те годы жили разные люди (например, сосланный из Казани Бурхан Шараф, переехавший из Петербурга Кабир Бакир и др.). На месте того дома сейчас стоит пятиэтажное жилое здание, на стене которого в 1986 году была установлена мемориальная плита, которая гласит, что «в доме на этом месте в 1906–1918 годы жил писатель, ученый, педагог, редактор журнала «Шура» Ризаэддин Фахретдинов».
Как отмечает З. Башири в той же книге, типография Каримовых была уже довольно-таки изношенной, буквы менялись редко, использовалась дешевая бумага и плохие краски. Постоянно помогавшие содержанию данной типографии Рамиевы были не очень довольны ее работой и принялись хлопотать об открытии собственной. На улице Водяной, находившейся за усадьбой Дэрдменда, было куплено здание, примыкавшее к углу просторного двора дома поэта. Дом был отремонтирован, там было установлено современное оборудование, имелись комнаты для редактора и корректоров.
С 1 января 1909 года «Вакыт» и «Шура» уже издавались там, что заметно сказалось на их качестве. Новшество сказалось и на выпуске других изданий. Начались публикации литературных, общественно-культурных, исторических книг, учебников с печатью «Типография «Вакыт». Типография принадлежала Рамиевым до февраля 1918 года.
Часть изданной в те годы в Оренбурге русской и казахской периодики также выходила в типографии «Вакыт». Газета «Казакъ» (Оренбург, 1913–1918), имевшая большой авторитет среди казахов и внесшая значительный вклад в развитие самосознания своего народа, а также несколько книг на казахском языке –

*Фатих Кәрими – язучы һәм нашир*
*Фатих Карими – писатель и издатель*

күренекле галим, язучы, педагог Ризаэддин хәзрәт Фәхретдинов яшәде» диелгән истәлек тактасы куелды.
Шул ук китабында З. Бәшири билгеләп үткәнчә, Кәримовларның басмаханәсе ярыйсы ук таушалган була, хәрефләр еш алышынмый, арзанлы кәгазь һәм начар буяулар кулланыла. Даими ярдәм иткәләп торсалар да, Рәмиевләр бу типография эшеннән бик үк канәгать булмыйлар.
Һәм 1907 елда ук үз типолитографияләрен ачу хәстәренә керешәләр. Дәрдемәнд йорт-утарының иркен ишегалды почмагында, арттагы Водяная урамында бина сатып алына. Ул төзекләндерелгәч, анда заманча типография җиһазлары урнаштырыла, мөхәррир һәм корректорлар өчен эш бүлмәләре булдырыла. «Вакыт» белән «Шура» 1909 елның 1 гыйнварыннан шул басмаханәдә ярыйсы ук сыйфатландырылган рәвештә чыга башлый. Алдарак хәбәр ителгәнчә, «Вакыт» басмаханәсе 1918 елның февраль аена кадәр Рәмиевләр карамагында була.
1910 елларда Оренбургта нәшер ителгән кайбер рус һәм казах вакытлы матбугаты да шул басмаханәдә чыккан. «Казакъ» газетасы (Оренбург, 1913–1918), казах телендә унлап исемдә китап шулай ук «Вакыт»та басыла.
Ул чорда Оренбургта русча алты-җиде журнал, шул чамада ук газеталар чыга, ә бердәнбер хосусый Бреслин типографиясе 1915 елда ябыла. Губерна идарәсе типографиясе исә күбрәк рәсми материаллар бастыруга йөз тота. Совет хакимияте дәверендә Рәмиевләр эшчәнлеген барлау бик хупланмаганга күрә, «Вакыт» басмаханәсенә кагылышлы төпле фәнни тикшеренүләр әлегәчә булмады. Анда басылып чыккан китаплар саны бер үк авторның хезмәтләрендә дә төрлечә күрсәтелә. Оренбург хәйрия җәмгыятенең «Белек» китапханәсе, Орскидагы «Шәрык китапханәсе», Троицк, Чиләбе, Кустанай һ. б.

результаты работы типографии Рамиевых.
В то время в Оренбурге на русском языке выходило около шести-семи журналов и примерно столько же газет, а единственная частная типография Бреслина закрылась в 1915 году.
Типография губернского управления была больше ориентирована на издание официальных материалов. Вероятно также, что в типографии Рамиевых печаталось еще несколько татарских периодических изданий, в том числе и журнал «Карчыга» («Ястреб»). Но фундаментальных научных исследований о типографии «Вакыт» практически не было, т. к. в эпоху советской власти не очень одобрялось изучение деятельности Рамиевых. И даже в трудах одного и того же автора указывается разное количество книг, напечатанных в этой типографии, и хронологические рамки ее функционирования. Библиотеки «Белек» Оренбургского благотворительного общества и «Шарык китабханасы» в Орске, другие фирмы и общества книжно-газетной торговли в городах Троицке, Челябинске, Кустанае и других местах выполняли также и роль издателей. Постоянно направляли заказы на издание книг, которые были им нужны, в типографии Казани и Оренбурга. Вероятно, такие заказы выполняла и типография «Вакыт».
Итак, какие же книги печатались в типографии «Вакыт»? На первом месте, конечно, труды очень уважаемого Рамиевыми сверстника Дэрдменда Ризы-хазрета Фахретдинова. 35 его книг воспитательного, религиозного и исторического содержания увидели свет при поддержке братьев Рамиевых, из них какая-то часть вышла в этой типографии.
На втором и третьем местах – Шариф Камал и Галимджан Ибрагимов. Все дореволюционные произведения Ш. Камала публиковались сначала на страницах «Шура» и «Вакыт», потом издавались отдельной

якын шәһәрләрдәге китап-газета сәүдәсе ширкәт һәм җәмгыятьләре нашир вазифасын да үтәгәннәр, кирәк дип санаган китапларын бастырып чыгару өчен, Казан һәм Оренбург басмаханәләренә даими рәвештә заказлар җибәреп торганнар. Андый заказларны «Вакыт» типографиясе дә үтәгән.

«Вакыт» типографиясендә кайсы әдип вә галимнәребезнең китаплары нәшер ителгән соң? Кемнәр Рәмиевләр матбагасына якын торган? Беренче урында, әлбәттә, Рәмиевләр тарафыннан бик ихтирам ителгән, Дәрдемәндкә яшьтәш булган Риза хәзрәт Фәхретдинов хезмәтләре. Аның дини, әхлакый-тәрбияви һәм тарихи эчтәлекле байтак китабы «Вакыт»та дөнья күргән. Икенче, өченче урында Шәриф Камал һәм Галимҗан Ибраһимов. Ш. Камалның (Петербургта басылып чыккан беренче китабыннан кала) революциягә кадәр дөнья күргән барлык әсәрләре дә диярлек башта «Шура» белән «Вакыт» битләрендә урын алган, аннары аерым китап рәвешендә басылганнар. 1910 елда «Козгыннар оясында» исемендә озын хикәясе, 1914 елда унбиш әсәрен берләштергән «Хикәяләр төркеме», 1915 елда «Акчарлаклар» повесте укучыга «Вакыт» басмаханәсе тарафыннан тәкъдим ителә. Г. Ибраһимовның да беренче



книгой. (Кроме первой его книги, изданной в Петербурге.) В 1910 году читателям был предложен большой рассказ «В вороньем гнезде», в 1914 году вышел «Сборник рассказов», включавший в себя пятнадцать известных произведений писателя, а в 1915 году – его повесть «Чайки». И первые рассказы Г. Ибрагимова тоже появлялись сначала на страницах «Вакыт» и «Шура», а затем выходили отдельными книгами. Рассказы «В море» (1911), «Столетие тому назад» (1911), «Угасший ад» (1912), «Старый слуга» (1912) и объемный очерк «Татарские поэты» (1913) были опубликованы в этой типографии. Даже некоторые произведения Фатиха Карими, имевшего собственную типографию, печатались в типографии «Вакыт». Это, например, его объемная книга «Стамбульские письма» (1913) и несколько книжек серии «Народы мира». Такие известные книги, как «Законы литературы» Г. Сагди, «Габделвали Яушев» Г. Баттала, коллективный сборник «Биография хазрата шаеха Зайнуллы», «О татарской литературе» Ж. Валиди – труды, наиболее полно отражавшие общественную, культурную и литературную обстановку того времени. Там же издана небольшая книга-брошюра активного члена организации «Тангисты»

*Мәхүбҗамал Рәмиева*
*Махубджамал Рамиева*



иҗат дәвере хикәяләренең күпчелеге әүвәл «Вакыт» белән «Шура» битләрендә, аннары аерым китап буларак «Вакыт» басмасында чыккан. «Диңгездә» (1911), «Йөз ел элек» (1911), «Уты сүнгән җәһәннәм» (1912), «Карт ялчы» (1912) хикәяләре һәм күләмле «Татар шагыйрьләре» (1913) очеркы шулай нәшер ителгәннәр. Үз басмаханәсе булган Ф. Кәриминең дә кайбер хезмәтләре «Вакыт» типографиясендә чыга. Мәсәлән, «Истанбул мәктүпләре» исемле калын (450 б.) китабы һәм «Дөнья халыклары» исемендәге берничә китапчыгының язмышы шундый. Иҗтимагый, мәдәни, әдәби хәл-әхвәлне күзалларга ярдәм иткән Г. Сәгъдинең «Әдәбият кануннары», Г. Батталның «Габделвәли Яушев» китаплары, «Шәех Зәйнулла хәзрәтнең тәрҗемәи хәле» күмәк җыентыгы, Шакира Мухаммедьярова «Крепостное право и освобождение крестьян», в переводе на татарский язык книга известного просветителя Н. И. Ашмарина «Очерк литературной деятельности казанских татар-мохаммедан за 1880–1895 гг.» – все это публиковалось в типографии «Вакыт». Издавались и другие переводные книги: известного писателя Турции Ахмета Мидхата, английского писателя Конана Дойла, русских писателей Александра Пушкина, Леонида Андреева, вторая книга Абая Кунанбаева «Абай тирмэсе» и др. Приобретая типографию, Рамиевы не стремились к получению материальной прибыли, а ставили целью служение своему народу, трудились для блага нации.

*«Вакыт» газетасы һәм «Шура» журналының хезмәткәрләре (сулдан уңга): Габдрахман Фәхретдинев, Фатих Кәрими, Рәкыйб Рәкыйби, Ризаэддин Фәхретдин, Госман Акчокраклы, Закир Рәмиев, Ярулла Вәли, Борһан Шәрәф. Оренбург, 1909*
*Сотрудники газеты «Вакыт» и журнала «Шура» (слева направо): Габдрахман Фахрутдинов, Фатих Карими, Ракиб Ракиби, Ризаэддин Фахретдин, Гусман Акчокраклы, Закир Рамиев, Ярулла Вали, Бурган Шараф. Оренбург, 1909*

Җ. Вәлидинең «Татар әдәбияты хакында», «Таңчылар» төркеменең актив әгъзасы Шакир Мөхәммәдьяровның «Алпавытлар заманы», Абай Конанбаевның икенче китабы – «Абай тирмәсе» – һ. б. хезмәтләр дә – «Вакыт» типографиясе җимеше. Казандагы укытучылар семинариясе укытучысы Николай Ашмаринның «Очерк литературной деятельности казанских татар-мохаммедан за 1880–1895 гг.» китабы да монда татарчага тәрҗемә итеп бастырыла. «Вакыт»та чыккан тәрҗемә китаплар арасында Төркиянең күренекле әдибе Әхмәт Мидхәт әсәрләре, инглиз язучысы Конан Дойл, рус әдипләреннән Александр Пушкин, Леонид Андреев китаплары һ. б. бар.
Шул рәвешле, басмаханә һәм бертуган Рәмиевләр нәшер иткән журнал белән газета татар халкына уңышлы гына хезмәт иткән. Оештыручыларының изге ниятен үтәгән.

*«Хөсәения» мәдрәсәсенең идарәчеләре һәм иганәчеләре. Беренче рәттә сулдан уңга: Казый Нурмөхәммәт Мәмлиев, казый Гыйниятулла Капкаев, казый Хәсәнгата Мәхмүдев-Габәши, дин белгече, мәдрәсә башлыгы Габделгалим Дәүләтшин; икенче рәттә: морза Мәхмүт Госманов, фабрикант Хәсән Акчурин, Закир Рәмиев, Әхмәт бай вакыфы идарәсе рәисе, морза Гайса Еникеев, мәдрәсәгә нигез салучыларның берсе сәүдәгәр Мәхмүт Хөсәенев, язучы һәм нашир Фатих Кәрими, морза Закир Хәеров. 1909*

*Попечители и меценаты медресе «Хусаиния». В первом ряду слева направо: казий Нурмухаммет Мамлиев, казий Гиниятулла Капкаев, казий Хасангата Махмудов-Габаши, директор медресе, ученый-богослов Габдулгалим Давлетшин; во втором ряду: мурза Махмут Гусманов, Хасан Акчурин, Закир Рамиев, председатель правления фонда Ахмета Хусаинова мурза Гайса Еникеев, один из основателей этого медресе Махмут Хусаинов, Габдулхамид Хусаинов, писатель и издатель Фатих Карими, мурза Закир Хаеров. 1909*




وقت
دینی واجتماعی مسئله‌لر
رحمت الٓهیه
مسئله‌سی
شورا
مشهور آدملر والوغ حادثه‌لر
ادبیات اصوللری
Татарстан Җөмһүриятенең Милли китапханәсе
Национальная библиотека Республики Татарстан



تاتار ادبیاتی
حقنده
مختصر کیمیا
قسم ثانی
معادن
اثر: عبدالله شناسی
لئونید آندرییف
آجلق پادشاه
مترجمی: رفیب رفیقی.
حکایه
دورت کون
Приложение къ газ. „Вактъ" № 2263.
ШУРО
№ 15
АВГУСТА 1 — 1917 ГОДА.
شورا
مقالەلر:
Татарстан Җөмһүрияте Милли китапханәсе
Национальная библиотека Республики Татарстан



МИЛОСТИВЫЙ ГОСУДАРЬ

Мухамедъ-Фатихъ Гильмановичъ!

Издавая на татарскомъ языкѣ газету "ВАКТЪ" и журналъ "ШУРО", я лично за себя и въ качествѣ уполномоченнаго брата своего Орскаго купца Мухамедъ-Шакира Мухамедъ-Садыковича Рамѣева, симъ уполномачиваю Васъ на слѣдующее: управлять конторой и редакцiей вышеозначенныхъ изданiй, завѣдывать кассою, нанимать служащихъ, приглашать сотрудниковъ и на время своего отсутствiя, редактора, условится съ ними, разсчитывать ихъ получать и принимать денежную, заказную, и другую корреспонденцiю, посылки, клади и товары присылаемые на имя газеты "ВАКТЪ" и журнала "ШУРО", покупать нужные для изданiя ихъ предметы, бумаги и другiе товары, нанимать помѣщенiя. Открывать въ банкахъ текущiе счета отъ имени вышеназванныхъ изданiй, подписывать чеки, получать переведенные через банкъ по адресу ихъ деньги. Предъявлять иски къ разнымъ лицамъ ходатайствовать повсѣмъ дѣламъ касающимся изданiя означенныхъ газеты и журнала, въ судебныхъ и административныхъ учрежденiяхъ и у должностныхъ лицъ, выступать отвѣтчикомъ отъ лица газеты и журнала противъ другихъ. Довѣренность эту можете передовѣрять другимъ лицамъ съ правомъ дальнѣйшаго передовѣрiя, что Вы или повѣренные Ваши учините, я вѣрю, спорить и прекословить не буду.

Довѣренность эта принадлежитъ крестьянину Мухамедъ-Фатиху Гильмановичу К а р и м о в у.

За себя и по довѣренности отъ брата Орскаго купца Мухамедъ-Шакира Мухамедъ-Садыковича Рамѣева Орскiй купецъ Мухамедъ-Закиръ Мухамедъ-Садыковичъ Рамѣевъ

девятьсотъ одиннадцатаго Марта двадцать четвертаго дня довѣренность эта явлена ... меня, Михаила Петровича ... Оренбургскаго Нотарiуса ... моей находящейся на Троицкой улицѣ, ... своеручно лицъ извѣстныхъ имѣющихъ законную правоспособность къ совершенiю актовъ, Орскимъ куп-

Дәрдемәнднең Фатих Кәримигә язган хаты (имзасы белән)
Письмо Дэрдменда Фатиху Карими (с подписью)



М. В. Д.
ОРЕНБУРГСКАГО ГУБЕРНАТОРА КАНЦЕЛЯРIЯ.
Февраля 6 дня 1906 г.
№ 367

СВИДѢТЕЛЬСТВО.

Дано сiе отъ Оренбургскаго Губернатора на основанiи VII отд. п. I ВЫСОЧАЙШЕ утвержденнаго 24 ноября 1905 года закона о печати въ томъ, что въ г. Оренбургѣ разрѣшается издавать газету на татарскомъ языкѣ подъ названiемъ „Вактъ" ( Время) газета выходитъ отъ 2 до 5 разъ въ недѣлю. по слѣдующей программѣ: I) отдѣлъ офицiальный; правительственныя распоряженiя, 2) передовая статья, 3) внѣшнiя и внутреннiя извѣстiя, городская хроника, 4) Фельетонъ, 5) телеграммы, 6) объявленiя, 7) смѣсь, переводы и извлеченiя беллетристическихъ произведенiй съ русскаго и другихъ языковъ, а также статьи на русскомъ языкѣ. Подписная цѣна 4 рубля въ годъ. Издателемъ газеты „Вактъ" состоитъ Орскiй купецъ Мухамедъ Закиръ Мухамедъ-Садыковичъ Рамѣевъ. Отвѣтственнымъ редакторомъ газеты - крестьянинъ Самарской губернiи Бугульминскаго уѣзда Мухамедъ Фатихъ Гильмановичъ Каримовъ, имѣющiй жительство въ г. Оренбургѣ.

Газета „Вактъ" ( Время) будетъ печататься въ собственной типографiи Каримова.

Гербовымъ сборомъ оплачено.

И. д. Губернатора

ОРЕНБУРГСКАГО ГУБЕРНАТОРА

Правитель Канцелярiи

«Вакыт» газетасын чыгару өчен таныклык
Свидетельство, выданное на издание газеты «Вакыт»



М. В. Д.

ОРЕНБУРГСКАГО ГУБЕРНАТОРА КАНЦЕЛЯРІЯ

13 Декабря 1907 г.

№ 3894

Оренбургъ.

СВИДѢТЕЛЬСТВО

Дано на основаніи VII Отд. п. I ВЫСОЧАЙШЕ утвержденнаго 24 ноября 1905 года закона о повременныхъ изданіяхъ, проживающимъ въ г. Оренбургѣ, Орскимъ купцамъ Мухамедъ-Шакиру и Мухамедъ-Закиру Мухамедъ-Садыковичамъ Рамѣевымъ въ томъ, что разрѣшено издавать въ г. Оренбургѣ двухнедѣльное повременное изданіе на татарскомъ языкѣ подъ названіемъ „Шуро" ( Совѣтъ) по слѣдующей программѣ:

I) Краткіе отчеты изъ иностранной и отечественной политической жизни.

2) Смѣсь.

3) Объявленія.

4) Рисунки.

Отвѣтственнымъ редакторомъ изданія будетъ состоять крестьянинъ Самарской губерніи Реза Эддинъ Фахретдиновъ. Подписная цѣна въ годъ четыре рубля, а какъ приложеніе къ газетѣ „Вактъ" три рубля. Печататься изданіе будетъ въ типографіи „Товарищества печатнаго дѣла Каримовъ, Хусаиновъ и К-о въ Оренбургѣ. Гербовымъ сборомъ оплачено.

Губернаторъ [подпись]

Управляющій Канцеляріей [подпись]

*«Шура» журналын чыгару өчен таныклык*
*Свидетельство, выданное на издание журнала «Шура»*

Энҗе-алмаслар югалмас
Һәм ятып калмас – үтәр.

Не остаются
перлы втуне,
Алмаз и Жемчуг
Не пройдут.



*Мөхәммәтзакир Рәмиев. Льеж шәһәре, 1914*
*Мухаммедзакир Рамиев. Льеж, 1914*

# Өзелгән өметләр. Көтелмәгән кичерешләр

# Крушение надежд и череда трагедий

1918 елның 23 гыйнварында Оренбург шәһәре биш айга большевиклар кулына күчә. «Вакыт» газетасы һәм «Шура» журналы чыгудан туктый. Басмаханә мөдире Ярулла Вәлине ияртеп, Дәрдемәнд «Вакыт» типографиясе бинасына юнәлә, совет вәкилләренә басмаханәне үз кулы белән тапшыра. Таләп ителгәнчә, басмаханә ике атна эшләрлек күләмдә чыгым акчасын да түли. Шушы вакыйгалардан соң җан тынычлыгын җуйган шагыйрь шәһәрдән китеп торырга карар кыла. «Аның Оренбурдан китәсен белгәч, атам саубуллашырга дип аларга барды, – дип яза Риза хәзрәт кызы Әсма Шәрәф. – Закир әфәнде үзе дә безгә еш килә, әткәй белән озаклап утырырга ярата иде. Күп сүзләрдән соң Закир әфәнде әткәйдән сораган: «Хәзрәт, әгәр дөнья тынычланып, заманчарак итеп «Шура»ның чыгу ихтималы булса, кире кайтыр идегезме?» – дип. Әткәй, бераз уйлап торганнан соң: «Һичшиксез, кире кайтыр идем», – дигән» («Ризаэддин Фәхретдин». – Казан, 1999).
Шуннан соң инде алар башка күрешмәгәннәр. Шул ук җәйдә Ризаэддин Фәхретдинов гаиләсе дә Оренбургны ташлап китә. Ул, Уфага кайтып, мөфтияттәге эшчәнлеген дәвам иттерә. Бу эшен ул 1906 елда, Оренбургка күчкәндә калдырып торган була. Шагыйрь чордашы вафат булган көздә аны мөфти итеп билгелиләр. (Безнең матбугатта әлеге күрешү вакыйгасын Дәрдемәнд үләргә ятканда булган хәл дип тасвирладылар. Шагыйрьнең шуннан соң өч елдан артыграк яшәгәнлеген әйтеп үтү кирәктер. 1919 елда әле ул Казанда оештырылган бер конференциядә дә катнаша.)
Әлбәттә, әлеге күрешү вакытында Дәрдемәнд

23 января 1918 года Оренбург на пять месяцев оказался под властью большевиков. Перестали издаваться «Вакыт» и «Шура». При участии зятя, хозяйственного руководителя типографии Яруллы Валиева, Дэрдменд лично передает типографию «Вакыт» с предварительной оплатой полумесячной работы коллектива только что избранным представителям Советов.
После этих событий обеспокоенный поэт решает на какое-то время покинуть город. Об их намерении уехать из Оренбурга узнает Риза Фахретдинов. Вот что пишет об этом в своих воспоминаниях его дочь Асма Шараф («Ризаэддин Фәхретдин». Казан, 1999): «Отец, узнав об этом, отправился к ним прощаться… И Закир-эфенди у нас часто бывал. Они любили иногда так общаться. В конце продолжительной беседы Дэрдменд спросил отца: «Хазрет, если события изменятся, и опять наступит затишье, и разрешат нам издавать журнал, вернулись бы вы к своей обязанности?» Сначала отец растерялся. Потом сказал: «Да-да, обязательно бы вернулся!» Так они попрощались навсегда».
Летом того же года и семья Ризы-хазрета Фахретдинова покинула Оренбург. Он вернулся в Уфу и продолжил прерванную летом 1906 года работу в муфтияте.
В год смерти поэта – в декабре был назначен муфтием. После прощального чаепития в феврале 1918 года они больше не встречались. В момент этого прощального разговора оба еще надеялись на улучшение ситуации в стране, на возможность издания своих газет и журналов. Но этого не случилось. (В нашей печати некоторые

тә, Ризаэддин хәзрәт тә әле шул еллардагы түнтәрелешләрдән соң яңадан тыныч тормыш көннәре килеренә, элеккечә үк газета-журналлар нәшер итү мөмкинлеге тудырылачагына нык ышанган булалар. Дәрдемәнд тә, бар булган мөлкәтне яңа хакимияткә тапшыргач, элеккечәрәк яшәү мөмкинлеге тудырылачагы турында хыяллангандыр, ахрысы. Әмма ул хыяллар тормышка ашмыйча кала.
Бу елларда Дәрдемәнднең иң ышанычлы киңәшчесе, әлбәттә, улы Искәндәр булган. Германиядә укып, Европада яшәп кайткан кеше. Мөгаен, ул елларда Искәндәрнең карашы да атасыныкына тартым булгандыр. 1919 елда, яңа хакимият тәртипләре урнаштырылган көннәрдә, кайбер Оренбург сәүдәгәрләре гаиләләре белән башта Оренбургтан Орскига, аннан соң ашык-пошык рәвештә Урта Азия белән Себер якларына омтылалар. Искәндәр андый гамәлләрне хупламый. Гаделсез, тотрыксыз сәяси шартлар үзгәрер. Халык кузгалышы уңай мохитле гадел тормышка юнәтелгән, дигән кебегрәк фикердә була.
Әйе, Искәндәр инде тормыш тәҗрибәсе туплаган, Европада шактый вакыт яшәп, яңарак кына иленә кайткан кеше. Хәзер андый карашлы шәхесләрне «чып-чын либерал» дип атыйлар. Мәдрәсәнең рөшди өлешен тәмамлагач та, этисе аны Санкт-Петербургтагы гимназиягә илтеп урнаштыра. Немец телендә белем бирүче махсус уку йортына. Ул вакытта ук Искәндәр

эту встречу истолковали как последнее прощание в период тяжелой болезни Дэрдменда. Поэт после этого случая прожил еще более трех лет. А зимой 1919 года был в Казани как участник одной конференции.)
Из вышеприведенной беседы можно сделать вывод, что Дэрдменд еще надеялся на улучшение обстановки в будущем. Видимо, предполагал, что после передачи новой власти принадлежащих их семье приисков отношение к ним изменится и они продолжат жить равноправными гражданами своей страны. Наверное, так думал тогда и их сын Искандер, главный помощник и советник отца. Во время установления новой власти в крае, в 1919 году, некоторые оренбургские купцы с семьями сначала уезжали в Орск, а потом быстрее устремлялись в сторону Средней Азии и Сибири. Искандер их действия не одобрял. Предполагал, что раз народ поднялся против той несправедливой политической системы, то это будет к лучшему.
Конечно, в эти годы основным советником отца был он, около десяти лет проживший в европейских условиях и вернувшийся недавно оттуда «истинным либералом». Период его учебы в Санкт-Петербургской гимназии тоже пришелся на бурлящие от народного волнения годы. Многие тогда говорили, что устои царской власти шатки, и громко требовали равноправия и справедливости для всех. Эту мысль повторяли и в Европе, когда



*Искәндәр Закир улы Рәмиев (сулдан беренче) Германиядә Тау академиясендә укыган иптәшләре белән. 1914*
*Искандер, сын Закира Рамиева (слева первый), с сокурсниками в горной Академии в Германии. 1914*

башкаладагы зур чуалышлар чорына туры килә. Урам һәм мәйданнарга җыелган халыкның «патшалык итү тәртипләре бетерелсен, илдә тигезлек, гаделлек тәртипләре урнаштырылсын» дип таләп иткән көннәргә. Германиядәге Җир асты казылма байлыклары белгечләрен әзерләүче академиядә укыган вакыты да Искәндәрнең бигүк тыныч еллары булмый. Анда да яшьләр бар халыкның да тиң, тигез яшәргә тиешлеген таләп итеп урамнарга чыга. «Монархизм тәртипләре бетерелергә тиеш» дип даулый.
Хәер, Дәрдемәнд күңелендә дә ул елларда шуңа охшаш уй-фикерләр яшәгән. Шул сәбәпле ул гасыр башында калыккан милли хәрәкәт вакыйгаларында шактый ук актив катнашкан. 1905 елның кышында бер төркем зыялылар, татар халкына ил күләмендә тиңлек, тигезлек бирелүен таләп итеп, патша исеменә хат язалар. (Хатның караламасын Йосыф Акчура әзерли.) Шул хатка иң башлап кул куючылар арасында Шакир белән Закир Рәмиевләр була. «Иттифакъ әл-мөслимин» фиркасен оештыруда катнашу да шушы максатлардан чыгып эшләнә. Болар барысы да, әлбәттә, ата белән улның бер фикердәрәк булганлыгына ишарәдер.
Европа халкы тормышын, аның көнкүрешен күреп кайткан кеше буларак, атасы улы әйткәннәргә ышанган. Ә Искәндәр исә аңа патша Россиясендәге тормыш-яшәешнең артта калганлыгын искә төшергәләп торгандыр. Шул ук җәйдә Балкан авылында булган бер әңгәмә дә шушы фикерләрне раслый. Балкан авылында кичке аш вакытында ике ут арасында калган атасы: «Кем җиңәр икән? Аклармы, кызыллармы?» – дигәч тә, Искәндәр: «Халык кызыллар ягында. Алар җиңәчәк», – дип җавап бирде дип, көндәлегенә теркәгән Маһруй Борнаева кызы Әсма Рәхмәтуллина.
Хак әйтә. Берәү дә аңа каршы төшми. Башкорт халкының Оренбургта уздырылган корылтаенда Башкорт мохтариятын

Искандер продолжил учебу в Горной академии в Германии. Писали и говорили, что монархическим порядкам скоро придет конец. Восстановится демократическое равноправие граждан.
О возможности изменения устоев жизни в России мечтал в те годы и сам Дэрдменд. В этом их с сыном мысли совпадали.
В бурный 1905 год и Закир с братом Шакиром одними из первых одобрили и подписали подготовленную группой Юсуфа Акчурина петицию на имя царя, требующую равноправия для татар и других народов России. Одна родственница, присутствовавшая на вечернем чаепитии осенью 1918 года, запомнила и записала такой диалог между отцом и сыном.
«Когда обсуждали, кто же победит в этой Гражданской войне, Искандер-абый сразу же ответил: «Конечно же красные. Большинство населения недовольно нынешней властью», – написала Асма Рахматуллина, дочь Магруй Бурнаевой.
Когда братья Жагфар и Мурад сообщат, что вступили в армию недавно объявленной Башкирской Автономной Республики, и Закир с Махубджамал отнесутся к этому событию отрицательно, братьев же поддержит Искандер. Он скажет родителям, что они уже взрослые мужчины, одному двадцать четыре, другому двадцать лет. Раз хотят защитить права новой автономии, пусть защищают. Но с умом и умением.
Видимо, вступили братья в эту армию по патриотическому порыву. Тогда много молодежи мобилизовалось туда. Оба брата скоро ушли воевать, но попали в разные полки. Мураду, видимо, более нравилось быть казаком, и он записался в казачий полк. Так как большевики до февраля 1919 года не признавали существования этой автономии, то эта армия, одним из организаторов которой был Заки Валиди, воевала первоначально на стороне белых.
Эти события подтолкнули Дэрдменда

оештыру карары чыгарыла. Хөкүмәте төзелә, армиясе туплана башлый. Мәскәү исә баштарак бу мохтариятны үз кочагына алмый.
Әти-әниләре Орскига китәргә җыенып йөргәндә, Җәгъфәр белән Морад шул мохтарият армиясенә язылганлыкларын хәбәр итәләр.
Закир белән Мәхүбҗамал исә улларының бу ниятен хупламыйлар, каршы булалар. Шулчак Искәндәр энеләрен яклый. «Алар инде үз хәлләрен үзләре хәл итәрлек ирләр. Берсенә 24, икенчесенә 20 яшь. Яңа мохтариятны яклыйсылары килә икән – якласыннар, – ди. – Тик акылларын җуймыйча, оста сугышчы булсыннар». Шәһәр яшьләреннән бик күпләр бу армиягә язылa. Ике бертуган да тиздән яу кырына чыгып китә, әмма икесе ике полкка эләгәләр. Морадка атлы казак булуы ошагандыр, мөгаен. Ул шунда язылa. Бу армияне

и его жену, не дожидаясь наступления весны, отправиться в город Орск. Искандер должен был приехать туда чуть позже – они с Шарифзадэ Дашковой ждали тогда своего первенца. Будущий известный конструктор радиоаппаратуры, в том числе и космической, Башир Рамиев родился только в мае. В конце мая они втроем последовали за родителями.
Находясь в Орске, ближе к фронту, Рамиевы надеялись установить связь с сыновьями, поэтому туда и решили поехать, не откладывая поездку на лето. Надежда была невелика, но надежда… Притом Дэрдменд был немного знаком с командиром полка, куда записался Жагфар. С Мусой Муртазиным они встречались в каком-то учреждении. Этот командир с громовым голосом ему тогда понравился. И Заки Валиди, один из организаторов этой автономии, говорят, его очень ценил…



*Европа буенча сәяхәт вакытында. Уңнан сулга: Закир Рәмиев, Зәйнәп Закир кызы, Камилә Шакир кызы, Садри Максуди. Рим, 1914*
*Во время путешествия по Европе. Справа налево: Закир Рамиев, Зайнап, дочь Закира, Камиля, дочь Шакира, Садри Максуди. Рим, 1914*

оештыручы Зәки Вәлиди икәнлеге барыбызга да мәгълүм.
Шушы вакыйгадан соң Дәрдемәндләр, яз җитүен көтмичә, юлга чыгарга булалар. Искәндәр хәбәр итүенчә, энеләре катнашкан полклар да бу вакытта Орск шәһәренә якын - тирәдә икән. Искәндәр гаиләсе исә ул тарафка соңрак, хатыны Шәрифзадә Дашкова беренче балаларын тапкач чыгарга тиеш була. Булачак атаклы радиоконструктор, радио мөмкинлекләреннән файдаланып эшләнгән күптөрле җиһазлар, шул исәптән космоста кулланылачакларын да уйлап тапкан Бәшир Рәмиев шушы гаиләдә май аенда гына дөньяга киләчәк. Орск тарафына дип алар май урталарында гына юлга чыгачаклар.
Дәрдемәнд белән Мәхүбҗамал исә, ашыгып, февраль азакларында ук чыгып китәләр. Аларның хыялы, Орскига барып урнашкач та, уллары белән элемтә урнаштырырга тырышу була. Шуңа күрә иртәрәк кузгалалар да инде. Дәрдемәнд Җәгъфәр улы хезмәт иткән полк командиры белән бераз таныш була. Күк күкрәүне хәтерләткән көр тавышлы Муса Мортазин белән очрашкалаганнар икән. Мохтарият җитәкчесе Зәки Вәлидинең дә ул командирны бик югары бәяләве турында ишеткәләде. Ләкин ул командирны кайдан эзләп табасы? Аңа кем аша чыгасы? Элегрәк аңа ул даирә белән эш итәргә туры килми шул.
Озаккарак сузылган сәфәр вакытында шагыйрь шул хакта да уйлангандыр, мөгаен. Өлкәнең ике шәһәре арасында сугыш дәвам иткәнлектән, Рәмиевләр Орскига урау юл белән баралар. Алар юлга чыкканда, иске тәртипләрне яклаучы аклар белән кызыллар арасындагы канлы тарткалашлар бакыр ятмаларына бай булган Медногорск белән Сара бистәләре арасында барган. Шуңа күрә Рәмиевләр 300 чакрымдагы Актүбә каласына поездда, аннан соң 140 чакрымлык юлны Мәхүбҗамалның кече энесе Мәхмүтҗан җибәргән чаналарда

В этот раз в Орск Рамиевы поехали обходным путем, чтобы не попасть в зону боя, идущего между защитниками старых порядков и красными в районе меднорудных поселков Медногорск и Сара. Об этом сообщил им также Искандер. Поехали пассажирским поездом до города Актюбинск, находящегося в 300 километрах от Оренбурга. Здесь их должны были ждать две подводы, высланные младшим братом Махубджамал – Махмутджаном. Между Актюбинским и Орском около 140 километров дороги по степи. Она была частично знакома Дэрдменду. Там селений мало, дорога прямая. Доехали они благополучно. Поселились в своих комнатах, когда-то выделенных им тестем. В этот раз в доме тестя прожили они целых два года. (Этот коллективный торговый и жилой двухэтажный дом на центральной улице города был разобран в 1984 году.) Их радушно приняли Махмуджан с женой и двумя сыновьями. Со старшим их сыном, родившимся в 1910 году, я встречался в городе Орске в 1950-е годы. Он хорошо помнил деда-поэта. Рассказывал, как с дедом и кучером втроем они рыбачили в небольших озерах рядом с рекой Урал. А иногда гуляли всей семьей в Зауральной роще, что находилась недалеко от дома, впоследствии арендованного семьей деда. Особенно гордился он тем, как иногда дед-поэт брал его с собой в мечеть. Летом 1920 года Рамиевы арендуют дом купца Билала Мусина, уехавшего на некоторое время в какое-то село, где у него имелись торговые заведения. Через год Дэрдменд умер именно в этом доме, расположенном на современном переулке Поля Лафарга.
В дни, когда вблизи города Орска шли бои, Рамиевы уезжали на время в ближайшие села. Один такой случай упомянут в дневниках Мирхайдара Файзи. Он пишет, что летом 1919 года семья Дэрдменда жила некоторое время в селе Джуняево – в тридцати километрах от города.

узалар. Исән-имин барып җитәләр. Мостафа байның төп йортында да шушы Мәхмүтҗан калганлыктан, Закир белән Мәхүбҗамал ике ел шунда яшәячәкләр. Ә Орскида да Совет хакимияте тәмам урнашып беткәч, әлеге ике этажлы сәүдәгәрләр йорты шул хакимият карамагына күчкәндер, мөгаен (1984 елда сүтелгән ул йорт фотосы саклана). 1920 елның көзендә Рәмиевләр бер авылга күчеп киткән сәүдәгәр Билал Мусин йортын арендага алалар. Бер елдан соң шагыйрь Дәрдемәнднең гомере нәкъ шушы биш тәрәзәле таза йортта өзеләчәк тә (хәзер П. Лафарг тыкрыгына кергән өй).

Шәһәр өчен каты сугышлар барган вакытларда Дәрдемәндләр Орскига якын авылларга да китеп торгалаганнар. «1919 елның җәендә шәһәрдән Җүнәй авылына качып килүчеләр арасында Дәрдемәндләр дә бар иде», – дип язган көндәлегенә Мирхәйдәр Фәйзи. Җүнәй – шәһәрдән утыз чакрымдагы авыл. Шушы елларда шагыйрьнең тагын бер мәртәбә Казанда булганлыгын да билгеләп үтик. 1919 елның гыйнварында татар язуын камилләштерүгә багышланган конференция оештырыла. Унынчы елларда ук имла алыштыруга карата үз фикерен матбугатта белдергән Дәрдемәнд тә аңа чакырылган була. Шул конференциягә багышлы бер хезмәтендә тарихчы Нияз ага Субаев «Закир Рәмиев тә чакырылды» дип телгә ала. Ул вакыйгада актив катнашкан Ф. Хәмидуллин 1960 елларда чыккан бер мәкаләсендә «Дәрдемәнд тә анда булды» дип яза.

* * *

1918 елның май ахырларында Орскига җир асты казылма байлыклары инженеры Искәндәр дә гаиләсе белән күчеп килә. Дәрдемәнд гаиләсе Орскига килеп урнашкан арада, аклар белән кызыллар арасындагы сугыш вакыйгаларының Чиләбе тарафынарак авышканлыгы

А в январе того же года Дэрдменд в последний раз посетил Казань. Он был приглашен на конференцию, посвященную совершенствованию татарской письменности. Дэрдменд еще в 1910 году в периодической печати выражал свое мнение о необходимости таких изменений. Об его участии на этой конференции упоминается в газетной статье педагога Ф. Хамидуллина и в труде об этом событии ученого Нияза-ага Субаева.
Семья инженера горных дел Искандера переехала в город Орск в конце мая 1918 года. К этому времени события Гражданской войны уже переместились в сторону Челябинска. Видимо, все еще надеясь на встречу с сыновьями, Рамиевы в начале лета решили поехать в село Балкан, входивший тогда в Верхнеуральский уезд. И провели там лето. В этот раз с ними поехали младшая сестра Махубджамала Махруй и ее дочь Асма. Махубджамал, наверное, пригласила их специально для успокоения своей души.
Это лето провели там Закир, Махубджамал, Искандер Рамиевы и Магруй Рахматуллина с тринадцатилетней дочерью Асмой. Сохранились дневниковые воспоминания Асмы. Сначала остановимся на ее портретном изображении «джизни-абый» и «апа-апакай». Она сначала коротко описывает портреты хозяев: «Джизни-абый ростом высок, глаза голубые. Волосы русовато-коричневатые. Тетя-апай белолицая, нос у нее прямой. Длинные волосы русоватые. Они очень дружелюбны. Джизни и Искандер-абый с утра уходят на работу. Порядок дня таков: в восемь утра завтрак и чай. Ровно в двенадцать обед, вечером ужин с чаем. Перед сном едим катык. Обстановка дома очень простая. В шкафах у стен – разные дорогие камни из Уральских гор и книги». Чем занимались здесь Дэрдменд и горный инженер Искандер этим летом – не выяснено. Видимо, прииски продолжали еще добычу



ачыклана. Балалары белән очрашуга өмет итептер инде, Рәмиевләр җәй башында Верхнеуральск өязенә кергән Балкан авылына килеп урнашалар. Бу сәяхәттә Мәхүбҗамалның сеңлесе Маһруй һәм аның яшүсмер кызы Әсма да катнаша. 1905 елда туган Әсма Рәхмәтуллинаның шул җәйдәге вакыйгаларга багышланган истәлек язмасы сакланган. Әсма «шагыйрь җизни» белән «апай-абыстаен» болайрак тасвирлый: «Җизни озын буйлы, зәңгәр күзле, чәче дә дөм кара түгел, коңгырт иде. Апай ак йөзле, туры борынлы, коңгырт озын чәчле. Бик тату яшиләр… Җизни белән Искәндәр абый еш кына эш белән китәләр иде. Көндә сәгать сигездә иртәнге чәй була. Көндә бер үк вакытта көндезге аш, кичке чәй бирелә. Йокы алдыннан катык ашый идек. Балкандагы йорт җиһазлары гади. Шкафларда Уралда

золота. Власть здесь была еще старая. Но бои между белыми и красными шли уже недалеко. Дэрдменд, наверное, занимался в основном с документами приисков, приводил их в порядок. А Искандер посещал места добычи, присматривал за работой добытчиков. По воспоминаниям Заки Валиди, и правительство Башкирской Автономии, спешно сбежавшее из Оренбурга, находилось тогда недалеко от этих мест – в поселке Темяс.
Через какое-то время Магруй с дочерью решаются уехать в Орск. С кем собирались уехать – Асма об этом не пишет. Пишет только, что приближалась осень. Перед этим было «получено сообщение, что Мурад-абый лежит в больнице, болен тифом. Был он где-то недалеко. Направили туда кого-то с гостинцами проведать. Этот человек

*Европа илләренә сәяхәт вакытында. Уңнан сулга: Закир Рәмиев, Садри Максуди, Камилә Шакир кызы Рәмиева-Максуди, Гариф Закир улы Рәмиев, Зәйнәп Закир кызы Рәмиева-Вәлиева, Искәндәр Закир улы Рәмиев, Әхмәт-Мидхәт Шакир улы Рәмиев. Бельгия, Льеж шәһәре. 1914*
*Во время путешествия по европейским странам . Справа налево: Закир Рамиев, Садри Максуди, Камиля Рамиева-Максуди, дочь Шакира, Рамиев Гариф, сын Закира, Рамиева-Валиева Зайнап, дочь Закира, Рамиев Искандер, сын Закира, Ахмет-Мидхат, сын Шакира. Бельгия, город Льеж. 1914*

табылган затлы ташлар, китаплар иде».
Шул рәвешле, күпмедер вакыт үтә. Маһруйлар Орскига кайтып китәсе булганда гына хәвефле хәбәр килә. «Шул көн бик хәсрәтле көн булды, – дип яза Әсма. – Морад абыйның тиф белән авырып ятуы турында инде хәбәр килгән иде. Шул ук көнне ашсулар белән аның хәлен белергә кемнедер җибәргәннәр иде. Ул кеше без китәсе көнне әйләнеп кайтты. Морад абый больницада тифтан үлгән… Бу хәбәрне ишеткәч тә, җизни абый да, апай да, бер сүз дә әйтешмичә… алларына карап, тыныч кына утырдылар».
Мөгаен, Морад Балкан авылыннан җитмеш-сиксән чакрымнар чамасындагы Верхнеуральск госпиталендә яткандыр. Шул вакытта аклар белән кызыллар арасындагы аяусыз сугышларның Урал атлы казакларының икенче үзәге саналган әлеге шәһәр тирәсендә барганлыгы мәгълүм.
Бу аянычлы хәбәр килгәндә Искәндәр бер дә телгә алынмый. Ул инде, мөгаен, моннан кайтып киткән булгандыр. Ике-өч айлык бала белән ят шәһәрдәге хатынын бөтен җәй буена калдырып тора алмагандыр.
Бу вакытларда Җәгъфәр кайларда йөргән соң? Шул хакта әлегә миндә бик төгәл мәгълүмат юк диярлек. Шунысы мәгълүм: 1919 елның февралендә Мәскәүдәге җитәкчеләр Башкортстан мохтариятын «тануларын» белдерәләр. Мохтарият полклары, кызыллар ягына чыгып, элекке коралдашларына каршы сугыша башлый. Аклар гаскәренә каршы сугышта аеруча Муса Мортазин полкы зур уңышларга ирешә. М. Мортазин беренчеләрдән булып Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнә.
Җәгъфәр бу вакытларда зур сугышбәрелешләрдә бик катнашмагандыр, дип фаразлана. Реаль училище тәмамлап, тимертомыр белән бераз эш иткән кеше буларак, М. Мортазин аны полкны корал белән тәэмин итүче ролендә, кылыч айкап ат өстендә чабулардан тыебрак торгандыр. Ә инде көнбатыш тарафларда сугышканда, полк

вернулся утром в день нашего отъезда. Сообщил, что Мурад-абый умер от тифа. Услышав эту весть, ни джизни абый, ни тетя-абыстай не проронили ни слова…» Асма в этот раз не упоминает Искандера. Его уже в это время, наверное, не было в Балканах. Не мог же он так надолго молодую жену и двух-трехмесячного сына одних оставить в городе.
Мурад, наверное, скончался в лазарете, находившемся в городе Верхнеуральске. Именно в это время вблизи «второй Уральской казачьей столицы» и шли ожесточенные бои.
А где же в это время находился его брат Жагфар? И знали ли об этом что-либо родители – пока не выяснено. В феврале 1919 года Москва признала Башкирскую Автономию. Полки Автономии перешли на сторону красных и стали воевать против своих бывших напарников. Особого успеха в этих боях добился 1-й полк Мусы Муртазина. И вскоре он одним из первых будет награжден орденом Красного Знамени.
По имеющимся воспоминаниям, Жагфар в этих боях прямого участия не принимал. Как окончивший реальное училище и имевший небольшой опыт работы с металлическими изделиями, он был тогда ответственным за состояние вооружения полка. А когда полк стал дивизией, видимо, и он участвовал в некоторых сражениях. Когда шли бои за освобождение Киева, осенью 1920 года в одном из боев вражеский кавалерист отсек ему левую руку. И в начале 1921 года он вернулся в Оренбург. Спустя некоторое время отправился за родителями в Орск. (Его дочь Зубарзят не смогла сообщить точных дат его возвращения и проживания в Орске.) По традиции мурз женили его там на родственнице – Гульнур Исмагиловне из рода Бурнаевых. Но в это время Дэрдменда уже среди них не было.
С именем Жагфара связаны два неудачных эпизода по восстановлению творческого

дивизиягә әвереләдерелгәч, Җәгъфәргә дә яу кырында кылыч уйнаткаларга туры килгән. Һәм Киев шәһәрен азат итү өчен барган бер зур бәрелештә дошман атлысының үткер кылычы аның сул кулын кисеп аткан. Озак кына дәвалангannan соң, ул 1921 ел башында Оренбургка кайта. (Кызы Зөбәрҗәт аның кайчан анда кайтканлыгын һәм шуннан Орскига күчеп килүен төгәл генә хәбәр итә алмады.) Ә бераздан соң инде ул Орск шәһәренә килә. Морза гаиләләрендә яшәп килгән тәртип буенча аны якын кардәш-ыру вәкиленә – Борнаевлар нәселеннән булган Гөлнур Исмәгыйль кызына өйләндерәләр. Шуннан элегрәк гүр иясе булган Дәрдемәнд инде, әлбәттә, бу вакыйгада катнашмый. Бу елларда Җәгъфәр ата-анасы белән хәбәрләшә алганмы? Хисчән шагыйрь йөрәге бу вакыйгаларны ничек кабул иткән? Шул хакта бернинди дә мәгълүмат юк. 1993–1994 елларда шагыйрьнең ике оныгы белән очрашып сөйләштек. Ул әңгәмәләрдә Зөфәр Бәширов та катнашты. Ике-өч көн Мәскәүдә, шагыйрь оныгы Бәшир ага Рәмиев өендә булдык. Үзен һәм атасы белән бабасына бәйле кайбер истәлекле әйберләрне Зөфәр шул көннәрдә фотога да төшереп алды.

* * *

Бу елларда Дәрдемәнднең шигырь язу-язмавын белүчеләр хәзер юк. Гражданнар сугышыннан бер кулын өздереп кайткан Җәгъфәргә бәйле ике вакыйга искә алына. Беренчесе 1930 елларда абыйсының аңа бер үтенеч хаты язуына бәйле. Искәндәр яңарак кына Уфага күчерелгән, «Башкирзолото» трестында лаборатория мөдире вазифасын үти башлаган була. Җәгъфәргә ул аталарыннан калган барлык кульязмаларны Уфага алып килергә куша. Кабат искә алып сөйләүчеләр сүзенә караганда, кайсыдыр станциядә бер поездан икенчесенә күчеп утырганда, Җәгъфәрнең кием-салым чемоданын урлыйлар. Шул чакта

наследия отца. В середине 1930-х годов Искандера Рамиева перевели на работу в Уфу. Назначили заведующим лабораторией треста «Башкирзолото». Наверное, кто-то тогда заинтересовался творчеством Дэрдменда. Искандер попросил брата привести имеющиеся черновики и другие записи отца в Уфу. Жагфар повез их брату. Но на одной из пересадок с поезда на поезд чемодан с его вещами украли. Видимо, заранее следили за сыном «богача». А в том чемодане была и папка с рукописями Дэрдменда. А после смерти Сталина, зимой 1955 года, с некоторыми позже найденными записями отца и своими воспоминаниями Жагфар приезжал и в Казань. Но ни в Союзе писателей, ни в книжном издательстве его по-доброму не принимали.
По сообщению поэта Виля Ганиева, в пятидесятые годы являвшегося



*Шәрифзадә Дашкина – Дәрдемәнднең килене, Искәндәрнең хатыны*
*Шарифзадэ Дашкина – сноха Дэрдменда, жена Искандера*

шагыйрьнең язмалары саклаган бәйләме дә урлана. Бай баласының чемоданын сагалап йөрүчеләр эше булгандыр инде бу. Рәмиевләрнең Оренбургта калган китапханәсенең язмышы да аянычлы. Элек алар бер таш келәткә тутырылып бикләнгән иде, дип сөйлиләр. Соңрак инде аларның бер өлеше төрле кулларга күчеп тарала. Кирәкмәсрәк дип саналган китаплар, төрле язмалар сугыш елларында мичкә ягыла. Шагыйрь кулъязмаларына бәйле икенче очрак та бик гыйбрәтле. Сталин вафат булгач, 1955 елда Җәгъфәр, атасының аннан-моннан эзләп табылган берничә әсәрен, аңа багышлы кайбер истәлек язмаларын һәм үз шигырьләрен тотып, Казанга килә. Ләкин монда аны бик төксе каршы алалар. Язучылар берлегендә дә, китап нәшриятында да аның тәкъдимнәрен кабул итмиләр. Шул вакытта «Совет әдәбияты» редакциясенә килгәләп йөргән, ә бераздан шунда ук эшли дә башлаган шагыйрь Вил Ганиев хәбәр итүенчә, аны хәтта «син буржуй баласы» дип мыскыллаучылар да була. Шул елларда Язучылар берлеге рәисе булган Гомәр ага Бәширов белән дә ул вакыйганы бервакыт искә алган идек. «Идарә әгъзалары белән сөйләшүдән соң мин аңа әдәбият галиме Мөхәммәт Гайнуллинга мөрәҗәгать итәргә киңәш бирдем», – диде ул.
Шуннан соң инде бу галим Оренбургта, Уфада була, шагыйрь кызы Зәйнәп Вәлиева белән дә таныша. Һәм 1959 елда аның Дәрдемәнд иҗатын һәм тормышын киң яктырткан күләмле очеркы басылып чыга. Ул хезмәт безнең җәмәгатьчелек өчен ачыш булды, Дәрдемәнд иҗатын кабат өйрәнү башланды.

* * *

Яңадан Орск каласына әйләнеп кайтыйк. Элеккеге дус-иш, фикердәшләрдән аерылгач, моңсу чакларда шагыйрь монда кемнәр белән аралашкан? Алдарак без аларны искә алырбыз. Әлбәттә, ул «дуслар»ның күпчелеге Мәхүбҗамал Борнаеваның туганнары булыр.

сотрудником журнала «Совет әдәбияты», Жагфара в Казани приняли очень недоброжелательно, некоторые осмеливались называть его «сыном буржуя». Тогдашний председатель Союза писателей Гумер-ага Баширов посоветовал ему обратиться к литературоведу Мухаммеду Гайнуллину. (Он сам мне об этом сообщил, когда я обратился к нему по этому поводу.) Так завязалась связь этого литературоведа с наследниками поэта. Он посетил Оренбург, в Уфе встречался с дочерью поэта Зайнап Валиевой. А чуть позже, в 1959 году, ученый напишет большую статью о жизни и творчестве поэта, вновь открыв путь любителям и исследователям поэзии Дэрдменда.
Вернемся в город Орск. С кем же в эти годы общался поэт? Конечно, в первую очередь с семьями родственников жены Махубджамал Бурнаевой. Старший ее брат Габдулла жил тогда в собственном двухэтажном доме. (Этот дом в 1994 году был еще на своем месте – на улице Пионерской.)
Семья Искандера после приезда в город в мае 1918 года поселилась в этом доме. А на другой улице жила семья брата матери Махубджамал – Закира Хакимова. Летом 1920 года, когда из большого дома на центральной улице выселили всех жильцов (этот дом разобран в 1984 году), старшие Рамиевы два-три месяца прожили в доме Хакимовых. Затем они арендуют частный дом Мусиных.
Самый тяжелый, сопровождаемый грустными событиями в жизни Дэрдменда, период – это 1920–1921 годы. Дела его по всем направлениям шли туго или даже совсем плохо. И различные трагедии одна за другой преследовали их в эти годы. А все началось с любимого всеми их сына Мурада… Именно здесь, в доме Габдуллы, произошла вторая трагедия в семье Рамиевых. При рождении второго ребенка умерла жена Искандера Шарифзадэ. Ее,

Туган белән бертөрле, дус, фикердәш белән икенче төрлерәк сөйләшенә шул…
1918 елда Рәмиевләр монда күчеп килгәндә, Мәхүбҗамалның өлкәнрәк энесе Габдулла да, әнисенең энесе Закир Хәкимов абыйлары да яшәгән. 1920 елда, арендага йорт алырга килешкәнче, алар ике-өч ай шушы Закир агаларында да торып киткәннәр. Шуннан инде Мусиннар йортына күчәләр.
1918 елның май ахырларында монда килгән Искәндәр гаиләсе исә Габдулла агаларының иркен, ике катлы йортында төпләнәчәк. (1994 елда ул йорт үз урынында – Пионерлар урамында урнашкан иде.)
Дәрдемәнд өчен бу калада уздырылган соңгы ике ел бигрәк тә аянычлы, хәвефле була. Җан җылысын, күңелен биреп эшләгән барлык эшләре таркалу хәлендә. Кирәк чакта киңәш бирешердәй, уй-фикерләр белән уртаклашырдай иң якын җан дуслары кайдадыр еракта калган еллар бу. Өстәвенә гаиләдә дә төрле авырлык, фаҗигаләр дә берсе артыннан берсе килә тора…
Әйе, Морад үлеменнән соң бер ел да үтми, бу йортка тагын бер зур кайгы төшә. Искәндәрнең сөекле хатыны, олыларның итагатьле килене Шәрифзадәнең икенче баласын тапканда гомере өзелә. Бәшир ике яшен тутырып, өченчегә барган көздә. Бәшир ага: «Бу вакыйганы мин әбиемнең кат-кат сөйләүләреннән генә хәтерлим. Ул әйтер иде: «Без карбыз тозлаганда, көз көне булды бу хәл», – дип. Димәк, 1920 елның сентябрьләрендә була бу үлем». Шулай дип нәтиҗә чыгарган ул, үз анасын искә алганда.
Ике-өч ел дәвам иткән канлы сугышлардан соң илдә ваба, тиф авырулары тарала. Бу афәт яңадан Рәмиев, Борнаев гаиләләре капкаларын да шакый. 1921 елның язында Маһруйның зур кызы үлә. Кабат Әсма Рәхмәтуллинаның язмаларына күз төшерик. «Бу вакытларда җизни безне бер дә ташламады. Чәй, шикәрләр юк чак. Кешеләр шулар урынына көздән киптерелгән кавын, карбыз кабыкларын салып эчте.

приятную, улыбчивую, очень любил муж, за прилежность уважали все старшие. Но вот Башир-ага ее не запомнил. Тогда ему не было еще и 2,5 лет. При встрече в Москве он нам говорил, что помнит ее только по рассказам бабушки. А она ее очень часто вспоминала. Говорила, что умерла она в дни соления арбузов. «Значит, это было в сентябре 1920 года», – подытожил разговор Башир-ага.
Обычно говорят, что беда не ходит одна. Так же случилось и в клане Рамиевых-Бурнаевых. События происходили весной 1921 года. Взглянем на воспоминания Асмы Рахматуллиной. После двух-трехгодичных кровавых войн в этих местах распространились смертельно опасные болезни, такие как тиф и холера. «Джизни (Дэрдменд) в эти годы не покидал нас. Чая, сахара не было. Вместо них люди использовали просушенные осенью корочки дынь и арбузов. Он нам приносил чай. Распространились опасные болезни. Мама нас облепила чесночными оберегами. Пили только кипяченую воду. Но это не спасло мою сестру Сару. Ей не было еще и восемнадцати лет. На ее похороны джизни дал нам деньги и привез три тушки овец», – пишет она.
Как отмечает в своем дневнике Мирхайдар Файзи, эта девочка Сара еще пару лет назад очень увлеченно читала стихи со сцены клуба «Шарык». К тому же успешно осваивала и игру на рояле.
Конечно, в последние годы Дэрдменд общался и со своим молодым свояком, мужем Магруй, муллой Ахметзяном Рахматуллиным. И с его другом и земляком (оба выходцы из Атнинского района современного Татарстана) Ахметзяном Нигматуллиным. Их в городе отличали между собой как «Черного» (свояк поэта) и «Рыжего» Ахметзяна. Второй является близким родственником народной артистки Галии Нигматуллиной. Говорили, что мударрис одного из пяти медресе города мулла Ахметзян только в мечети и медресе носил

Җизни безгә чәйләр китергәли иде. Хәтәр авырулар таралды. Әни безне сакларга тырышты, кайнамаган су эчмәскә кушты. Кул, муеннарыбызга сарымсак бәйләмнәре бәйләп куяр иде. Ләкин бу чаралар да Сара апамны саклап кала алмады. Унсигез яше туларак ул тифтан үлде. Аны җирләү көннәрендә җизни безгә акча һәм өч сарык түшкәсе китереп бирде», – дип яза Әсма. Апасының пианинода бик оста уйнавын да искә ала.

Шушы вакыйгадан ике ел чамасы элгәрерәк булган бер хәбәрне дә искә төшереп үтик. «Шәрык» клубында узган бер кичә турында көндәлегенә язганда, Мирхәйдәр Фәйзи дә Сараны бик мактап телгә алган. Ул кызның бик оста, бик матур итеп сәхнәдә шигырь сөйләве күңелгә бик ятышлы булды, дигән. Тик кем әсәрен сөйләгәнлеген генә язмаган.

Орскида яшәү дәверендә Дәрдемәнд, нигездә, приискларына бәйле эшләр белән шөгыльләнгән. Алтын чыгару чыгымнарына дип алынган зур кредитларны, аларны каплар өчен тапшырылган алтынга кагылышлы документларын шундагы чалму. В доме и в гостях у него в руках всегда была мандолина. И на книжных полках у него больше было светских книг, чем религиозных. При людях он любил читать стихи.

Молодой купец Ахметзян Нигматуллин также был активистом при проведении культурных мероприятий в городе. Со многими купцами и другими общественными деятелями участвовал в 1911 году при покупке дома для общественной библиотеки и кинотеатра, был председателем общественного клуба «Шарык». (В этом здании потом до начала 1960 года находился татарский клуб имени 1 Мая.) Когда в 1919 году в городе установилась советская власть, в этом клубе обосновался штаб комиссариата по работе с местным национальным населением. Комиссаром был тоже свой человек – Абдулла Давлетшин из казачьего хутора Ильяс, находившегося в трех километрах от города. До революционных событий он был одним из молодых преподавателей медресе «Хусаиния». Дэрдменд, видимо, его хорошо знал. И он иногда посещал бывший клуб



*Орск шәһәрендәге сәүдәгәр Борнаевлар йорты. Бирегә 1918–1919 елларда Мәхүбҗамал һәм Закир Рәмиевләр яшәгән. Абдулла Исәнбаев фотосы, 1972*

*Дом купцов Бурнаевых в Орске. В 1918–1919 годах здесь жили Махубджамал и Закир Рамиевы. Фото Абдуллы Исанбаева, 1972*

банкларда барлау, тәртипкә китерү мәшәкатьләре булгандыр… Приискларны яңа хөкүмәт вәкилләренә тапшыруны рәсмиләштерү – бу эшләрнең барысын да аңа һәм Искәндәргә башкарып чыгарга туры килгәндер, мөгаен.
1918–1921 елларда, Орскида яшәгәндә, аның яшьрәк буын зыялыларыннан ике Әхмәтҗан белән фикер уртаклыгы тапканлыгын искә алалар. Шәһәрдә танылган мәдрәсә мөдәррисе Әхмәтҗан Рәхмәтуллин – Дәрдемәнднең яшь баҗасы, Маһруй Борнаеваның ире. Орск халкы аны «Мулла Әхмәтҗан», «Кара Әхмәтҗан» буларак искә ала. Мулла Әхмәтҗан мәдрәсәдә генә чалмалы, өендә мандолинада уйнап, җырлап кич утыруларга һәвәс кеше булган, дип сөйлиләр. Шигырьләр сөйләүгә дә һәвәс булган. Ә Әхмәтҗан Нигъмәтуллин, 1911 елда ук шәһәр халкын шаккатырып, кино тамашасын оештыруда катнашкан, китапханә бинасын салышкан заман бае. Аның катнашында ачылган кино йорты соңыннан «Татар клубы»на әверелде.
1920 елларгача ул шунда ук «Шәрык клубы» рәисе булып та тора. Дәрдемәнд, ара-тирә шул «Шәрык клубы» бинасына килеп, төбәктәге милли азчылык арасында эшләргә тиешле яшь комиссар Абдулла Дәүләтшин белән дә аралашкалаган. Бу кеше элек «Хөсәения»дә иң яшь хәлфә булган. Заманча хәбәрдар, Мирхәйдәр Фәйзи абыйсының кызына яңарак кына өйләнгән кияү. Шәһәр янәшәсендәге Ильяс бистәсендә туган егет. Дәүләтшин Орскида 1920 елдан беренче милли газета – «Ирек йолдызы»н чыгара башлый. Атна саен нәшер ителгән ике битле бу газетада әдәбият-сәнгать почмагы да була: шигырь, әдәби парча, мәдәният яңалыклары урнаштырыла анда. Ул елларда ире белән бергә шул газетаны чыгарышкан Хәлимә апа, 1971–1972 елларда Мәскәүдә очрашканда: «Анда Дәрдемәнд әсәрләре басылганын хәтерләмим», – дигән иде. Мөгаен, ул комиссар бүлмәсендәге үзәктән алынган «Шарык» и общался с комиссаром свободно. Давлетшин был женат на племяннице Мирхайдара Файзи, недавней гимназистке Халиме. В 1971, 1972 годах с Халимой-апа я встречался в Москве. Муж, освобожденный в начале 1960-х годов из Сталинских лагерей, не дожил до того дня. Давлетшин с 1920 года в Орске выпускал газету «Ирек йолдызы» («Звезда свободы»). Некоторые номера этой газеты хранятся в городском музее. Еженедельно там помещалась и литературная страничка. Халима-апа помогала мужу в выпуске этой газеты. Но не помнила случая помещения там стихов или других записей Дэрдменда. Он, наверное, посещал этот штаб комиссара для обсуждения положения дел в стране и для ознакомления с поступавшей туда центральной прессой.
…Приближались последние месяцы и недели жизни Дэрдменда.
Писал ли Дэрдменд в это время стихи? Печатали ли о нем что-нибудь на страницах губернских газет? Об этом сегодня ничего не известно, т. к. газеты за период 1919–1925 годов в Оренбурских архивах почти не сохранились. А в те годы там издавались около десяти газет на татарском, башкирском и казахском языках. Большой архив оренбургских изданий казахстанцы тогда увезли в город Кзыл Орду – в новую, после Оренбурга, столицу своей республики. И этими материалами пока никто не заинтересовался. Там могут быть и стихи поэта, и воспоминания о нем.
Озарявшие его вдруг мысли и строки поэт, возможно, и позже записывал. Но их сегодня у нас нет. В Оренбургском доме Рамиевых с середины 1920-х годов поселились чужие люди. Ценную часть библиотеки поэта разобрали, часть старых книг и бумаг сожгли в годы войны…
Осенью 1921 года тиф сразил и старшую дочь поэта Уммугульсум Камалову. Дэрдменд приехал в Оренбург, чтобы проститься с ней

газеталар белән танышу, ил күләмендә барган хәл-вакыйгаларны ишетү өчен дип кенә әлеге «Шәрык клубы»на килгәләгәндер. Бу елларда Дәрдемәнднең шигырь язу-язмавын белүчеләр хәзер юк.
Шагыйрь Дәрдемәнд гомеренең соңгы айлары, атналары якынлаша.
1918–1919 елларның җәй һәм көзендәге зур сугышлардан соң Оренбург төбәгендә тиф, ваба ише йогышлы авырулар киң тарала. 1921 елның көзендә тиф зәхмәте шагыйрьнең олы кызы Өммегөлсемне дә аяктан ега. Дәрдемәнд, кызы белән хушлашырга һәм ятим калган оныклары язмышын хәл итәргә дип, Оренбургка килә. Шул ук Әсма Рәхмәтуллина «анда ризыклар алып китте» дип яза. Дәрдемәнд Өммегөлсем җеназасын чыгаруда катнаша. Кияве Гариф та авыр хәлдә була. Шуннан соң шагыйрь, ике кечкенә оныгын – Кафия белән Галияне ияртеп, Орскига кайтып китә. 1915 елда туган, бабасы белән киткән «зуррак кыз» Кафия апа Камалова-Усманова белән дә хәбәрләштек. «Орскидан сиксән чакрымдагы Сара станциясенә бер иске

и решить судьбу осиротевших девочек, т. к. и зять Гариф был тяжело болен.
Асма Рахматуллина пишет, что «джизни поехал туда с продуктами. Но помочь им уже не смог». Об их возвращении в Орск рассказывала мне Кафия-апа Камалова, третья их дочь. До осени – начала болезни Уммугульсум – их старшая дочь Рабига с сестрой Раузой Яушевой уже была отправлена в Среднюю Азию. (Поездка группы татарской интеллигенции и купцов в начале лета 1921 года описывается в воспоминаниях Таджи Гиззата, в то время являвшегося артистом Оренбургского театра. Он пишет, что, убегая от голода и болезней, они отправились целым составом в Ташкент. Одним из их попутчиков был поэт, в то время ответственный секретарь одной из оренбургских газет Хади Такташ.)
После похорон Уммугульсум Дэрдменд забрал к себе двух маленьких внучек – Кафию и Галию. Кафие, старшей, было тогда около шести лет. Возвращались они в Орск тем же рабочим поездом, каким поэт приехал. Дорога еще не была достроена.



*Беренче рәттә уртада Дәрдемәнднең җәмәгате Мәхүбҗамал балалары белән: сулда кызы Зәйнәп, уңда килене Миңсафа (Искәндәр хатыны); икенче рәттә (уңнан сулга) Искәндәр, уртада Бәшир Искәндәр улы, сулда Кафия (Өммегөлсем кызы)*
*В первом ряду посередине – супруга Дэрдменда Махубджамал с детьми: слева дочь Зайнап, справа сноха Минсафа (супруга Искандера); во втором ряду (справа налево) – Искандер, рядом с ним Башир, сын Искандера, слева Кафия (дочь Уммугульсум)*

вагонда кайттык», – дип сөйләде ул. Тимер юл төзелешенә кирәк-яракны ташучы товар поездына ул елларда бер-ике иске пассажир вагоны тагып йөрткәннәр. Мирхәйдәр Фәйзи дә шундый поездларда йөргәләгәнен искә ала. «Сарадан арбалы атка утырып киттек. Яңгыр яугалап тора иде. Бабай плащын Галия белән икебез өстенә ябып, безне кочаклап алып кайтты», – дигән иде Кафия апа. Галия белән Кафия, бабалары үлгәч, Искәндәр гаиләсендә тәрбияләнәләр. «Миңсафа җиңги мине ашыгыбрак кияүгә бирде. Абый ул вакытта Учалы якларында командировкада иде», – дип, үпкәсен дә белдереп алган иде Кафия апа шул әңгәмә вакытында.
Егерме яшьлек улының, итагатьле Шәрифзадә киленнең һәм олы кызы Өммегөлсемнең фаҗигале үлемнәрен кичерә ул елларда нечкә шагыйрь күңеле. Аеруча соңгы авыр кайгы кичерү, озын юлның мәшәкате, көзге суык Дәрдемәндне тәмам хәлдән яздыргандыр инде. Кайтып бер атна чамасы авырып яткач, 1921 елның

В состав со строительными материалами подцеплялись один-два старых вагона для своих же рабочих и пассажиров. В одном из таких вагонов они и возвращались в Орск. Поезда шли тогда только до станции Сара. От Сары до Орска восемьдесят километров ехали на подводе. «Временами шел дождь, – вспоминает Кафия-апа. – Бабай, посадив нас на колени, прикрывал своим плащом». Потом эти девочки до совершеннолетия воспитывались в семье Искандера. Имеется и несколько фотографий тех лет с их участием.
Эта поездка стала трагическим концом жизни поэта. Чуть более недели проболев дома, он умер 9 октября 1921 года. Пережитое горе, хлопоты долгой дороги, осенние холода совсем обессилили его. М. Гайнуллин пишет, что поэт умер от тифа. В те годы о том же было сообщено и в газете «Башкортстан», издававшейся в городе Стерлитамак (в то время столице Башкирской Автономной Республики).




*1920–1921 елларда Закир Рәмиев гаиләсе яшәгән йорт. Орск*
*Дом, в котором жила семья Закира Рамиева в 1920–1921 годы. Орск*

9 октябрендә Закир Рәмиев-Дәрдемәнд вафат була. Шәһәр янәшәсендәге Ильяс бистәсе зиратына җирләнә. Ул Урал-суның аргы ягындагы үрдә урнашкан. Шәһәрнең хәллерәк кешеләрен элек-электән шунда җирләгәннәр. Чөнки шәһәр читендәге ике зират та Урал елгасы ташыган елларда су астында кала иде. 1957 елда үземә дә Урал-суның дуамаллануын, Иске шәһәр урамнарыннан фәкать «солдат көймәләрендә» генә йөреп булганлыгын күрергә туры килгән иде.
Ильяс бистәсенең зират ягы башына 1941 елда каяндыр «патрон заводы»н китереп утырталар. Дәрдемәнд кабере сугыштан соң әле койма читендәрәк була. Кабер өстендәге истәлек ташын мин әле сугыштан соң рәтләп киткән идем, дип сөйләде миңа 1950 елларда бер абзый. Ул Борнаевлар нәселенә якын кешеләрнең берсе иде. Хәзер ул зират тулаем хәрби завод биләмәсендә калды.
Мәхмүтҗан Борнаевның ике улы иде. Шуларның өлкәне, 1910 елда туганы белән мин илленче елларда Орскида очрашкан идем. Ул шагыйрь бабасы һәм ат йөртүче белән Урал буендагы күлләргә баргалаганнарын, балык тотканнарын сөйләде. Шәһәр белән елга арасындагы урманчыкка (халык телендә «Зауральная роща» дип йөртелә) күмәкләп кич уздырырга йөргәнлекләрен искә алды. «Кайчакларда бабай мине, кучер янәшәсенә утыртып, мәчеткә дә алып баргалады», – дигән иде бу кече Борнаев, 1920 ел вакыйгаларын искә төшереп.

Ун яшьлек Рәшит Борнаев күңелендә калган истәлекләр шагыйрь гомеренең иң-иң авыр чорына туры килгән көннәргә карый. Дәрдемәнд белән Искәндәрнең алдагы елның җәен Юлык төбәгендәге приискларда үткәргәнлеге мәгълүм. Юлыкта гомер иткән Мәрьям апа Рәмиева 1980 еллар башында миңа: «Ул җәйдә алар бездә торып, приискларына бездән йөрделәр», –

Дэрдменда, как и других знатных людей города Орска, часто затопляемого водами Урала, похоронили на кладбище хутора Ильяс, расположенного на возвышенности. Сейчас это кладбище находится в черте Нового Города, на территории одного из заводов. В послевоенные годы надгробный камень на могиле Дэрдменда видели рядом с забором этого завода. Но позднее территория завода расширилась. Могилы многих видных деятелей Орска остались за забором этого предприятия, именуемого в народе «почтовым ящиком № 11». Естественно, сотни надгробных камней, наверное, использовались там при строительных работах. И, может быть, сохранились в нишах множества заборов или в фундаментах зданий.
Ныне в местном музее имеется небольшой стенд – своеобразное напоминание о том, что в этом городе жил татарский поэт Закир Рамиев – Дэрдменд.
Воспоминания десятилетнего Рашида Бурнаева относятся к лету 1920 года.
А предыдущий год Дэрдменд и Искандер провели в селе Юлук, вокруг которого и расположены основные прииски Рамиевых. Об этом в начале 1980 года сообщила мне их родственница Марьям-апа Рамиева.
«В то лето они жили в основном у нас. На прииски выезжали от нас», – говорила она.
Самый сложный период жизни Закира Рамиева – Дэрдменда приходится на середину 1920 года. К этому времени он окончательно расстался со своими приисками, привычным укладом жизни и богатством, нажитым еще и предыдущими поколениями. Это лето было для него временем душевного разлома. Такое его состояние отражено и в двухстрочном стихотворении, приведенном Мухаммедом Гайнуллиным в сборнике поэта за 1959 год. В каждом слове стихотворения чувствуется душевный надлом автора. Он так и пишет: «У Уральского сокола надломаны крылья». Его душа в это время стремится

дигән иде. Закир Рәмиев-Дәрдемәнднең кая барырга, нишләргә белмичә интеккән көннәре 1920 елның урталарына туры килә дә инде. Гомерен багышлаган эшеннән, даими аралашып торган кешеләрдән, ата-бабалары чорыннан бирле тупланып килгән бай мирасыннан аерылган көннәр бит бу. 1959 елда Мөхәммәт ага Гайнуллин туплаган китапка кергән:

Эшәнләнде даланың толпар аты,
Урал шоңкарының сынды канаты, –

кебек, күңел сыкрауларын чагылдырган шигырь юллары да, мөгаен, шул җәйдә, Урал елгасы янәшәсендәге күлләрдә бик кыска гомерле сары төнбоек чәчкәләре чайкалышкан мизгелләрдә тугандыр… Әйе, бу көннәр Урал-тау кыялары өстеннән талпынып очарга күнеккән лачынның канаты сынган көннәр була шул. Мулла вәгазен ешрак тыңларга тырышуы да шул күңеле тынычсызланганлыктандыр… Дөрес, мин Дәрдемәнднең кайсы көндә, соңгы имзасын куеп, барлык мал-мөлкәтеннән ваз кичкән мизгелен ачыклый алмадым. 1970–1980 елларда әле Оренбург, Уфа архивларында алтын табышына бәйле документларны теләсә кем кулына бирмиләр иде. Бәшир Рәмиев әйтүенчә, ул хәл егерменче елның урталарында була. «Әтием шул вакыттан хөкүмәт карамагындагы алтын чыгару эшендә эшли. 1925 елның көзендә аны Баймак бистәсендәге алтын рудасын эшкәртү заводына баш технолог буларак билгелиләр. Без анда, кар төшкәч, берничә чанага төялеп бардык. Без – Кафия, Галия, мин, әбием, үги әни белән бер чанада идек. Ун елдан соң Уфага күчтек. Әтине «Башкирзолото» трестына лаборатория мөдире итеп билгеләделәр. Бу сәяхәт вакытында инде Баймакта туган энем Равил дә бар иде. Мәхүбҗамал әби Баймакта да, Уфада да безнең белән яшәде», – дигән иде ул.
Искәндәр Рәмиев, соңгы вазифасын башкарганда, 1938 елның 14 апрелендә

то на природу, где на озерной поверхности высыпаны яркие цветочки водяных лилий, то в мечеть – послушать успокоительный монолог муллы.
В 1970–1980-е годы я был в архивах Оренбурга и Уфы, хотел уточнить время расставания Дэрдменда со своим прошлым и со своим главным нажитым богатством. Но в те годы документы, связанные с золотодобычей, не всякому выдавались. Позднее, во время встречи с внуком поэта Баширом Рамиевым мы вспоминали данный период жизни деда. Он сообщил, что это произошло летом 1920 года. «Тогда же отец новой властью был официально принят на работу по своей специальности. А к концу лета 1925 года его назначили главным технологом Баймакского медно-золотоплавильного завода. Семья наша – бабушка, мачеха, двоюродные сестры Кафия, Галия и я уже на санях выехали туда же. Через десять лет отца перевели в Уфу – заведующим лабораторией треста «Башкирзолото». И туда мы выехали в том же



*Бәшир Рәмиев – Дәрдемәнднең оныгы, СССР Дәүләт бүләге лауреаты, фән докторы, радиоконструктор*
*Башир Рамиев – внук Дэрдменда, лауреат Государственной премии СССР, доктор наук, радиоконструктор*

«элекке буржуй баласы» буларак кулга алына. 1943 елда Себердә вафат була. 1957 елда аклана. Шул документының күчермәсе миндә бар. 1938 елның җәендә институтның икенче курсын тәмамлаган Бәширне дә укудан чыгаралар.
Шагыйрьнең сөйгән хатыны, авыр көннәрдә сабырлыкка үрнәк булырдай тыныч холыклы Мәхүбҗамал турында да кыскача әйтеп үтик. «Үги әни Миңсафа кырысрак холыклы иде. Элек ул бабамнарда әбиемнең ярдәмчесе – «чәй куючы»сы булган. Анам үлгәч, әтине аңа өйләнергә кыстаучылар да әбием белән бабам була. Безне, өч ятимне, аның кыерсытуларыннан әби саклады», – дигән иделәр миңа Бәшир ага һәм Кафия апа. 1938 елда Искәндәр кулга алынгач, Мәхүбҗамал кызы Зәйнәп фатирына күчеп китә. Аның ире – язучы Ярулла Вәли – 1937 елның җәендә кулга алынган була. Шуннан соң бер хәбәре дә килми. Бу вакытта Зәйнәпнең улы белән кызы буй җиткән булалар инде. Мәхүбҗамал өлкән улы белән бер елда – 1943 елда вафат була. Уфа шәһәре зиратында җирләнә.
Дәрдемәнднең тирән фикергә бай эчтәлекле кабатланмас шигырьләре, халкының бәхетле киләчәге өчен дип кылган изге эшләре мәңге онытылмас. Татар халкының горурлыгы булган шагыйрь Дәрдемәнд рухы күңелләребездә мәңге сакланыр!

составе. И был еще брат Равил, родившийся в Баймаке», – вспоминал он.
Искандер Рамиев как «сын буржуя» был арестован 14 апреля 1938 года. Тем же летом выгнали из института и второкурсника Башира. Искандер умер в лагере в 1943 году. Реабилитирован в 1957 году как невинно арестованный. (Копию этого документа его сын подарил и мне.)
Сообщу в нескольких словах и о судьбе любимой и уважаемой жены поэта – Махубджамал. До ареста Искандера она жила в семье сына, помогала снохе Минсафе, бывшей когда-то в их доме домработницей. (Башир-ага говорил, что бабушка и дед уговорили отца жениться на ней после смерти его матери.) «Мачеха обращалась с нами крутовато, а бабушка нас всегда защищала»,– говорили мне Башир с Кафией. Махубджамал после ареста сына пересилилась в семью дочери Зайнап. Ее муж, писатель Ярулла Вали, был арестован на год раньше Искандера. Исчез навсегда. Их дети к этому времени уже были трудоспособными. Видимо, постаревшей бабушке в этой семье тогда жилось лучше. Умерла она в том же году, что и старший их сын, – в 1943 году. Похоронена в Уфе.
Глубоко национальная, колоритная и отточенно-совершенная поэзия Дэрдменда всё более органично проникает в нашу жизнь. Его добрые дела и неповторимая поэзия навсегда останутся в памяти народа.

*Үзенең коелган корыч кебек өслүбе, тирән мәгънәсе, һичбер шагыйребездә булмаган аһәңе, музыкасы белән татар әдәбиятында бөтенләй аерым ялгыз торган шагыйрь Дәрдемәнд...*

*Галимҗан Ибраһимов*



*Своим стилем, подобным литой стали, глубоким содержанием, благозвучием, музыкальностью поэт Дэрдменд занимает совершенно особое место в татарской литературе...*

*Галимджан Ибрагимов*

*Дәрдемәнд. Ярымфигура. Б. Урманче эше. 1968*
*Дэрдменд. Полуфигура. Работа Б. Урманче. 1968*


ДӘРДМӘНД
ИСӘ ЖИЛЛӘР


Дәрдмәнд


ДӘРДЕМӘНД
МИРАСЫ
ҺӘМ
ХӘЗЕРГЕ ЗАМАН


ДӘРДЕМӘНД
АГАРГАН КЫЛ
ПОСЕДЕВШАЯ
СТРУНА


Дәрдмәнд


ДӘРДМӘНД
Сайланма
әсәрләр


Лирон Хамидуллин
История
татар
в лицах
Дэрдменд


DƏRDMƏND
ƏSƏRLƏRE
„JANALİF"
QAZAN
1929


Лирон Хамидуллин
Зарница на небосклоне


Дәрдемәнд
Дэрдменд


Бертуган
РӘМИЕВЛӘР



...ных сведений виновный в том прив... ...тветственности по всей строгости ...нно-революционного времени.

Ор...кий Городской Отдел Продовольствия.

№

Регистрационная карточка.

Фамилия
Имя
Отчество
кварт
Квартирохоз. комнатн. жил. прислуга.
(ненужное зачеркнуть).

Поименной перечень членов семьи владельца карточки.

| Откуда прибыл. | Фамилия, имена и отчества главы и членов семьи. | Возраст | Род занятий | Чем занимался до 1917 года | В каком профессион. союзе состоит членом. | Какое и где имеет недвижимое имущество. | Категория |
|---|---|---|---|---|---|---|---|





Тартмачык
Шкатулка






Гаиләнең аш сервизыннан көмеш кашык һәм чәнечке. «ЗР» – Закир Рәмиев монограммасы белән
Серебряные ложка и вилка из фамильного столового сервиза семьи с монограммой Закира Рамиева – «ЗР»







*Шагыйрьнең төрки-немец сүзлеге*
*Тюрко-немецкий словарь поэта*




*Дәрдемәнд әсәрләре. Казан. Яңалиф, 1929*
*Произведения Дэрдменда. Казань. Яналиф, 1929*


Здесь с 1890 по 1918 год
жил известный татарский
поэт ЗАКИР САДЫКОВИЧ
РАМИЕВ /ДЭРДМЕНД/
1859-1921




*Шагыйрь йортында мемориаль такта ачу. Сулдан – Дәрдемәнднең оныгы Равил Рәмиев. Оренбург, 1989, 17 май*
*Открытие мемориальной доски на доме поэта. Слева – внук Дэрдменда Равиль Рамиев. Оренбург, 1989, 17 мая*

# Шигырьләр
# Стихи

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар, гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.
Түгеп күз яшьләреңне бу кәгазьгә,
Ни моңлы уйларың бар – сөйлә безгә!

*«Каләмгә хитап»*

## ЯҢГЫР

Көн кызды, кызды һава монарланып[1],
Сагымлап[2], кыр белән дала чобарланып.
Һава тымык - шылт итми!.. Кысылды тын:
Яңгыр көтә җирнең йөзе, комарланып[3]…

Күренде күк йөзендә кара болыт,
Болганып, гайрәт белән ужарланып[4],
Йөгертеп өермәләр, истереп җил,
Ачулы килә атылып, йомарланып…

Ялт! итте яз кылычы, кыеп күкне,
Бушанды күк – яңгырны коеп түкте.
Күк селкенеп украна[5], җир сыгыла,
Нәдер итеп, Ходаемга халык сыгына.

Мал, чулашып[6], уртага алып балаларын,
Баш иярләр, куеп арка җил агына.

Күк ярылып чатырлый, тау шаңгырый,
Шифалы ява коеп яз яңгыры.
Җан-җәнлек, су тавышы тулды җиһан,
Шаулый-гөрли җирнең йөзе, күк яңгырый.

* * *

Ятам кайчаклары моңлап,
Һаваның тынлыгын тыңлап,
Килә өннәр, колак чыңлап.
Диямен:
– Ни бу? Нидәндер бу?
Җавап урынында гөрли су,
Тирәклек тирбәнә, шаулый!..

---

[1] *Монарланып* – һаваның куерып, зәңгәрләнеп һәм ерактан болыт төсле булып күренүе.
[2] *Сагымлап* – куерып, миражланып, буланып.
[3] *Комарланып* – «сусап, зарыгып» мәгънәсендә.
[4] *Ужарланып* – котырынып.
[5] *Украна* – ыңгыраша. Борынгы үзбәк телендә ат кешнәвен аңлата.
[6] *Чулашып* – куркышып.

О перо! Какая тайна на душе – открой,
Расскажи про все, что было
до сих пор с тобой.
Проливая на бумагу слезы из очей,
О печалях нам поведай на душе твоей.

*«Обращение к перу»*

**ДОЖДЬ**

День раскалялся. В воздухе густом
Над степью, полем марево дрожало.
Ни шороха. Дыханье стеснено.
Земля дождя покорно ожидала.

Приплыла туча черная. Вослед,
Сгустив, скрутив, перемешав все небо,
Примчавшийся холодный ветер рвет
И мечет, клокоча от гнева.

Сверкнула молния – весенний меч,
Блеснув, снял с неба напряженье.
Дождь хлынул, прогибая землю, свод,
И люди, прячась, молят о прощенье.

Подставив спины ветру, в середину скот,
Детенышей согнав, сгибает выи.

С расколотого неба с треском льет
Весенний ливень. Реки дождевые,
Свергаясь шумным водопадом с гор,
Несут по свету силы молодые.

* * *

В минуту грустную одну
Лежу, внимая тишину.
И достигает слуха вдруг,
Как будто звон, какой-то звук.
Я говорю:
– Что это? Отчего?
Тогда
На мой вопрос журчит вода,
Дрожит у берега ветла,
Листва шумит.
Шумит листва…

## И МӨХӘРРИР!

Канча[1] тартсаң, и мөхәррир, сүзне чит тел сибенә[2],
Тел ясалмас, гәр туган сүз ятмаса үз ибенә!
Алсаң, ал «сүз»ләрне читтән, «хәреф[3]»ләргә бирмә юл,
Кертмә бер чит ләһҗәдән[4] «хәреф» ләһҗәбез тәртибенә.
«Хәреф»ләр тәбдил[5] итеп, чит ләһҗәдән алмак «әдат[6]» –
Бел, мөсавидер[7] бинаи рухыбыз[8] тәхрибенә[9].
Тел – вөҗүд[10], сүзләр – бәдәндер[11], сарфы[12] вә тәркибе[13] – рух[14].
Максадың гәр хәер исә, куй, тимә тел тәркибенә!
Сөт имешкән һәмдәмемдер[15], кан әнисемдер – телем,
Җан биреп күнмәм хәрим[16] васылдан тәгърибенә[17].
Мөддәгыйләр рәдденә[18] гәр җитмәсә сүзем дәлил,
Түккәнем күз яшьләрем җитсен алар тәэдибенә[19].
Кершән, иннекләр дә яксаң, бер кара тән булмас ак,
Энҗе, алмазлар да булмас «зиштә руга[20] зәйбә ру[21]».
«Булса ак бармакларың нечкә, колагың ал колак,
Алтын алкасыз да син күркәм, йөзексез дә сылу»*,
Тел ватып, «тил»ләрне каттың[22], бер татып күр, нинди тәм:
Биргәнең бер болганык су, салганың ватык сәбу[23]!
Куй, табигать хөкмен итсен – шул тәкамел[24], шунда ямь!..
Көткәнең, бәлкем, «дәлил»дер? Бак, дәлил алдыңда… бу!

* * *

Әгәр барсаң, саба җил[25], безнең илгә,
Сәламнәр әйт, сәлам ул нечкә билгә!
Төшендә юл өчен чәчкәен тарасын,
Гарибнең[26] кайтырыннан фал карасын,
Ходаеннан кавышмаклык сорасын.
Сәламнәр әйт, сәлам ул нечкә билгә!
Дәрийгъ, бер гомер икән сөргән элек без,
Йөрер бергә, көләр, уйнар идек без,
Бу көндә Сак белән Соклар кебек без…
Сәламнәр әйт, сәлам ул нечкә билгә!

---

* «Ике мисрагы Шәйхе Сәгъдидән алынмыштыр». – *Дәрдемәнд искәр.*

[1] *Канча* – никадәр, күпме генә.

[2] *Сибенә* – уңаена, ибенә.

[3] *« Хәреф»* – бу урында «хәреф» сүзе сүзләрнең төрләнешен һәм җөмләдәге бәйләнешен биргән грамматик чара мәгънәсендә алына.

[4] *Ләһҗәдән* – телдән, диалекттан.

[5] *Тәбдил* – алыштыру, үзгәртү.

[6] *«Әдат»* – кушымчалар, бәйлекләр.

[7] *Мөсавидер* – тигездер.

[8] *Бинаи рухыбыз* – телебезнең рухы.

[9] *Тәхрибенә* – харап ителүенә, бозылуына.

[10] *Тел – вөҗүд* – тел – тормыш, барлык.

[11] *Бәдән* – тән.

[12] *Сарфы* – сүзләрнең морфологиясе, төрләнүләре.

[13] *Тәркибе* – телнең синтаксисы, җөмлә төзелеше.

[14] *Рух* – җан.

[15] *Һәмдәмемдер* – сөт туганым.

[16] *Хәрим* – аңа кагылырга тыелган нәрсә.

[17] *Васылдан тәгърибенә* – үз нигезеннән ераклаштырылуына.

[18] *Мөддәгыйләр рәдденә* – дәгъвачыларның сүзләрен капларга, юк итәргә.

[19] *Алар тәэдибенә* – аларны әдәпкә чакырырга.

[20] *Зиштә руга* – ямьсез йөзлегә.

[21] *Зәйбә ру* – йөз бизәге яки «зиба ру» – күркәм йөзле, гүзәл (кыз).

[22] *«Тил» ләрне каттың* – күңелләрне болгаттың.

[23] *Сәбу* – су яки эчемлек савыты, чүлмәк.

[24] *Тәкамел* – тулган, җитешкән, камилләшкән.

[25] *Саба җил* – иртәнге җил.

[26] *Гарибнең* – читтәге ялгыз мескеннең.

## О ПИСАТЕЛЬ!

Подгонять слова под буквы из другого языка
Языку родному пользы не дает наверняка.
Хочешь взять чужое слово – можешь место дать ему,
Не давай дорогу «букве», чуждой слову своему.
Алфавит сменив, и нормы изменять для наших слов,
Знай, что это равносильно разрушению основ.
Знай, язык есть жизнь, слова суть – тело,
а грамматика – наш дух.
Не касайся его строя, если ты не враг, а друг.
Молоком и кровью связан, я родной язык, как храм,
В чистоте хранить обязан, поруганью не отдам.
Но когда для оппонентов не довольно слов моих,
Пусть послужат мои слезы убеждением для них.
Под белилами и пудрой тела черного не скрыть,
«На дурнушке и алмазам украшением не быть».
«Без перстней на пальцах белых и точеных, ты, душа,
Без сережек с жемчугами в ушке алом хороша»*.
Изумляя простодушных, ты под видом «языка»,
Их поишь водою мутной из разбитого горшка.
Пусть природа нас рассудит. Ей доступны лишь одной
Красота и совершенство. Вот они перед тобой.

* * *

Если будешь на рассвете в стороне родной,
Передай приветы, ветер, тоненькой одной!
Пусть во сне расчешет косы. По примете той
Пусть дорогу нагадает милому домой.
Пусть у Господа свиданье вымолит нам с ней.
Передай приветы, ветер, тоненькой моей!
Ах, какая жалость! Нашу жизнь прожили мы.
Всюду вместе были, вместе радовались мы.
Словно Сак и Сок в разлуке изнываем мы.
Передай приветы, ветер, тоненькой моей!

** Оба стиха взяты у шейха Саади. – Прим. Дэрдменда.*

* * *

Нидер, и сөйгәнем, бу яшь күзеңдә,
Ничөн хәсрәт күренде гөл йөзеңдә?
Борынгы шатлыгың юктыр сүзеңдә,
Ничөн хәсрәт күренде гөл йөзеңдә?
Күтәр чәчкәйләрең, күтәр кабагың,
Күренсен күзләрең, көрпә[1] яңагың.
Шифа җилабе[2] бар матур күзеңдә,
Сагышларга дәва – ширин[3] сүзең дә.
Үзеңдә бар икән тирьяк[4] күзеңдә,
Ничөн хәсрәт күренде гөл йөзеңдә?

Фида җаным синең юлыңда, и яр,
Берүк, сау бул, берүк, уйланма, зинһар.
Белалмыйм ниндәен гизлә[5] моңың бар,
Ничөн хәсрәт күренде гөл йөзеңдә?

* * *

Атам-анам йорты өчен
Булса мең җаным фида,
Туган-үскән җирем өчен
Соң тамчы каным фида.

## ЗАМАНА ВАГЫЙЗЫНА[6]

Куеп тор инде, сөйләмә юк-бар гәбеңне,
Өйрән бар әүвәле үз мәзһәбеңне[7].
Җитәр, бакырма, күп белдек, өйрәндек,
Мөселман, кяфер итмәккә[8] шәбеңне!

---

[1] *Көрпә* – йомшак.
[2] *Шифа җилабе* – шифалы су.
[3] *Ширин* – татлы.
[4] *Тирьяк* – тарта, җәлеп итә торган көч.
[5] *Гизлә* – сагышлы, яшерен.
[6] *Вагыйзына* – үгетчесенә.
[7] *Үз мәзһәбеңне* – үз динеңне, үз юлыңны.
[8] «Берәүләрне динле, икенчеләрне динсез дип печать басып утыруда» мәгънәсендә.

* * *

Что, милая, во взоре твоем ясном?
Какая мука на лице прекрасном?
В речах твоих веселие угасло.
Какая мука на лице прекрасном?
Повыше волосы поднявши, заколи ты,
Открой глаза и юные ланиты.
В глазах твоих есть блеск животворящий.
В речах лекарство от тоски щемящей,
Противоядие от чар опасных,
Но что за мука на лице прекрасном?

Я, жертва на пути твоем, не знаю,
Какая тайна дух твой омрачает.
Пожалуйста, не мучь себя напрасно.
Какое горе на лице прекрасном?

* * *

Будет нужно, тысячу жизней
Отдадим за отчий кров.
За родную землю жертва –
До последней капли кровь.

**СОВРЕМЕННОМУ НАСТАВНИКУ**

Довольно, хватит, слышим долго.
Сперва найди дорогу сам.
Горазд кричать, сбивая с толку
На путь неверных мусульман.

## АЛЛАГА ТӘВӘККӘЛ!

*(Сыҗым Колыйдан)*

Абындым, таяндым, дидем: Аллага тәвәккәл!
Һәр төскә буяндым, дидем: Аллага тәвәккәл!
Куйдым башымны кулларым өстенә дә яттым,
Үлектәй узандым[1], дидем: Аллага тәвәккәл!
Уянды сорнай[2], кучте торып бөтен кәрваннар,
Мин күчтем, юлландым, дидем: Аллага тәвәккәл!
Иң арттагылар килде, кичте таптап алар да,
Тузанга болгандым, дидем: Аллага тәвәккәл!
Телем-телем телендем мин, искергән җиләндәй,
Йөз ямау ямандым, дидем: Аллага тәвәккәл!
Атларга – печән, этләргә – сөяк, малга җим булдым,
Канча[3] кем таландым, дидем: Аллага тәвәккәл!
Керләнде чалмам, уңды бүркем, шапкам кызарды,
Һәр төскә буяндым, дидем: Аллага тәвәккәл!

## БУЗЛӘРЕМ МАНАЛМАДЫМ

Гәрчә мин дә бар саналдым,
Ил катар[4] саналмадым,
Илдә йөрдем, хазлар алдым[5],
Уйласам – сан алмадым!

Янды Мәҗнүн, янды Фәрһад[6], –
Бер янып ат алдылар,
Мин, гариб, мең кат янып та –
Яндыга саналмадым;
    Уйлагыз: мәгъшука меңнәр!..
    Мин гашыйк саналмадым!

Кемгә васләт[7], кемгә өмид
Нигъмәтен бирде фәләк[8],
Мин өмиднең сул кулыннан
Бер сынык нан[9] алмадым.
    Кемгә васләт, кемгә өмид!..
    Мин сынык нан алмадым!

[1] *Узандым* – сузылдым.
[2] *Сорнай* – озын торба, быргы.
[3] *Канча* – ничаклы.
[4] *Ил катар* – ил эчендә.
[5] *Хазлар алдым* – өлеш алдым.
[6] *Мәҗнүн белән Фәрһад* – Навои әсәренең гашыйк геройлары.
[7] *Васләт* – кушылу, кавышу.
[8] *Фәлә к* – язмыш.
[9] *Нан* – икмәк.

## ХВАЛА АЛЛАХУ!

*(Из Сижима Кулыя)*

Споткнулся, устоял и говорю: хвала Аллаху!
Окрасился во все цвета, сказал: хвала Аллаху!
Лег головою на руки и, ноги протянувши,
Как мертвый, с упованием сказал: хвала Аллаху!
Зурна взыграла, поднялись, пошли все караваны.
Я тронулся в дорогу, уповая: хвала Аллаху!
Шли задние. Они прошли, топча и напирая.
Я, залепленный пылью, говорю: хвала Аллаху!
Как старый рваный плащ, лоскутьями висящий,
Залатанный стократ, я говорю: хвала Аллаху!
Стал сеном лошадям, собаке костью, птице кормом.
Истерзанный до крови, уповал: хвала Аллаху!
Испачканы чалма и бурка, шапка покраснела,
Во все цвета окрасился, сказал: хвала Аллаху!

## НЕ ОТБЕЛИЛ НА САВАН БЯЗИ

Хоть и значился в отчизне,
Но признания не знал.
В доле был, страну объездил,
Славы не завоевал.

От любви пылал однажды
И прославился Фархад,
Как Меджнун. А я безвестно
На костре сгорал стократ.
        Только вдумайтесь: безвестно
        От любви сгорал стократ!

Кому встреча и надежда,
Кому счастье и покой.
Не дала судьба мне крохи
Хоть бы левою рукой.
        Кому счастье, кому радость,
        Мне и крохи ни одной.

Әйттеләр, кем, бер бәхетсез
Илгә гашыйксың, фәкыйрь.
Бер кызардым, бер бүзәрдем[1]...
Ни таныйм – таналмадым!
...ни таныйм?.. Таналмадым!

Сезне, милләт кызлары, аһ!
И өмид йолдызларым!
Таң сәхәрләр эзләп-эзләп,
Бер күреп каналмадым[2].
...и өмид йолдызлары!..
...бер күреп каналмадым!

Иске җилләр ил эченнән,
Иртә-кич салдым колак,
Җил-җиләсләрнең моңыннан
Зәүкы әлхан[3] алмадым.

Кайда бер тау, кайда мәэмүл[4]
Чишмәи әбелхәят[5]!
Тез йөгендем, яшь тамыздым, –
Дәрткә дәрман алмадым.
...дәрткә дәрман алмадым!

Биэре милләт[6], маэи зәмзәм[7]
Күзләдем еллар буе,
Җитте дәфенем вакыты[8],
Кәфнем бүзләрен маналмадым.
Вәйла[9]!..
Дәрийгъ[10]!
Бүзләрем маналмадым!!

[1] *Бүзәрдем* – агардым.
[2] *Каналмадым* – туйганчы күрә алмадым.
[3] *Зәүкы әлхан* – көй ләззәте.
[4] *Мәэмүл* – булуы күздә тотылган урын.
[5] *Чишмәи әбелхәят* – мәңгелек суы чишмәсе.
[6] *Биэре милләт* – милләт коесы.
[7] *Маэи зәмзәм* – зәмзәм суы.
[8] *Дәфенем вакыты* – күмелер вакытым.
[9] *Вәйла* – никадәр үкенеч.
[10] *Дәрийгъ* – аяныч.

Говорили мне: несчастный,
Ты влюблен в страну свою.
Я краснел, бледнел. Напрасно:
Мне ли скрыть любовь мою?
    Мне ль скрывать любовь мою?

Девы нации! Вы – звезды
И надежд ее, и дел!
Я искал вас на просторах,
Наглядеться не успел.
    Звезды нации! Надежда!
    Наглядеться не успел.

Ветры времени гудели,
Днем и ночью я внимал,
В звуках этих и мотивах
Наслажденья не познал.

Под горою на коленях
Со слезами заклинал,
Струи чистых вод земзема
Я для нации искал.

Много лет искал колодец,
Страсть мою не утолил.
Час настал – на саван бязи
Для себя не отбелил.
    Вай!
    Какая жалость! Бязи
    Для себя не отбелил.

*Шигырьгә иллюстрация. Рәссаммы Б. Урманче. 1968*
*Иллюстрация к стихотворению. Художник Б. Урманче. 1968*





چوقکلاغان آق اتکه تولپار توگل ١٩٦٤

## САБЫЙ

*(Шигъре мәнсүр)*[1]

Бәхетле сабый!
Карагыз: ниндәен рәхәт, никадәр дә
татлы йокы эчендә!..
Бөтен вөҗүден ниндәен матур тынычлык каплаган!
Күкрәккәен бер кабартып, бер төшереп,
күркәм тын алуларын, көрпә йөзкәендә
җилбер-җилбер уйнаган көлемсерәүләрен,
һәнүз тупрак өстенә тиелгән кечкенә
тәпкәйләрен күргәнегездә, гүя бер фәрештә,
күк йөзендә оча-оча, канаткайлары талган да,
җир йөзенә төшеп, бу бишекнең эчендә яткан
калган дип әйтәсегез килмәсме?..
Бәхетле сабый! Йокла!
Синең һәрдаим тынычлык эчендә калуыңны
теләгән шәфкатьле әнкәеңнең күзе алдында
рәхәт-рәхәт йокла!
Син, өлкән адәмнәр кебек, уянсаң – зәхмәтле эшләр,
йокласаң – имәнеч төшләр күрмисең.
Уяныр-уянмас әнкәеңнең йөзенә карап көлүдән
башка һич эшең юк.
Һәм никадәр дә күркәм, татлы көләсең!
Әнкәең никадәр арыган, никадәр талган булса,
янә шул матур көлүләрең аның бар кебек
мәшәкатьләрен оныттырадыр.
Синең көләр йөзкәеңне күргән саен,
әнкәеңнең дә йөзе көлеп, йөрәгендә
бер шатлык, бер сөенеч пәйда буладыр.
Шундук сине шәфкатьле кочагына ала,
күкрәгенә баса, сиңа ашналыклар күрсәтә.
Син дә, аңа җавап урнына, күркәм-күркәм
көләсең һәм, татлы-татлы имәргә башлап,
туйганыңча имәсең. Бу хәлдә янә әнкәеңнең
йомшак кочагында сирпелеп йоклаудан
башка эшең калмый.
И бәхетле сабый! Йокла!
Синең һәрдаим тынычлык эчендә калуыңны
теләгән шәфкатьле әнкәеңнең күзе алдында
рәхәт-рәхәт йокла!..

[1] *Шигъре мәнсүр* – чәчмә шигырь (нәсер).

## ДИТЯ

*(Стихотворение в прозе)*

Счастливое дитя!
Взгляните: как покойно,
как сладко оно спит!
Каким умиротворением овеяно все его существо!
Когда вы видите, как, красиво поднимая и опуская грудку,
дышит малыш, как на прелестном его личике
играет подвижная улыбка,
смотрите на его маленькие ножки,
еще не касавшиеся земли,
не кажется ли вам, что это ангел,
налетавшись в небе, утомил свои крылышки и,
опустившись на землю, остался в этой колыбели?..
Счастливое дитя! Спи!
Спи сладко-сладко
на глазах своей любящей матушки,
желающей твоего покоя!
Ты не увидишь, подобно взрослым, мучений во сне
и тяжелых дел наяву.
Едва проснувшись, нет тебе другого дела,
как радостно глядеть в лицо твоей матушки и улыбаться.
До чего же красиво и счастливо ты улыбаешься!
Какой уставшей, утомившейся ни была бы твоя мама,
от твоей улыбки
она забудет все свои заботы.
Каждый раз, когда она видит твое веселое личико,
она улыбается сама,
и радость и счастье охватывают ее.
Она тотчас берет тебя в свои объятья,
прижимает к груди и выражает свою любовь.
А ты отвечаешь ей радостным смехом
и принимаешься быстро-быстро,
досыта сосать. После этого тебе ничего не остается,
как, разметавшись в мягких материнских объятьях,
засыпать.
О счастливое дитя! Спи!
Спи сладко-сладко
на глазах своей любящей матушки,
желающей твоего покоя!

* * *

Утырган бер егет, янда егетләр,
Оча атлар, чаба, чәчри күбекләр.
Бу якларга карап килгән кебекләр!..
Торып, көзге карап, зиннәт тагынды,
Гаҗәп: кемне көтә, кемне сагынды.

* * *

Тиң булырмы йолдыз тулган айга,–
Ул буйга-сынга, ачык чырайга.
Ымтылган иләк кебек йөрешләре,
Ул моңлы, матур күз сөзешләре.
Ялвару кирәкмәс, кирәк наз гына,
Ул да урыны белән, аз-аз гына.

* * *

Түкте кояш нурларын алтын-сары,
Тауларның бетте эреп салкын кары.
Күтәрелде күк йөзенә сабан тургай,
Ишетелде чырлап түккән моңлы зары.

* * *

Ачылды, кар эреп, таулар, тугайлар.
Суык көннәр үтеп, кышлар да бетте.
Исән җаннар күрер тиз якты айлар,
Биш-ун көннән мона майлар да җитте.

* * *

Таулы матур илләрендә
Гөрли агым сулары;
Тонык ялтыр күлләрендә
Каңгылдый аккулары[1].

[1] *Аккулары* – аккошлары.

* * *

Подле все, джигит к джигиту, ждут, сидят.
Мчатся кони, хлопья пенные летят,
Словно будто в эту сторону глядят.
        Встала к зеркалу, надела украшенья.
                                        Для чего?
        Странно: словно стосковалась, ждет кого…

* * *

Как звезда луне на небе не чета,
Не сравнить другую с нею никогда:
Ясный лик и эти взоры, и уста,
Шаг порывистый и стройный гибкий стан.
Не с мольбою к ней, лишь нежностью,
                                        но пусть
Только к месту, временами и чуть-чуть…

* * *

В лучах от солнца желто-золотистых
Растаял на горах холодный снег.
Пронзительную песнь из поднебесья
Льет жаворонок жалостно на всех.

* * *

Растаял снег, и обнажились горы,
Освободился от зимы тугай.
Кто жив, уже увидит лето скоро,
Пройдет пять-десять дней, и будет май.

* * *

В стране красивых скал и гор
Потоки бурные шумят.
На глади глянцевой озер,
Сбираясь, лебеди кричат.

* * *

Көлемсерәп, көн башланды
Җәйге күркәм таң белән;
Япраккайлар да яшьләнде,
Һәм тибрәнде кук үлән.

* * *

Чыкты кояш, кызарып, нурлар очты,
Бизәнде тау, бизәнде кыр, гөлләр үсте.
Һава тымык, шылт итми… үләннәр – чык,
Җым-җымылдап уйныйдыр җирнең өсте.

## ЯЗ

Яз булды, нисан[1] ява пыскып, карлап,
Таулардан сулар ага гөрләп, шарлап.
Каңкылдап килде аккош белән казлар,
Кайнады кош, тулды күл, тулды сазлар.
Язларның килде җитеп якты көне,
Ишетелде һавада аккош өне,
Талпынып салмак, авыр күк йөзендә,
Күренде килгән очып каз дөркеме.
Яз булды, җитте килеп хозур айлар,
Сайрап очты һавага бүз тургайлар,
Рәхәтләнеп маңгырый куй, сыер мөңри,
Куанып, кешнәп уйный колынкайлар.
Куанып йөгерә киек иркен чүлдә,
Каңкылдап, аккош йөзә аукан[2] күлдә,
Сайраша сандугачлар, түгеп моңнар,
Хайваннар шатлык кыла уңда-сулда.

[1] *Нисан* – апрель ае яңгыры. Халыкта «ләйсән яңгыр» дип тә йөртелә.
[2] *Аукан* – иркен.

* * *

Утром с летнею зарею
День начался, улыбаясь.
Прослезились листья. Травы
Голубые колыхались.

* * *

Под красными лучами солнца
Преобразились горы, степь.
Цветут цветы,
Ни дуновенья.
И лишь роса, перебегая,
Играет на лице земли.

**ВЕСНА**

Пришла весна. Сочится небо: дождь и снег.
Потоки горные, бурля, стремят свой бег.
Прибыли лебеди и гуси, гогоча.
Кишат озера и болота, все кричат.
Настал весны прозрачный, ясный миг,
Звенит под небом лебединый крик.
Домой из теплых возвращаясь стран,
Проследовал гусей усталый караван.
Весенних месяцев чудесная пора:
Трель жаворонка с самого утра,
Мычит корова, блеют овцы на дворе,
Ржет жеребенок, радуясь игре,
В степи просторной радуется зверь,
Друг с другом лебеди на озере теперь,
Общаясь, голосят. Настал час соловью.
Вся живность радость празднует свою.



*«Без» шигыренә иллюстрация. Рәссамы Б. Урманче*
*Иллюстрация к стихотворению «Мы». Художник Б. Урманче*



*Шигырьгә иллюстрация. Рәссамы Б. Урманче. 1968*
*Иллюстрация к стихотворению. Художник Б. Урманче. 1968*

## ХӘЯТ

### I

Бакчы, уенын башлаган, күңелен биргән курчагына,
Күр бәхетсезлекне: тап килдем вакытсыз чагына.
Уйнасын күңлен ачып, гаеп итмә, зинһар, и күңел,
Ним сабыйдыр[1] ул сабыйлык көннәрен бик сагына.
Санкем[2] угыл, кыз туен итмәктә ул, кызган уен,
Йөгерешеп, курчак төшеп менмәктә ак бармагына.
Чөнки мәшгульдер үзе, кылды ишарәтләр күзе,
Гамьле күңлемнән кибет ачтым, кичеп бер ягына.
Сорды ул гөл: – Кем, нидер сәүда?.. Дидем: – Сәүдаи гыйшык[3]!
Тамды гөлләр, түкте ул дөррләр[4] – «Керәм уртагына!..»

Уен өчендер сүзләре гәр, саф күңелдер, уены чын;
Күрче: курчакларны куйды, алды хушбуй, ягына.
Очмак өчендер мәхәббәт багына[5] ул гандәлиб[6],
Чәч тарап, көзге карап, санкем канаткай кагына.
Сидкы вә ихласым[7] өчендер кем ачып төш агъзыма,
Сакланып сүздән, яман күздән бөтиләр тагына.
Бер тамаша кыл күңел кем, җиргә беткән гөл түгел,
Чын мәхәббәт гөлләредер кунды тәнкәй агына!..

### II

Сәер итеп күр, канча сонгыять[8] сарыф итеп дәст әзәл[9],
Ни бәдаигъларны[10] төзде, тезде хөсне багына[11].
Илтимас итмеш абәдкем[12] (чөн будыр хөкме самад[13]!),
Гыйшкы багыннан кичеп үтсен җиһан чардагына.
Ул калын ил кем гадәмдән сил булып[14] килмәктәдер,
Шәвыкләр[15] бирмәктә әлдән бу вөҗүд ирмагына.
Ул гасырларкем һәнүз көтмәктәдер зәүкый хәят[16],
Шәвыкләрдер бу әсир төшкән килеп чәчбагына[17].
(Шәвыкләр кем һәрбере бер дәвернең солтаныдыр,
Сан тезелмешләр көтеп нәүбәт, менеп калфагына.)
Хикмәте – хөкме кадәрдән[18] вә хәбәр булсаң әгәр,
И күңел, тап чара, өстә яра, гыйшкы дагына.
Гыйшкы җәннәтдер морад итсәң хәят җавидан[19],
Кер аңа вә кермә ул мәрдүд фәна[20] япрагына.
Дәрд, гыйшык нирванә шәмгы[21],
«Дәрдемәнд» пәрванәсе[22],
Ул канып күчте, янып кичте бәка[23] тупрагына.

---

[1] *Ним сабыйдыр* – ярым сабыйдыр.
[2] *Санкем* – әйтерсең лә, гүя.
[3] *Сәүдаи гыйшык* – гыйшык сәүдәсе, гыйшык уты.
[4] *Дөррләр* – энҗе, асылташ бөртекләре.
[5] *Багына* – бакчасына.
[6] *Гандәлиб* – сандугач, былбыл.
[7] *Сидкы вә ихласым* – чын һәм саф күңелем.
[8] *Канча сонгыять* – ничаклы осталык.
[9] *Дәст әзәл* – табигать (язмыш) кулы.
[10] *Ни бәдаигъларны* – ничаклы бизәнү, төзәнү әйберләрен.
[11] *Хөсне багына* – матурлык бакчасына.
[12] *Илтимас итмеш абәдкем* – мәңге чиге булмаган вакытның теләге.
[13] *Чөн будыр хөкме самад!* – югары көчнең хөкеме шулай!
[14] *Гадәмдән сил булып* – билгесез яткан ташкын булып.
[15] *Шәвыкләр* – кызыгулар, бу урында «өмет» мәгънәсендә килә.
[16] *Зәукый хәят* – тормыш ләззәте.
[17] *Чәчбагына* – чәч үргеченә.
[18] *Кадәрдән* – тәкъдирдән.
[19] *Җавидан* – мәңгелек тормыштан.
[20] *Мәрдүд фәна* – ташланган, бетә торган.
[21] *Нирванә шәмгы* – шәм яктылыгы.
[22] *«Дәрдемәнд» пәрванәсе* – «Дәрдемәнд» гыйшык уты тирәсендә очкан күбәләк.
[23] *Бәка* – мәңгелек.

## ЖИЗНЬ

### I

Погляди, взялась за куклу, а с какой играет страстью!
Как не вовремя случился я в ту пору, на несчастье.
Не тревожь, пускай забаве предается всей душою,
То полудитя у детства остается в нежной власти.
В самый раз игра в разгаре, куклы в пальцах так и ходят,
У любимой куклы свадьба, нужно свадебное платье.
Мне, по занятости крайней, подала лишь знак глазами,
Примостился только с краю, чтобы душу рассказать, я.
– Чем терзаешься? – спросила. Говорю: – Любовной мукой.
Занялась, мой свет: – Играю! Принимаю я участье!
Погляди, задвинув кукол, за духи взялась серьезно,
Упорхнуть в сады готова к соловьиному причастью.
Перед зеркалом, как крылья, распустила длинны косы,
От дурного глаза, слова талисман скрепил запястье.
Не цветок, земле и тленью обреченный. Полюбуйся:
То на белом ее теле расцвела любовь для счастья.

### II

Посмотри, с каким искусством вечность, сад свой создавая,
Разместила в нем красоты совершенного творенья.
Волей вечности и властью Высшей мудрости и силы
Пусть взойдет на небо жизни вертограда вдохновенье.
Низвергаясь к нам потоком из пустыни мирозданья,
Да наполнит жизнь порывом дерзновенного стремленья!
Вдохновение и страсти – нынче узники у жизни,
В них столетьями природа утоляла наслажденье.
(За одной другая страсти миром правили веками,
Приводя султанов к цели их глухого вожделенья.)
Разломать печать печали и любовных мук старайся,
О душа, когда открыта ты для воли провиденья.
Если хочешь вечной жизни, этот рай – любовь и счастье.
Там живи, по бренным листьям не ходи в страну забвенья.
Страсть любви есть огнь палящий, мотылек «Дэрдменд»,
сгорев в нем,
В прахе вечности бессмертной обретается без тленья.

* * *

Аның янында кичкән котлы көндә
Гаҗәп ләззәтле төшләр күрдем өндә.
Хәзин[1] гомрем чүлендә санкем ул – көн:
Ачылды күк-капу золмәтле[2] төндә.

* * *

Кил, җитеш тиз, кил, җитеш,
И сөйгәнем, зармын сиңа.
Сак белән Соклар кебек,
Күптән өмиддармын сиңа.

* * *

Көләрсең, көлдерер, шатландырырсың,
Сөярсең, сөйгәнем, һәм сөйдерерсең.

* * *

Яшүсмер күңелеңи дәртләндерәсең,
Сөярсең, сөйгәнем, һәм сөйдерәсең.

* * *

Сөләйманны җиңә Бәлкыйс аягы,
Мисырның тәңресен – Муса таягы.

* * *

Нидер, иркәм, бу кадәр үз-үзеңне хур иткәнең –
Күңлемә хуш килмәде ак йөзең акбур иткәнең!

---

[1] *Хәзин* – кайгылы, хәсрәтле.
[2] *Золмәтле* – караңгылы.

* * *

В благословенный, с нею проведенный день
Я грезил наяву, витая в снах:
Как будто небо расступилось надо мной
В пустыне жизни на моих глазах.

* * *

Приходи скорей, тоскую,
Жду, любимая, тебя.
Словно Сак и Сок, живу я
Лишь надеждой на тебя.

* * *

Дашь рассмешить себя, обрадуешь и будешь,
Милая, любимой и полюбишь.

* * *

Обрадуешь, любимая, и радоваться будешь,
Любить заставишь и сама полюбишь.

* * *

Как ножкою Балхис сражен был Сулейман,
Так посохом Мусы — все боги египтян.

* * *

Что ж ты мелом портишь, милая,
И без мела лицо белое?

* * *

Кичә-көндез өмиддармын[1] сиңа,
Сак белән Соклар кебек зармын сиңа.

## КЫЙТГА

*(Тәмам булмаган бер әсәремнән)*

Чәчеп сүз дөрләрен[2], и килке мәгъмүм[3],
Күңел җан-җирләрен ачып, төхем[4] күм!
Бетеп гомереӊ, итеп күмгәч үзеңне,
Итәрләр хирзе җан[5] күмгән сүзеңне.
Түгеп моңнар, туган көйләрне көйлә,
Янып, шәйда[6] күңел көйгәнне сөйлә.
Агыз яшьләрне, кыл төшләрне ирва[7],
Бетеп, җир-җир буй атсын нәхле сәүда[8]?
Караңгы төн исә якын, ераклар,
Хәзин кальбемне[9] вакла – як чыраклар:
        Гарибләр[10], шамчырак күргәндә юлда,
        Дисеннәр, берзаман бар булган ул да…

## КАЛӘМГӘ ХИТАП

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар – гаян ит[11],
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит[12].
Түгеп күз яшьләреңне бу кәгазьгә,
Ни моңлы уйларың бар – сөйлә безгә!
Бабалар кабере янында күңел зар,
Аталар рухының армандасы[13] бар…
Кара туфрак тулы мазлум нидасы[14],
Алар кемдер?.. Алар кемнәр фидасы[15]?..
Каләм! Кальбеңдә ни сер бар, гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален – бәян ит.
Түгеп күз яшьләреңне бу кәгазьгә,
Ни моңлы уйларың бар – сөйлә безгә!

---

[1] *Өмиддармын* – өмет баглаучымын.
[2] *Сүз дөрләрен* – сүз җәүһәрләрен.
[3] *Килке мәгъмүм* – сагышлы камыш каләм.
[4] *Төхем* – орлык, йомырка.
[5] *Хирзе җан* – җанны саклый торган тылсым.
[6] *Шәйда* – гыйшык диванасы.
[7] *Ирва* – сугару.
[8] *Нәхле сәүда* – гыйшык күбәләге.
[9] *Хәзин кальбемне* – хәсрәтле күңелемне.
[10] *Гарибләр* – бу урында «интегеп килүче юлчылар».
[11] *Гаян ит* – мәгълүм ит, ачып сал.
[12] *Әхвален бәян ит* – хәлләрен сөйләп, хикәя итеп бир.
[13] *Армандасы* – үкенечле өмете, теләге.
[14] *Мазлум нидасы* – кыерсытылган, җәберләнгәннәр тавышы.
[15] *Фидасы* – корбаны.

* * *

День и ночь тобой живу я,
Словно Сак и Сок тоскуя.

## КЫЙТГА

*(Из незавершенного произведения)*

Жемчугами слова, скорбное перо,
Разрыхливши душу, заложи зерно!
Когда, век свой кончив, в землю ляжешь сам,
Прорастет из зерен слово-талисман.
Изливая звуки родины святой,
Душу страсти жгучей остужая, пой.
Слезы проливая, орошаешь сны,
Да цветут по землям дерева любви!
Огонек надежды засвети в ночи,
Из души иссохшей наստругав лучин.
Бедный путник скажет, увидав огонь:
Был на этом свете некогда и он!

## ОБРАЩЕНИЕ К ПЕРУ

О перо! Какая тайна на душе – открой,
Расскажи про все, что было до сих пор с тобой.
Проливая на бумагу слезы из очей,
О печалях нам поведай на душе твоей.
Близ надгробий дедов в сердце –
скорби горький след,
Дух отеческий взывает к нам хранить завет.
Полон ропота и жалоб на могилах прах.
Кто они? Чьей жертвой пали? Кровь на чьих руках?
О перо! Какая тайна на душе – открой,
Расскажи про все, что было до сих пор с тобой.
Проливая на бумагу слезы из очей,
О печалях нам поведай на душе твоей.

## ТАЛ ЧЫБЫК

*(Ислах[1] сораган шәкертләргә тартамын)*

Ничөн суга сузыласың,
Тал чыбыккай, интегеп;
Ялварасың, борыласың,
Тилмерәсең, өзеләсең,
Аккан суга күз тегеп.
Япракларың кылтырый…
Эчеп канасың[2] килә!
Йөгрә-кача, су чылтырый,
Кояш нурында елтырый
Һәм кача ул, һәм көлә!

## ЯЗ ЧӘЧӘГЕ

*(Мәдрәсәи «Мөхәммәдия»гә тартыладыр)*

Килер-килмәс борын гөрләп матур яз,
Ничек бөктең, умырзая, билеңне?
Исәр-исмәс икән таңда җил,
Ничөн кызганмадың, түктең гөлеңне?

* * *

Кичә күр, иркәм, нидер иткәннәрем,
Гамь заманында[3] яман әйткәннәрем.
Күргәнең миннән яфаларны оныт –
Әйләмә яд[4], ул хафаларны оныт!
Әмма шул көннәрне, кем, булган иде,
Гыйшык илән моңлы күңел тулган иде.
Уйнашыр, уйнар идек без мәңгү шад,
Шул заманнарны онытма, әйлә яд!

---

[1] *Ислах* – реформа, уку-укытуны яңарту.
[2] *Канасың* – туясың.
[3] *Гамь заманында* – кайгылы чагымда.
[4] *Әйләмә яд* – искә төшермә, телгә алма.

## ИВА

*(О шакирдах, ждущих реформы)*

Что ж ты, ива, гнешься-маешься,
Над водою все сгибаешься,
Глаз не сводишь, не насмотришься,
Как течет вода, хлопочешь ли
Напоить листочки бледные,
Трепещат на ветках бедные…
А вода течет и плещется,
Убегает, где-то прячется
И играет, и смеется,
Блещет, светится на солнце.

## ВЕСЕННИЙ ЦВЕТОК

*(О медресе «Мухаммадия»)*

Что ж, подснежник, не дождался
Дней погожих и сломался?
Что ж ты, ветер, на рассвете
Погубил цветок в расцвете?

* * *

Прости мне, милая, слова,
Что в пору горькую сказал.
Все, чем обидел, позабудь,
Не помни зла и доброй будь.
Но дни, которые прошли
В любви и в радости текли,
В веселье, играх – вспоминай
И никогда не забывай!

## УРАМ ЕГЕТЛӘРЕНӘ

Чамасы, гыйльме шәп матур егетнең,
Кай эчке – кайда барыннан хәбәрдар.
    Эчендәген беләшешә тышыннан –
    Өнәр бар ирдә, бакчы, зур өнәр бар!

* * *

Гариб моң[1] бар өнендә җил-җиләснең –
Туган илләрдән искән җил димәссең.

* * *

Гөрләсә су, чыңраса акку, һаваларда очып,
Агъласа айрым болыт – яшьләр түгеп, тауны кочып…

* * *

Язып терсәк, басып куллар бөергә,
Курай салмагына басып биергә!

* * *

Агышың, и агымсу, туп-тулы зар,
Синең ни хәсрәтең, ни моңнарың бар?..

* * *

Кил, и дустым, хафа булма – бетәр бу;
Килер бер көн – китәр хәсрәт, үтәр бу!

---

[1] *Гариб моң* – чит-ят моң.

**ЗАВСЕГДАТАЯМ УЛИЦЫ**

Хорош собой, толковый парень:
В напитках крепких знает толк.
Он содержимое бутылки
По виду угадать бы мог!

* * *

Есть чуждый отголосок в звуке ветра,
Как словно не с родных просторов это.

* * *

Журчит ручей, клич лебединый стынет в небе,
Обняв утес, оплакивает тучка жребий.

* * *

Под звучание курая,
Подбоченясь, выступаю.

* * *

Вода, в твоем журчании одно роптанье!
Какое горе у тебя? О чем страданье?

* * *

Не грусти, мой друг, все минет,
День настанет – горе сгинет.

* * *

Исәрме яз җиләс җилләр,
Килерме җәй, чәчеп гөлләр.

* * *

Сыгылдырып күл камышын, җилләр исә,
Яз үтә, көзләр җитә, еллар кичә.

* * *

Тегәп моңлы күзем күкнең йөзенә,
Хикәя сөйләдем айның үзенә.

* * *

Ничә багълар күңелләрдә төзелде,
Сары юллар булып гамьләр сызылды.
Өмидләр, кем, менеп башка тезелде,
Агарган кыл кебек, бер-бер өзелде.

* * *

Булат такмый кәмәрләгән конан[1] бил,
Тази[2] атлар җалын какмый биә[3] җил.
Өшәнләнде даланың толпар аты,
Урал шоңкарының сынды канаты.

* * *

Җитәр инде, Дәрдемәнд, сүзне озатма,
Катып кунган күңелләргә боз атма!
Дилең[4] өчен телең булсын тозаклы,
Йөз аклыгың өчен – аузың йозаклы!

[1] *Конан* – нәзек.
[2] *Тази* – йөгерек.
[3] *Биә* – бии.
[4] *Дилең* – күңелең.

* * *

Придет весна со свежим ветром,
Цветы покроют землю летом.

* * *

Камыши под ветром гнутся,
Весны, годы пронесутся.

* * *

Воздев с тоскою к небесам глаза,
Печаль свою луне я рассказал.

* * *

Садами бредил я, их в мыслях создавая!
Печалей желтые дороги протянулись,
Надежды, угодить спеша, вернулись
И лопнули, как струны, за одной другая…

* * *

Без булата препоясан тонкий стан,
Не летят на конях всадники, привстав.
Не встает тулпар крылатый под седло,
Переломлено у беркута крыло.

* * *

Не дли, Дэрдменд, мучительное слово!
И так душа закоченеть готова.
Покоя ради пусть язык твой тускл,
Не дрогнет на лице ни один мускул.

* * *

Гомерләрдер... Өелмәктә сагышлар...
Дәвам итмәктәдер шиддәтле[1] кышлар...
Һавалар тын... Кыеп очкан һома[2] юк...
Азан иштелсә дә, кыйбла-нөма[3] юк!..

* * *

Булырмы яз, исеп җилләр,
Килерме җәй, ачып гөлләр;
Җитәрме кыш, кичеп еллар, –
Диярменсез, газиз илләр.

* * *

Җилдем, йөгердем,
Бу җиргә җиттем;
Төштем бу чокырга –
Беттем, аһ, беттем!..

* * *

Бу ул матур, бу ул күркәм,
Бу ул,
Бу ул – хуш исле яз!
Бу ул – хуш исле таң җиле!..

* * *

Талигымдыр[4] таәзәлдән[5] –
Һәр эшем бозгын төшәр;
Былбылә корсам тозагы,
Бәхтемә козгын төшәр!

[1] *Шиддәтле* – бәла-казалы.
[2] *Һома* – бәхет кошы.
[3] *Нөма* – компас.
[4] *Талигымдыр* – өлешемдер, бәхетемдер.
[5] *Таәзәлдән* – әүвәле булмаган үткән заманнан.

* * *

В лихие времена неотвратимы
Страдания и гибельные зимы.
Ни птицы-феникса, ни тени от крыла.
Доносится азан, но не видна кибла.

* * *

Весна ль придет с теплом и ветром,
Придет ли лето, в цветы одето,
Зима ль задует, наступая, –
Все ты, все ты – земля родная…

* * *

Я бежал, стремился
Во весь дух,
Прибежал, свалился
В яму – бух!
Я попал
Прямо в яму!
Ах, пропал…

* * *

Как душистая весна,
Ты хороша,
Словно ветры предрассветные,
Свежа.

* * *

Знать, от первых дней
Все дела с клеймом:
В клетке соловей,
Ястреб над селом.

* * *

Болыт үтте. Гөмберли күк еракларда.
Сил[1] шаулый, сулар гөрли болакларда.
Тавышы – колакларда… озакларда…

* * *

Бертуганың чит тибәдер,
Дәүләт тигез булмаса;
Ана сөтен айры имә,
Бала игез булмаса.

* * *

Күрәмсең бу кабер ташын:
Башын игән, рөкүгъ иткән[2]!
Басып җиргә газиз башын,
Янә кемнәрне юк иткән?

* * *

Кил, и башчы! Агачны юнма юкка,
Кирәк булмас – угыңны як, кил, утка.
Агарды чәч,
Куарды баш,
Сары юллар сызылды.
Өмидләр, кем…
Өмидләр, кем…
Дәригъ, бер-бер өзелде!..

---

[1] *Сил* – ташкын, гөрләвек.
[2] *Рөкүгъ иткән* – иелгән, намазда тезләнгән.

* * *

Гроза прошла… Грохочет гром далеко,
Сель движется, вода журчит в потоках.
В ушах звучит, не умолкая… долго…

* * *

Когда нет равенства в стране,
Изгнанник будет брат родной.
Двух разлученных близнецов
Вскормить как матери одной?!

* * *

Гляди, вот камень гробовой
Стоит, склонившись головой.
Кого он здесь, среди могил,
Поклоном горестным почтил?

* * *

Подойди, о лучник! Стрелы
Не точи, сожги.
С головою поседелой,
Опаленный. Зги
Впереди не видно, только
Желтые пески.
Ах, какая жалость, сколько,
Ах, какая жалость, сколько
Без надежд тоски!..

* * *

Рәнеж хәтер[1] булганын илнең суыктан белде яз,
Кем, чәчеп нур, йөргезеп җилләр шифалы, килде яз.

Кар эреп, кырлар ачылды, таудан исте хуш җиләс,
Тау вә сахраларга яңа җан биреп сирпелде яз.

Кырны, тугайларны алды язгы сулар ташкыны,
Кем, чәчеп нурлар шифалы, йөргезеп җил, килде яз.

Яз үтеп, көннәр бетеп, булды тәмам гомрем кышы,
Агъла, и бичара Закир, кем, синеңчөн үлде яз.

* * *

Сеңеп җиргә, менеп җилгә, булып бу,
Агып кичмәктәдер гөрләп агым су.

Агач, ташлар тынып, таулар да тыңлар,
Менеп таштан, очып ташка, төшеп су,

Ага гөрләп, ага зарлап агым су,
Китә йомгакланып-йомгакланып бу.

Качан, балкып, җиһанга тулды якты,
Килеп, нур агълаган тауларны бакты, –

Дәрийгъ[2], нур күз яшен бәллүр[3] санды,
Кереп әлванга[4], ал канга буянды.

Ишет төннәрдәге былбыл фиганен[5],
Аның да бакчы, залим, якты җанын.

Очып, чүлләр кичеп, таулар ашып,
Килеп төшкән микән, башкай адашып?

Ят илнең яд итеп якты кояшын,
Камышлы суларын, кырчынлы ташын,

Тавышлар чыңравын ул саф һавада,
Сагышлар яңратып иркен далада,

Ерак диңгездә ул кышлар кичергән,
Чит илләрдән гариб моңлар[6] китергән.

---

[1] *Рәнеж хәтер* – «күңеле рәнҗүе» мәгънәсендә.
[2] *Дәрийгъ (дәригъ)* – үкенеч, кызганыч.
[3] *Бәллүр (биллүр)* – хрусталь.
[4] *Әлванга* – төсләргә.
[5] *Фиганен (фөган, фәган)* – ярдәм сорап ялваруын.
[6] *Гариб моңлар* – чит-ят моңнар.

* * *

Весна о родине в беде по холоду узнала,
Пришла, рассыпала лучи, целебный ветер разослала.

Растаял снег, открыв просторы, пришла с гор свежесть,
Вдохнувши жизнь в леса и горы, весна сияла.

Луга, низины потоки вешние омыли,
Лучами, ветром весна отчизну врачевала.

Когда ушла весна, для жизни зима настала.
Рыдай, Закир, о той, которой весной не стало.

* * *

Свергаясь с круч, взвиваясь к тучам с ветром,
Из-под земли поток прорвался к свету.

На камни прыгает, с камней сбегая,
Деревья, горы смотрят, замирая.

В клубки клубясь, свиваясь в перекаты,
Течет ревя, бурля, снося преграды.

Когда заря накрыла землю светом,
Заплаканные горы вскрыв при этом,

Увы, сочла их слезы хрусталями.
Лучи окрасились в цвет крови сами.

Ночами горю соловья внимая,
Смотри, тиран: душа его святая.

Чрез море, горы, из степи безбрежной
Летя, дорогу ль потерял сердечный?

По солнцу бывшей родины скучая,
О рощах и озерах вспоминая,

Как изливал всю душу на просторе
В многоголосом неумолчном хоре,

Он, проведя в далеких странах зимы,
Принес с чужбины скорбные мотивы.

## ВИДАГЪ[1]

Тәгәрәп-аунап
Буй үскән
Туган илем, исән бул!
Чәч кузгатып,
Җай искән
Таңгы җилем, исән бул!
Йөгреп-йөгреп
Туктаган…
Яулык болгап
Сыктаган
Нәзкәй билем, исән бул!

## КОРАБ

Шаулый диңгез…
Җил өрәдер…
Җилкәнен киргән кораб!
Төн вә көндез
Ул йөрәдер:
Юл бара ят ил карап…
Чыкты җилләр,
Купты тулкын –
Ил корабын җил сөрә!..
Кайсы юллар,
Нинди упкын
Тарта безне, җан сорап?!

## НӘСЫЙХӘТ

Җитәкләргә тырыш дөньяи дүнәнне[2],
Икенең бересе: йә сине җитәкләр.
Алып барыр үзеңне бер чокырга,
Барырсың – бардырыр, төртәр, этәкләр.

Мона ни ул усал карчыкның име:
Ку артыннан, ярыймы-юкмы дими!
Җитеп тә, бер сикертеп типсәң артын,
Дәни[3] бит ул – үзен тигәнгә тими!

---

[1] *Видагъ* – аерылышу.
[2] *Дөньяи дүнәнне* – дөнья дигән атны.
[3] *Дәни* – мәкерле.

## РАССТАВАНИЕ

Земля, где вырос я,
в траве валяясь,
Резвясь и бегая, прости!
Где шевелил рассветный ветер
На голове моей власы.
Где бегал и остановился…
Любимая, что провожала,
Платком махая мне, прости!

## КОРАБЛЬ

Разорвалось небо в клочья…
Жадно всматриваясь вдаль,
Выгнув парус,
Днем и ночью
Бороздит моря корабль.
Волны выше,
Бездна глубже,
Нет спасенья кораблю!
Кто восхощет наши души?
Что зовет его во тьму?!

## НАСТАВЛЕНИЕ

Одно из двух: ты погоняешь жизнь,
Или она тебя, толкая, гонит.
Загонит в яму, как ты ни держись
За край ее, столкнет, утопит.

Гони ее, каргу, перед собой
И не давай покоя стерве.
Нагнав, разок подпни ее ногой,
Она чудная: гонишь, стерпит.

* * *

Исәрме җил тугай буйлап,
Җыlармы кыз моңын сөйләп,
Көләрме шатланып, көйләп, –
Агач, таш эчләре шаңрап,
Киләдер бер нида яңрап!..

* * *

Җәй үтте…
Кар-яңгырлы көз урнашты,
Күк тугайның баурына боз урнашты.
Гөл кипте,
Сабагында кинә калды.
Былбыл!
Сиңа бер бөртек инә калды.

* * *

Гөрләгән сулар башында,
Тыңлагыз, шунда үтәр –
Йөрсә сыктап таң-сәхәрләр
Моң-сагышлардан хыял.
И туган илнең һавасы,
Рәнҗемим, зинһар, күтәр!
Рәнҗемим, зинһар, күтәр!

Ни газизрәк – бу ватанмы?
Аһ, туган каүмем газиз!
Ул мөкаддәс кан белән ул
Изге сөткә ни җитәр!..
Сөт калыр, ватан китәр!
Сөт калыр, ватан китәр!

* * *

Веют ли ветры,
Плачет ли дева,
Бор ли счастливый гудет,
Солнцем ли залито вешнее небо –
Горе с бедою грядет…

* * *

Минуло лето…
Холодная со снегом и дождями
Воцарилась осень.
Застыл со льдом в утробе сизый лес.
Засох цветок,
Осталась в стебле горечь.
Лишь острие его тебе осталось,
Соловей!

* * *

Слышишь, вешним половодьем,
Безотчетны, неясны,
В наших душах колобродят
Грезы юности и сны?
Не взропщу, отчизны воздух,
Дай подняться высоко!
Дай подняться высоко!

Что для сердца сокровенней?
С материнским молоком
Что сравнить?
Что есть священней
Кровных уз в краю родном?
Минут царства и державы,
Не иссякнет молоко!
Не иссякнет молоко!




*Рәсемдә Дәрдемәнднең "Бүзләрем маналмадым" шигыреннән өзек китерелгән. Рәссамы Ч. Әхмәров*
*На рисунке приведена строфа из стихотворения Дэрдменда «Я не соткал белой ткани». Художник Ч. Ахмеров*



*Татар кызы. Рәссамы Ч. Әхмәров*
*Татарская девушка. Художник Ч. Ахмеров*

## ҮТКӘН КӨННӘР

Әй кая ул көн ки бездә –
Шәп торулар бар иде;
Әмма дошманларда гамьләр[1],
Эч пошулар бар иде.

Берзаман чыгар идек без
Кырга дуст-ишләр илә;
Анда уенлар, көлүләр,
Сикерүләр бар иде.

Һай, гомерләр… үтте-китте…
Кая китте ул заман!
Кайда ул шәп һае-һулар[2]!
Гөфтегүләр[3] бар иде…

Бер вакыт буенча рәхимсез
Дәгел иде кызлары;
Анда туташларда ымлар,
Күз кысулар бар иде.

Ничә еллар үтте, әмма
Күрмәдек кызлар йөзен!
Янымызда әүвәле
Кандай[4] сылулар бар иде.

Шигърене күргәч (Закире)ң,
Диде өлкәнләр дә: «Һай!
Яшь чагында бездә һәм
Андай йөрүләр бар иде!»

---

[1] *Гамьләр* – бу урында «көнчелекләр» мәгънәсендә.
[2] *Һае-һулар* – шау-гөр килүләр.
[3] *Гөфтегүләр* – кара-каршы сөйләшүләр, әңгәмәләр.
[4] *Кандай* – нинди.

## БЫЛЫЕ ДНИ

Где они, деньки-денечки,
Распрекрасное житье!
У врагов одни заботы,
Беспокойство и нытье.

Мы друзей сберем, бывало,
И – на волю погулять!
Веселиться, посмеяться,
Бегать, прыгать да скакать.

Было время, было дело,
Хай, все шло само к рукам!
Игры, шумное веселье,
Разговоры по душам.

От красавицы жестокой
Мук натерпишься порой.
Взоры были, и намеки
Доходили стороной.

Столько лет прошло, не видя
Толком пары женских глаз.
А каких красавиц только
Прежде не было у нас!

Прочитав стихи Закира,
Говорили старики:
«Хай! И мы бывали прежде
Погулять не дураки».

## БЕЗ

Гасырлар кичте-китте… кичте еллар!
Нәбиләр[1], падишаһлар сөрде дәуран[2]…
Гомерләрдер күчеп кәрван вә кәрван,
Килеп кичте җиһандан канча илләр!..

Сүнеп, вәйран булып[3] мәгъмур[4] тиякләр,
Җир астында тезелде ку[5] сөякләр!..
Исә җилләр, күчә комлар… бетә эз…
Дәрийгъ, мәхзүн[6] күңел, без дә бетәбез!

Мосафир, кем җиһанга басты ботны,
Биетте ажгырып аны замана…
Өеп чергән өмидне… төртте утны –
Йотып утларны китте… яна-яна…

## КЫЙТГА

Һөҗүм иткән фәләк[7] җир-җир корып дам[8]…
Ишет милләтнең ул фөрьяд[9] вә зарын!
Сине бер хам тимер зан кыйлган ул хам…*
Чыгар кындан каләм – тел зөлфикарын[10]!

* * *

Куанды ил, канат какты мәләкләр,
Шашып, аң-таң булып, шайтан төкерде!..
Җитәр, җилкенмә, йолкынма, күңел, син,
Кияү булсаң да, ул туйга түгел син!
Җиһан тормыш туен иткән чагында,
Синең урның – үлекләр аймагында.

* * *

Ни әбаирдер мисакъта рухым иткән иртикяб,
Кем гадәм зәукыннан әүвәл хөкем ителгән янасы*.

---

[1] *Нәбиләр* – пәйгамбәрләр.
[2] *Дәуран (дәверан)* – гомер, чор.
[3] *Вәйран булып* – җимерелеп, хәрабә хәленә килеп.
[4] *Мәгъмур* – төзек.
